# МӘГАРИФ
education

mәğәrif

просвещение

## ТАТАР ТЕЛЕ

№3/ 2023




Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ**

МӘГАРИФ education
mağərif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

СЕНТЯБРЬ, 2023 ел

№ 3

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан,
Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе,
а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2023 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррирләр: **Фаизова Р.Г.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка: **Халитова Э.И.**

*Беренче тышлыкта: Буа шәһәрендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, директорның милли мәсьәләләр буенча урынбасары Фәүзия Хәйретдинова.*

*Сөмбел Таишева фотосы*

*3, 4, 14, 48, 60, 75 нче битләрдә Сөмбел Таишева фотолары*
*29, 38 нче битләрдә* Альберт Сабир фотолары
8, 18, 22, 43, 64, 67, 71, 83 нче битләрдә «Мәгариф» журналы фото архивыннан
87 нче битендә Энҗе Хиразова фото архивыннан

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

*Журнал распространяется бесплатно.*

**Расиха ФАИЗОВА.** Буада рус, чуваш балалары да татар телен сайлый....................3

**ЗӨҺРӘ РӘХИМҖАНОВА, ГӨЛСӘРИЯ МУЛЛАГАЛИЕВА.** Сабыйлар һөнәр сайлый....................8

**АЛСУ СУРОВА.** Туган тел дәресләрендә укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру алымнары....................14

**ГӨЛНАЗ КАМАЛОВА.** Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану....................18

**ЛӘЙСӘН ВӘЛИЕВА.** Ф.Әмирханның «Ай өстендәге Зөһрә кыз» әсәрен образлар бирелеше аша анализлау....................22

**РҮЗӘЛ ЮСУПОВ.** Телебез ничек бозыла?....................29

**ЭНҖЕ НУРИСЛАМОВА.** «Әйтеләсе сүзем чишмә челтерәвенә тиң»....................38

**ЛИЛИЯ ИБРАҺИМОВА.** Сүз ясагыч кушымчалар....................43

**ЛӘЙЛӘ ЗӘЙДУЛЛИНА, ЭЛЬВИРА АБДРАХМАНОВА.** Без – Тукайлы халык....................48

**ГӨЛНАЗ ГАЙНУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙНИЯТУЛЛИНА.** Укучыларда тыңлап аңлау, уку, язу һәм сөйләм күнекмәләре булдыру....................53

**ЛЮЦИЯ ЮНЫСОВА.** Сүзнең тамыры....................60

**ГӨЛИЯ ЧИГВИНЦЕВА.** Шигъри җанлы укытучы....................64

**ЛӘЙСӘН НИГЪМӘТУЛЛИНА.** Тарихта җуелмас эзе бар....................67

**ГӨЛНАЗ МУЛЛАГАЛИЕВА.** Укытучы заман белән бергә атлый....................71

**ЛӘЛӘ МОРТАЗИНА.** «Солабаш университеты» мөдәррисе....................75

**ЛИЛИЯ ҖӘЛӘЛОВА.** Ни өчен бу һөнәрне сайладыммы?....................79

**РИММА ГАБСАБИРОВА.** Чын дус нинди була?....................83

**ЭНҖЕ ХИРАЗОВА.** Укучыларда татарча дөрес язу гамәлләрен формалаштыру алымнары....................87

МӘГАРИФ education

01




# БУАДА РУС, ЧУВАШ БАЛАЛАРЫ ДА ТАТАР ТЕЛЕН САЙЛЫЙ



**Расиха ФАИЗОВА**




Ана теленә кызыксынуны үстерү укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм, заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын сорый. Буа шәһәрендәге аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендәге биш татар теле һәм әдәбияты укытучысының берсе, директорның милли мәсьәләләр буенча урынбасары Фәүзия Зариф кызы Хәйретдинова белән очрашкач, кайсы яктан гына килсәк тә, сүз туган телебезгә барып тоташты. Бу мәктәпне ТНВның «Мәктәп», «Тамчы-шоу» тапшырулары аша хәтерләүчеләр дә бардыр.

– Фәүзия ханым, 35 ел гомерен мәктәп белән бәйләгән мөгаллимә буларак, әйтегез әле, татар теле укытучысының бүгенге төп проблемасы нәрсәдә?

– Бездә рус, чуваш балалары да туган тел буларак татар телен сайлый һәм дәүләт теле буларак өйрәнә. Бу юнәлештә әти-әниләр белән зур эш алып барабыз. Мәктәпкә кабул иткәндә үк, әти-әниләргә әлеге мәсьәләдә этәргеч бирәбез, алар гаризада кайсы телне сайлавын күрсәтә. Кайчагында яшь ата-аналарның татар телен кирәксенмәүләре, аларның телебезгә салкын мөнәсәбәте җанны әрнетә. Бала каршы түгел, ә ата-ана «юк» дип кырт кисеп куя. Бала татар төркемендә укыса, анда өй эшен азрак бирәләр, дип, рус төркеменә күчермәкче булып йөрүчесе дә табыла. Дөрес, андыйлар күп түгел. Мисал өчен, узган уку елында укучыларыбызның 458 е татар, 206 сы рус, 56 сы чуваш, 8 е башка милләттән иде. Шулардан 700 е туган тел буларак татар телен, 28 е туган тел буларак рус телен сайлады. 2 милли белем һәм тәрбия сыйныфында (4 нче А, 5 нче В сыйныфлары) – 57 укучы ( бу барлык татар балаларының 12 % ы), телне татар һәм рус төркемнәренә бүлеп укытабыз.

Мәктәбебездә милли белем һәм милли традицияләр нигезендә тәрбия бирү иң төп юнәлешләрнең берсе санала. Хәзерге заманда балада милли үзаң формалаштыруда милли белем бирү хәлиткеч роль уйный. Директорыбыз Ранис Рәисович Әхмәтов безгә бөтен шартларны тудырып ярдәм итә. Нинди тәкъдим белән чыксак та хуплау табабыз. «Әйдәгез, кызлар, эшлибез татар теле безгә кирәк!» – дип кенә тора. Бездә туган тел буларак, рус телен сайлаучы ике генә төркем бар иде, аларның берсе мәктәпне тәмамлады, хәзер берәү генә калды.

–Татар телен үзебез дә юньле-рәтле белмибез, дәрес әзерләгәндә ярдәм дә итә алмыйбыз,

диюче әти-әниләр дә очрыйдыр?

– Булгалый. Аңлатабыз инде андыйларга, өйләренә дә барган булды. Алар, гадәттә, рус төркеменә бирәләр балаларын. Мин, әлбәттә, татар теленә ихтыяҗ булуын һәм укучыларым татар теленнән имтихан бирсен иде дип телим. Берничә ел элек олимпиадаларда актив катнашып йөргән укучыларым: «Сезне алыштырырга кайтачакбыз, татар теле укытучылары булабыз»,– дип, татар теленнән имтиханга әзерләнеп тә йөргән иделәр, киләчәктә телгә ихтыяҗ юк, перспектива күрмибез, дип ахыр чиктә күңелләре сүрелде һәм инглиз теле юнәлешендә укырга киттеләр.

Безнең чуваш балалары да татарча бик яхшы белә. Алар өчен берничә ел инде чуваш телен өйрәтүче якшәмбе мәктәбе эшли, ни гаҗәп, балаларны шунда тарту авыррак.

Мәктәптә укучылар белән бик күп чаралар үткәрелә, Буа драма театрына, район мәдәният сараена, Туган якны өйрәнү музеена даими экскурсияләр оештырабыз. «Сөмбелә», «Каз өмәсе» йолалары, «Нәүрүз» бәйрәме, Габдулла Тукай, Муса Җәлилнең туган көннәренә багышлап «Шигърият көне», татар теле һәм әдәбияты атналыгы һ.б. үткәрелә. Мәктәбебездә күп еллардан бирле «Үз йолдызыңны кабыз!» драма түгәрәге эшләп килә. Укучылар бик теләп йөриләр һәм, ел саен «Ният», «Сәйяр», «Без бергә» фестивальләрендә катнашып, призлы урыннарга лаек булалар.

Сәләтле балалар белән дә эш эзлекле рәвештә алып барыла. Укучыларыбыз республикакүләм конференцияләрдә, күп кенә бәйгеләрдә җиңүләргә ирешәләр. Узган уку елында Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары бездә булып, укучылар тормышын яктырткан «Татар теле– сәхнә теле» дигән спектакль куеп китте. Пушкин картасы белән 100 ләп бала карады ул тамашаны. Шагыйрь-укытучы Гөлнур Айзатуллова да еш кунак мәктәбебездә. Уздырылган чаралар барысы да туган җиргә, халкыбызның гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү, сөйләм телләрен баету максатын күздә тота.

– Сөйләм телләрен баету дигәннән, балалар матур әдәбиятны укымый дибез, ул чагында баланың сүз байлыгы да чамалы, сөйләм теле дә көтег-
рәк, такы-токы була түгелме соң инде?

– Игътибар итсәгез, хәзер күбрәк тә андыйлар, компьютерга алданалар. Шуңа күрә дә әдәбият дәресләренә әдәби китаплар алып киләм. Әсәрнең әзрәген кычкырып укыйбыз да, кызыксынып укысыннар дип, калганын өйдә укып бетерегез, дим. Укымыйлар. Татар теле укытучылары гына түгел, рус теле, әдәбияты укытучылары да зарлана бу уңайдан. Андыйларга «РФ халыклары телләре» дип аталган укуларда катнашып, грантка ия булган Ләйлә Абзалованы, Ренат Харис премиясенә лаек булган Энҗе Гомәрованы үрнәк итеп куярга кала.

Сөйләм теле аксаганнар белән дәрес кысаларында авазларны дөресләү өстендә эшлибез. Без инде «к», «г»ларны төзәтәбез. Кайберләре тәнәфес вакытында укытучы янына үзе килә.

–Татар теле кабинетларыгыз да бик матур икән, дәреслекләр уңаеннан ни диярсез? Хәзер бит ИЯЛИ дә,«Мәгариф – Вакыт» та дәреслекләр чыгара. Татар китап нәшри-

ятында да дәреслекләр бастыралар. Сез нинди дәреслекләргә өстенлек бирәсез?

– Әйе, мәктәптә өч татар теле һәм әдәбияты кабинеты бар. Шуларның икесе компьютер, проектор белән җиһазландырылган. Өчесендә дә күрсәтмә материаллар, портретлар, медиотека тупланган. Дәресләрдә яңа технологияләр кулланып эшләүгә зур игътибар бирәбез. Ел саен төрле дәрәҗәдәге семинарлар кысаларындареспублика, төбәкара, район күләмендә ачык дәресләр күрсәтәбез. 2021 елда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган бәйгедә 500 мең сумлык грантка лаек булдык һәм шул хисаптан татар теле һәм әдәбияты кабинетларына проекторлар, стендлар алынды, милли костюмнар тегелде, музей оештырдык. Экспонатлар җыюда укучыларыбыз да, әтиәниләребез дә актив катнаштылар.

Мәктәптә туган телне (татар телен) һәм туган тел әдәбиятын укытуны укыту-методик тәэмин ителеше Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган дәреслекләрнең федераль исемлеге нигезендә тормышка ашырыла. Татар төркемнәрендә Ф.Ш. Гарифуллина, Ф.Ф. Харисов, Р.К. Сәгъдиева, Ф.Ф. Хәсәнова дәрес-
лекләре белән эшләп килдек.

Башлангыч һәм урта сыйныфларда башка милләт балаларын татар теленә өйрәтүдә «Сәлам», «Күңелле татар теле» УМКсын кулланып эшлибез. Ул телне өйрәткәндә, укучыларда теләк һәм кызыксыну уята. Җайлы да, җырлар да булгач, балаларга да кызык. Мин андагы җырларны татар төркемнәренә дә алып керәм. «Карагыз әле, нинди матур бит безнең татар теле!» –дип, «Туган тел»не сузып җырлап җибәргән чакларым да була, чөнки үзем дә бик җырларга яратам. (Җырлап та җибәрә.)

– Сез сәхнәдә дә җырлагансыздыр, музыка мәктәбен тәмамладыгызмы әллә?

– Юк. Бернинди музыка мәктәбе булмады, тумыштан килгән сәләт белән авыл клубында гармунга җырлап үскән балалар без. Безнең Тутай авылында күршегә туганнан туган апасына композитор Сара Садыйкова кайтып йөри иде. Ул йортта элмә такта тора хәзер. Мин аңа күчтәнәчкә сөт, йомырка кертәм. Ул үзенең яңа җырларын миннән җырлатып карый иде. «Яз да сайрый, көз дә сайрый /Бер нәни кош бакчамда», – дип җырлаганнарым әле дә истә. Аннан аяклар җиргә тими генә, канатлар үсеп киткәндәй очып чыга торган идем. «Мин сине консерваториягә укырга кертәм», – дигәне дә булды. Берсендә көзге көн, пычрак, «Кара әле, Фәүзия, тургай ничек сайрый!» – ди, тәмам хисләнеп. Әй Аллам, каян, нәрсә ишетә диген… Хәзер күп кенә истәлекләрне укучыларыма да сөйлим. Берсендә минем абыйлар колхоз печәнен чәлдереп алып кайтып баралар икән дә , Сара апа: «Ах, Мокамайлар, караклар!» – дип, артларыннан куа икән тегеләрнең…. Шуларны искә төшереп утырабыз хәзер. Мәктәпкә очрашуларга чакыра идек. Сара апаның кызы Әлфия Айдарская белән дә очрашулар булды. Музей җитәкчесе декретта чагында ул, авылга кайтып, музейда эшләп торган иде.

Сара Садыйкова музеена да алып барып кайтам балаларны, турыга гына барганда Буадан 30 чакрым Тутай авылы.

–Туган авылга кайткач, бала чагыгызга, әти-әни янына кайткан кебек булып киләсезме?

– Әлбәттә. Һәркемгә үз туган ягы, туган нигезе газиз. Мин ишле гаиләдә алтынчы төпчек бала булып тудым. Апа, абыйлар белән бергәләп, колхозга бишәр гектар чөгендер эшкәртеп, фермада сыер савып, кечкенәдән авыр эш эшләп үстек. Галимҗан Ибраһимовча итеп, «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек», – дисәм, ул безгә бик туры киләчәк. Башта биш чакрым җәяү йөреп күрше Кызыл Тау авылына, аннан Чувашиянең Ялчик авылына йөреп укыдык. Анысы җиде чакрым. Шунда мәктәпне медальгә тәмамладым.

– Укытучы һөнәрен сайлау ул балачак хыялы идеме?

– Кулыма чүпрәк сеткамны тотып, университетның юридик факультетына гариза бирергә килгәч, минем документларны карадылар да, аттестаттагы чуваш телен күреп, «Сез безгә яхшы белгеч булачаксыз, милли мәктәпләрдә рус теле укытырга безнең кафедрада эшкә калырсыз»,– дип, филология факультетына керергә кыстадылар. Авыл баласына болай да укырга керергә авыр, дип ризалаштым, чөнки әтием авылда институт тәмамлаган бердәнбер ветеринария табибы иде.

– Гаиләдә педагогика юлын сайлаган бердәнбер бала да сез булдыгызмы?

– Юк. Абыем Илгизәр Садыйков әле дә ветеринария техникумында укыта, Гөлсинур апам Вахитова озак еллар ТР Фәннәр академиясендә өлкән фәнни хезмәткәр булып эшләде, Илһам абыем Апас районында ДОСАФта укыта, апам Венера Бәдретдинова ветеринария техникумында мастер булып эшләде. Илсөяр апам гомер буе Казанда салым инспекциясендә булды. Күбебезнең эше укыту белән бәйле. Телче булып китүемә һич кенә дә үкенмим. Җаным-тәнем белән балалар татар телен белсеннәр дип тырышам. Сөйләм теле булса җитә, грамматика кирәкми, ди кайберәүләр. 9 нчы сыйныфларда җөмлә тикшергәндә, «Ә рус телендә ул болай», – дип чагыштырып карау мөмкинлеге дә бирәм, «Балалар, карагыз, нинди камил бит телебез, бу бит югары математикага тиң!»– дим. Күптән түгел генә рус төркемендә укыган укучымны очраттым кибеттә. Мәскәүдә яши икән. «Сез минем күңелемдә шундый матур эз калдырдыгыз. Балаларым башкалада татарча укымый, мин сездән алган белемгә нигезләнеп, аларны үзем өйрәтәм. Рәхмәт сезгә!» – ди. Мондый бәяне ишетүе бик күңелле бит укытучы өчен.

– Үзегезнең балаларыгызның телгә мөнәсәбәтен беләсе килә. Алар белән дә таныштырып китсәгез икән.

– Ирем Рашат белән бер ул, бер кыз тәрбияләп үстердек. Әтиләре –төзүче. Балалар шушы мәктәптә укыдылар, бөтен бәйге, олимпиадаларда катнашып йөри иделәр. Улым Рифатның хәзер инде үз гаиләсе бар. Ул – инженер, экономист, ике югары уку йорты тәмамлады, Казанда банкта эшли. Кызым Әдилә – Ульян каласында IT-белгеч. Институтта инглиз, француз һәм үзлегеннән кытай, испан телләрен өйрәнде. Элек бер авызга ике тел сыймый дия торган иделәр. Сыя. Тик алар арасында ана теле беренче булырга тиеш. Балалар кечкенә чакта бик елаганда да «Туган тел»не җырлап юата идем. Хәзер улым вакытвакыт: «Әнием, әйдә, «Туган тел»не җырла» ,– дип, видеодан шалтырата. 2,5 яшь ярымлык оныгым Даниярны да Г. Тукайның «Туган тел»е белән юатабыз.

02



# САБЫЙЛАР ҺӨНӘР САЙЛЫЙ

*(Уртанчылар төркемендә интегральләшкән белем бирү эшчәнлеге)*



**Зөһрә РӘХИМҖАНОВА,**

Балтач районы Кариле балалар бакчасының I квалификация категорияле өлкән тәрбиячесе



**Гөлсәрия МУЛЛАГАЛИЕВА,**

Балтач районы Кариле балалар бакчасының югары квалификация категорияле тәрбиячесе

Баланы социальләштерү процессының иң мөһим өлеше – аның һөнәри билгеләнеше, үз һөнәри юлын аңлы һәм мөстәкыйль сайлау процессы. Бала олы тормышта нинди һөнәр белән шөгыльләнүен аңлы рәвештә сайласын өчен, аны мөмкин булганча күбрәк төрле һөнәрләр белән таныштырырга кирәк. Һәм, иң беренче чиратта, якын-тирәдәге кешеләр, әти-әниләр һөнәрләре белән таныштырудан башлау дөрес. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның хезмәт һәм һөнәрләр дөньясы турында күзаллауларын формалаштыруны аңлаешлы һәм кызыклы итеп, заманча белем бирү таләпләрен исәпкә алып төзергә кирәк. Сабыйларның һөнәрләр дөньясы турында күзаллауларын киңәйтү һәм мәктәпкәчә яшьтәге этапта ук һөнәри юнәлеш бирү эшен системага салу өчен, без бу юнәлештә максатчан эш алып барырга булдык.

**Максат:** балаларның һөнәрләр турында кызыксынуларын һәм башлангыч белемнәрен формалаштыру.

Максаттан чыгып, үз алдыбызга түбәндәге **бурычлар**ны куйдык:

– яшь үзенчәлекләренә туры китереп, һөнәрләр турында күзаллау формалаштыру;

– өлкәннәрнең хезмәте, матди һәм матди булмаган хезмәт нәтиҗәләре, аның шәхси һәм иҗтимагый әһәмияте турында күзаллауны киңәйтү;

– һөнәрләр турындагы күзаллауны уен эшчәнлегендә чагылдырырга өйрәтү;

– хезмәткә һәм һөнәри дөньяга карата эмоциональ-уңай мөнәсәбәт формалаштыру;

– мәктәпкәчә яшьтәге балаларга һөнәри юнәлеш бирү буенча ата-аналар арасында даими аңлату-агарту эше алып бару;

– төрле һөнәр ияләренә карата хөрмәт, аларның хезмәтенә (хезмәт нәтиҗәләренә) сакчыл караш тәрбияләү.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга иртә һөнәри юнәлеш бирү буенча эш безнең балалар бакчасында өлкәннәрнең балалар белән уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре һәм социаль учреждениеләре белән хезмәттәшлек итүе, проектлар буенча эшләү аша оештырылды.

Бу эшне тормышка ашыру максатыннан һәр яшь төркеме өчен перспектив планнар төзелде, аларда әлеге юнәлеш буенча чаралар үткәрү каралган иде. Балаларга иртә һөнәри юнәлеш бирү нәтиҗәле булсын өчен, төркемнәрдә үстерешле предметлы тирәлек мохите булдырдык. Һөнәрләр турында китаплар, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, санамышлар, тизәйткечләр, һөнәрләр һәм хезмәт кораллары турында шигырьләр, бармак һәм артикуляция гимнастикасы буенча уеннар, ял минуты картотекасы тупланды. Шулай ук сюжетлы-рольле, сүзле уеннар, өстәл уеннары картотекасы, «Балалар бакчасы һөнәрләре», «Бездә тәрбияләнүче сабыйларның әти-әниләре һөнәрләре», «Төрле һөнәрләр», «Авыл һәм шәһәр кешеләре һөнәрләре», «Хатын-кыз һәм ир-ат һөнәрләре» темалары буенча күрсәтмә материаллар, күптөрле дидактик уеннар, мультфильмнар, видеофильмнар тупланды, «Һөнәрләр дөньясында» лэпбугы ясадык. Киенеп уйнау почмагы сюжетлы-рольле уеннар өчен костюмнар белән тулыландырылды. Төркемнәрдә «Кибет», «Хастаханә», «Чәчтарашханә», «Гараж», «Төзелеш», «Даруханә», «Банк» темалары буенча уңайлы уен зоналары булдырдык һәм баеттык.

Балалар белән эшне оештырганда, без төрле алымнар, эшчәнлек төрләре: әңгәмәләр, күзәтүләр, экскурсияләр, виртуаль экскурсияләр, рәсемнәр карау, күргәзмәләр, матур әдәбият уку, мультфильмнар карау, сәнгать иҗаты, табышмаклар чишү, викториналар, бәйрәмнәр, төрле уеннар кулландык.

Һөнәри эшчәнлекнең тәүге нигезләре уенда салына. Уен – баланың беренче профориентаторы. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеге турында күзаллауларын формалаштыруда сюжетлы-рольле уеннар зур роль уйный. Сабыйлар андый уеннарны бик яратып уйный, чөнки алар үзләре теләгән рольне башкара ала. Сюжетлы-рольле уеннар вакытында балалар бер-берсе белән аралаша, алар үзләрен ирекле тота, уйнаганда булган белемнәренә, тәҗрибәләренә таяна һәм күзаллауларын киңәйтә.

Һөнәрләр белән таныштырганда, төрле дидактик уеннарны куллану да нәтиҗәле. Аларны белем бирү эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә, аерым балалар белән дә, берничә бала белән дә кулланып була. Уеннар барышында балалар төрле һөнәрләр, аларның атрибутлары, үзенчәлекләре белән таныша.

Шулай ук педагоглар һәм ата-аналар тырышлыгы белән «Һөнәрләр дөньясында» кейсуены әзерләнде. Ул унике төрле һөнәр буенча уеннар комплектын үз эченә ала. Һәр һөнәр буенча фотосурәтләр, иллюстрацияләр, табышмаклар, шигырьләр, буягычлар, видеоматериаллар тупланды. Әлеге уеннар кейс-технологиягә нигезләнеп төзелгән. Уйнаганда, балалар төрле проблемалы ситуацияләрне чишә һәм аларның һөнәрләр турында белемнәре формалаша, арта.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга иртә һөнәри юнәлеш бирү эшен оештыру кысаларында «Күлмәкне кем тегәр?» мультфильмын төшердек. Бу эштә педагоглар гына түгел, балалар да катнашты. Алар мультфильм булдыруның барлык этапларында: сценарий язуда, атрибутлар һәм декорацияләр ясауда, пластилиннан фигуралар әвәләүдә, сюжетларны кую һәм фотога төшерүдә, рольләрне тавышларга бүлеп укуда актив катнашты. Мультфильм ясау барышында балалар ашчы, чәчтараш, тегүче һөнәрләре турында белемнәрен ныгытып кына калмады, ә сценарист, режиссёр-мультипликатор, рәссам-куючы, тавыш бирү актёры, тавыш режиссёры, монтаж ясаучы кебек һөнәр вәкилләренең эш үзенчәлекләре белән дә танышты. Нәтиҗәдә килеп чыккан мультфильм балаларга икеләтә кызыклы булды, чөнки алар аны ясауда үзләре дә катнашты. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Мәгарифне үстерү институты тарафыннан уздырылган «Иң яхшы цифрлы белем бирү практикалары» авторлык методик эшләнмәләренең республика бәйгесендә катнашып, әлеге мультфильмыбыз I дәрәҗә Дипломга лаек булды.

Иртә һөнәри юнәлеш бирү буенча эш төрле һөнәр ияләре белән очрашулардан башка мөмкин түгел. Балаларыбыз тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, шәфкать туташы, музыка җитәкчесе, аш-су остасы, кер юучы кебек бакча хезмәткәрләренең һөнәр үзенчәлекләре белән танышты. Шәфкать туташы, кер юу, аш бүлмәләренә һәм балалар бакчасының башка кабинетларына экскурсияләр оештырдык. Экскурсия вакытында балаларның игътибары эшләүче кешегә, аның башкара торган эшенә карата мөнәсәбәтенә, башка кешеләр белән үзара мөгамәләсенә юнәл-

телде. Әлеге һөнәр иясенә нинди сыйфатлар хас булуы турында сөйләделәр. Өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлеген күзәтү балаларның үз-үзләрен тотышына, аларның кешеләргә, җиһазларга карата мөнәсәбәтләренә уңай тәэсир итә.

Балалар өчен виртуаль экскурсияләр дә кызыклы булды. Мәсәлән, алар виртуаль рәвештә чәчтарашханәгә, хастаханәгә «барып кайттылар». Бакчада тәрбияләнүчеләрнең әти-әниләре белән дә очрашулар узды. Алар үзләренең махсус киемнәрен алып килде, үз һөнәрләре турында балаларга аңлаешлы итеп мәгълүмат җиткерде. Балалар үз чиратында үзләрен кызыксындырган сорауларга өлкәннәрдән җаваплар ала алды.

Чыннан да, балалар бакчасы педагогларының балаларны өлкәннәр хезмәте белән таныштыру эше ата-аналар белән бәйләнешсез генә тиешле нәтиҗәләр китерә алмый. Ата-аналар белән анкеталар, консультацияләр, буклетлар, белешмәлекләр, «Әти-әниемнең һөнәрләре» фотоальбомнары, очрашулар, фотокүргәзмәләр, төрле һөнәрләр өчен костюмнар тегү, «Элек һөнәр ияләре кулланган атрибутлар» күргәзмәсе кебек эш төрләре кулланылды.

Балалар бакчасының еллык планы нигезендә тәрбиячеләр өчен әлеге тема буенча төрле чаралар: «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга башлангыч һөнәри юнәлеш бирү проблемалары һәм перспективалары» темасына педагогик киңәшмә, консультацияләр, «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән иртә һөнәри юнәлеш бирү буенча эш формалары» темасына семинар-практикум, дидактик кулланмалар бәйгесе уздыру каралган иде.

Шулай ук курчаклар күргәзмәсе оештырдык, алар өчен тәрбиячеләр көче белән төрле һөнәрләр буенча костюмнар тегелде. Әлеге курчаклар шөгыльләр барышында, режимлы моментларда мәктәпкәчә яшьтәге балаларны теге яки бу һөнәрләр белән таныштырганда файдаланылды. «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга һөнәри юнәлеш бирү буенча иң яхшы дидактик кулланма» бәйгесе кысаларында безнең балалар бакчасы базасында педагоглар төрле кызыклы дидактик кулланмалар, уеннар әзерләде.

Бу юнәлеш буенча үзебезнең эш тәҗрибәсе белән без тәрбиячеләр өчен «Мәктәпкәчә учреждение шартларында иртә һөнәри юнәлеш бирү» дигән тема буенча үткәрелгән төбәк семинарында уртаклаштык. Анда безнең тәрбиячеләр балаларның ашчы, табиб һөнәрләре турында күзаллауларын киңәйтү буенча ачык чаралар күрсәтте. «Күлмәкне кем тегәр?» мультфильмын ясау этаплары белән таныштырдык. Шулай ук балалар «Һөнәрләр калейдоскобы» музыкаль композициясе белән чыгыш ясады. Әти-әниләр көче белән тегелгән һөнәр киемнәре модасы күрсәтеп, балалар үзләре сайлаган һөнәр иясе булып карадылар һәм подиумда модель булып йөрү күнекмәләренә дә төшенделәр.

Сабыйларның һөнәрләр дөньясы, иҗтимагый әһәмияткә ия хезмәт нәтиҗәләрен баету аларда үзләрен кызыксындырган эшчәнлек төрен сайлауда инициативалылыкны үстерүгә, мөстәкыйльлек, активлык һәм иҗатдилык күрсәтүгә ярдәм итте. Бу – аларга киләчәктә мәктәптә уңышлы укырга, ә соңыннан үз эшенең осталары булырга ярдәм итә. Киләчәктә дә без бу юнәлеш буенча эшне дәвам иттерергә

уйлыйбыз. Чөнки хәзерге дөньяда яңа төр һөнәрләр күп, һәм безнең бурыч – мәктәпкәчә яшьтәге балаларга иртә һөнәри юнәлеш бирү өчен шартлар тудыру. Киләчәктә балалар һөнәр сайлауда ялгышмасын иде.

Түбәндә журнал укучылары игътибарына иртә һөнәри юнәлеш бирү буенча уртанчылар төркемендә уздырылган «Нәни аш-су осталары» дигән белем бирү эшчәнлеге эшкәртмәсен тәкъдим итәбез.

**Белем бирү өлкәләренең интеграциясе:** танып белү үсеше, сөйләм үсеше, сәнгати-эстетик үсеш.

**Үткәрү формасы:** оештырылган белем бирү эшчәнлеге.

**Максат:** балаларның ашчы һөнәре турындагы күзаллауларын үстерү.

**Бурычлар**

*Үстерелешле:* балаларның ашчы һөнәре турында белемнәрен киңәйтү; бәйләнешле сөйләмне, сүзлек запасын үстерү.

*Белем бирүдә:* кош теле ясарга өйрәтү; камыр җәю һәм кисү өчен кулланыла торган эш кораллары белән таныштыру һәм алар белән эшләргә өйрәтү.

*Тәрбияви:* ашчы хезмәтенә кызыксыну уяту, пөхтәлеккә өйрәтү.

**Алымнар:** әңгәмә, слайдлар карау, камыр белән эшләү, сүзле уен.

**Актив сүзлек:** ашчы, кош теле, уклау, кискеч, камыр.

**Җиһазлау:** ноутбук, экран, эшчәнлекнең эчтәлеге буенча презентация, өстәлләр, төрле һөнәр ияләре булып киендерелгән курчаклар (ашчы, табиб, төзүче, янгын сүндерүче), төрле һөнәр ияләренең эш кораллары (укол, чүкеч, фен, кәстрүл, такта, уклау, кискеч, чүмеч, кыргыч, пычак, таба, плитә уенчыклары); балалар саны буенча уклаулар, силикон куналар, кискечләр, тозлы камыр кисәкләре, тәлинкәләр, алъяпкычлар, башлыклар, салфеткалар.

## ЭШЧӘНЛЕК БАРЫШЫ

### I. Кереш өлеш

**Тәрбияче.** Исәнмесез, балалар! Кәефләрегез ничек? Мин сезгә бер табышмак әйтим әле.

Әйтегезче, кем соң шулай
Тәмле ашлар,
Котлетлар һәм пироглар,
Салатлар һәм тортлар
Әзерләп безне сыйлый? *(Экранда ашчы сурәте күрсәтелә.)*

– Балалар, без сезнең белән бүген ашчы һөнәре турында сөйләшербез. Сез ашчы турында нәрсәләр беләсез? Ашчы нишли? *(Балалар җавабы.)* Әйе, ашчы тәмле итеп төрле ризыклар пешерә.

### II. Төп өлеш

1. «Ашчы һөнәрен таны» уены.

**Тәрбияче.** Балалар, ә хәзер менә бу өстәл янына килегез әле. *(Төрле һөнәр ияләре булып киендерелгән курчаклар куелган өстәл янына киләләр.)* Игътибар белән карагыз, өстәлдә нәрсәләр бар? Шушы курчаклар арасыннан ашчы курчакны табып күрсәтегез әле. Сез аны ничек таныдыгыз? Ашчы курчак башына, өстенә нәрсә кигән?

2. «Ашчыга нинди эш кораллары кирәк?» уены.

**Тәрбияче.** Балалар, һәр һөнәр иясенең эш кораллары бар. *(Төрле уенчык эш кораллары куелган өстәл янына киләләр.)* Менә бу өстәлдә төрле һөнәр ияләренең эш коралларын күрәсезме? Сез шулар арасыннан ашчы һөнәренә туры килгән эш коралларын сайлап алыгыз. Сайлап алынган эш кораллары белән ашчы нишли, сөйләп күрсәтегез әле. *(Балалар ашчыга кирәкле эш коралларын сайлап алалар һәм алар*

*ярдәмендә ашчы нишләве турында җөмләләр төзеп әйтәләр. Мәсәлән: «Ашчы уклау белән камыр җәя», «Ашчы табада котлет, балык кыздыра» һ.б.)*

3. Ризыклар турында әңгәмә.

**Тәрбияче.** Мин бүген сезгә ашчы булып карарга тәкъдим итәм. Ашчы төрле ризыклар пешерә. Сез татар халкының нинди милли ризыкларын беләсез? Ә менә бу ризыкны танып атый аласызмы? *(Экранда – кош теле сурәте.)* Әйе, бу татар милли ризыгы – кош теле була. Ә сезнең ашчы булып карыйсыгыз киләме? Мин сезгә ашчылар булырга һәм кош телен пешереп карарга тәкъдим итәм. Ризык пешерер алдыннан ашчы нишләргә тиеш? Башлык һәм алъяпкыч ашчыга ни өчен кирәк?

4. Кош теле ясау.

**Тәрбияче.** Ә хәзер өстәлләр янына киләбез. Эшне башлар өчен безгә нишләргә кирәк? Эшкә керешер алдыннан кулларны… *(чиста итеп юабыз).* Чәч төшмәсен өчен… *(башлык киябез),* пычранмас өчен… *(алъяпкыч бәйлибез). (Балалар кулларын юа, башлык һәм алъяпкыч кия.)* Ә хәзер өстәлдәге эш коралларына игътибар итегез. Анда нәрсәләр күрәсез? Кош теле ясау өчен, мин сезгә камыр кисәкләре бирәм. Иң беренче камырны нишләтәбез?

**Балалар** *(слайдка карап әйтәләр һәм эшлиләр).* Камырны җәябез.

**Тәрбияче.** Ә хәзер нишлибез?

**Балалар** (*слайдка карап әйтәләр һәм эшлиләр).* Кискеч белән камырны кисәбез.

**Тәрбияче.** Һәм соңыннан нишлибез?

**Балалар** (*слайдка карап әйтәләр һәм эшлиләр).* Киселгән кош телләрен тәлинкәгә салабыз.

**Тәрбияче.** Хәзер кош телен ашап буламы? Юк шул әле. Аны пешерәсе бар. Ә кош телен ничек пешерәләр? Кемнең аны пешергәнне күргәне бар? Кош телен майда куыралар. Балалар, кош телен үзегез генә пешерә аласызмы? Кем белән пешерәбез? Ә хәзер ничек пешерәбез? Газ плитәсе юк, кайда пешерәбез? Балалар бакчасында аш-су бүлмәсе бармы соң? Анда кемнәр эшли? *(Балалар бакчасында эшләүче ашчы керә.)*

**Ашчы.** Исәнмесез, балалар! Сез мине таныдыгызмы?

**Тәрбияче.** Балалар, Гөлназ апагыз безнең балалар бакчасында кем булып эшли? Балалар бакчасының аш-су бүлмәсендә газ плитәсе бармы? Гөлназ ханым, сез безгә ярдәм итә алмассызмы? Кош телләрен кайнар майда пешереп бирегезче.

**Ашчы.** Кош телләрен бик оста ясагансыз, бик теләп пешерермен. *(Балалар ясаган кош телләрен алып чыгып китә.)*

**Тәрбияче.** Эшне төгәлләдек, хәзер безгә нишләргә кирәк?

**Балалар.** Эш урынын җыештырабыз, кулларны сөртәбез. (*Ашчы пешкән кош телләрен алып керә.)*

**Ашчы.** Рәхим итеп алыгыз. Ә мин кире үз эшемә кайтыйм. Сезгә төшке ашка тәмле ризыклар пешерәсем бар. Сау булыгыз.

**Балалар.** Рәхмәт. Сау булыгыз.

**Тәрбияче.** Менә, балалар, Гөлназ апагыз кош телләрен пешереп тә алып килде. Кош телләре тагын да тәмле булсын өчен, өсләренә шикәр комы сибик әле.

**III. Йомгаклау**

**Тәрбияче.** Балалар, сезгә ашчы булу ошадымы? Ә сез кош телен пешерү турында кемгә сөйләр идегез? Кош телен җәяргә, кисәргә кемгә өйрәтер идегез? Әйдәгез, балалар, үзегез ясаган кош телләрен алып, төркемебезгә кайтабыз. Кош телләрен авыз итеп карарбыз.




03

# УКУЧЫЛАРНЫҢ УКУ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ АЛЫМНАРЫ

МӘГАРИФ

*(Мастер-класс)*

**Алсу СУРОВА,**

Чистайдагы 2 нче лицейның татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Хәерле көн, хөрмәтле хезмәттәшләрем! Сезне барыгызны да мастер-классымда күрүемә бик шатмын. Мастер-классым күңелләрегезгә тирәнрәк үтеп керсен өчен, без аны курай моңы астында үткәрербез.

«Фән ул – диңгез: чум да рәхәтләнеп, энҗе-мәрҗәннәр эзлә», – дигән күренекле татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани.

Без, һәрбер дәрестә укучылар белән тел дигән дәрьяга чумып, энҗе-мәрҗәннәр эзлибез, алар ярдәмендә сүз байлыгыбызны арттырабыз, белемнәребезне ныгытабыз.

Яңартылган федераль белем бирү стандарты таләпләре буенча хәзерге вакытта белем бирү оешмаларында функциональ грамоталылыкны үстерү – иң актуаль темаларның берсе. Уку грамоталылыгын формалаштыру аның бер тармагы булып тора. Үземнең темамны да шуны истә тотып билгеләдем.

Белем бирүнең нинди генә өлкәсен алсак та, беренче чиратта, аңлап уку, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аера белү сәләте кирәк. Төп максатларымның берсе– укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру, алган белемнәрен тормышта дөрес итеп кулланырга өйрәтү.

**Мастер-классымның темасы:** «Туган тел дәресендә укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру алымнары».

**Максат**: укучыларда аңлап укуга кызыксыну уяту.

Минем фикеремчә, белемле һәм тәрбияле шәхес кенә тормышта үз урынын таба алачак. Шуларны истә тотып, мин түбәндәге **бурычлар**ны куйдым:

– укучыларны үз фикерләрен татар телендә дөрес һәм матур итеп әйтә белергә өйрәтү;

– укучыларның аңлап уку күнекмәсен булдыру;

– хезмәттәшлек нигезендә төрле яклап камил, иҗади үсешкә сәләтле, компетентлы, тормышка әзер шәхес тәрбияләү.

Алда әйтеп үтелгән бурычларны тормышка ашыру өчен уку грамоталылыгын үстерүгә юнәлдерелгән технологияләр һәм алымнар сайлап алырга тырыштым. Шулай ук алар укучыларның эшчәнлеген активлаштыруга, хезмәттәшлеккә нигезләнгән. Болар:

– интерактив технологияләр;

– аңлап уку технологиясе;

– критик фикерләүне үстерү технологиясе;

– проблемалы укыту технологиясе.

Эшнең нигезе итеп аңлап уку технологиясен алам, ул текст белән эшләүнең өч этабын үз эченә ала:

**I этап.** Укуга кадәр текст белән эшләү.

**II этап.** Уку вакытында текст белән эшләү.

**III этап.** Укудан соң текст белән эшләү.

Дәресләрне кызыклы, нәтиҗәле итү максатыннан төрле алымнар кулланам. Бу юлы аңлап уку технологиясенә караган түбәндәге алымнарга тукталасым килә. Аларны дәреснең төрле этапларында кулланырга мөмкин:

1. «Ышанасызмы?» алымы.
2. «Мозаика» алымы.
3. «Тәрәзәле язу» алымы.

Татар теле дәресләрендә укучыларны активлаштыру өчен, бу метод һәм алымнарны отышлы дип саныйм.

**Төп өлеш**

«**Ышанасызмы?» алымы**

– Дәрес 45 минут дәвам итә. Ышанасызмы?

– Мәктәп балаларсыз яши ала. Ышанасызмы?

– Укытучылар һәрвакыт яңа идеяләр эзли. Ышанасызмы?

– Мастер-класстан сез үзегезгә файдалы мәгълүмат аласыз. Ышанасызмы?

– Текст белән эшләү баланың тел (сөйләм) үсешенә тәэсир итми. Ышанасызмы?

– Уку камиллеген формалаштыру укучыларның белемнәрен һәм мөмкинлекләрен киңәйтүдә роль уйнамый. Ышанасызмы?

– Мин дә ышанмыйм. Хөрмәтле хезмәттәшләр, нинди алым кулландым мин?

– Бүген без яңа әсәр белән танышырбыз. Ышанасызмы?

– Төп герой өч малай булыр. Ышанасызмы?

– Кыз гөберле бакага әверелер. Ышанасызмы?

– Мин «Сез ышанасызмы?» алымын текстны укыр алдыннан файдаландым. Бу алымны текстны укыр алдыннан куллануның төп максаты – укучыларда текстның эчтәлеген фаразлау сәләтен, осталыгын үстерү.

Әлеге сорауларны **текст белән танышыр алдыннан** һәм **текстны укыгач** та бирергә мөмкин. *(Алынган нәтиҗәләр чагыштырыла һәм йомгак ясала.)*

– Без бүген «Өч кыз» татар халык әкиятен тикшерербез. Бу әкият барыбызга да таныш дип уйлыйм. Искә төшереп үтик дисәгез, каршыгызда битләр ята.

– Һәрберегез әкият буенча берәр сорау әзерли. Аңлашылганча, сорауларга ышанырга да, ышанмаска да мөмкин. *(Җавапларны тыңлап үтү.)*

– Бу биремне **текстны укыганнан** соң үтәргә мөмкин:

1. Әлеге алым укучыларның текстны аңлап укуларын тикшерү өчен, төшенеп бетмәгән урыннарны кабатлау өчен файдалы.
2. Эзләнү күнекмәсен булдыра.
3. Шулай ук төрле фактларны бердәм картинага бәйләү өчен дә кулланырга мөмкин.
4. Бу алым тәнкыйди фикерләүне дә үстерергә ярдәм итә.

**«Мозаика» алымы**

**–** Бу эшне парларда алып барабыз. Сезнең каршыгыздагы тасмаларда әкияттән җөмләләр бирелгән. Сез аларны әкиятнең эчтәлеге буенча дөрес тәртиптә җыярга тиеш буласыз.

– Тикшерәбез.

– Җавабыгыз дөрес булса, тасмаларны әйләндергәч, салават күпере төсләре чыгачак.Тикшереп үтик әле.

– Картиналар белән эшлибез. Рәсемне җыясыз һәм текстның кайсы өлешенә туры килүен әйтәсез.

– Бу алым хакында текстны реконструкцияләү яки «сүтеп җыю» дип әйтергә мөмкин.

1. Әлеге алым укучыларның текстны аңлауларын тикшерү, уку материалын җиңел үзләштерү өчен кирәк.
2. Эзлеклелекне булдырырга, вакыйгаларны тәртип белән урнаштырырга өйрәтә.
3. Салават күпере төсләренә ябыштырылган җөмләләр логик фикерләүне үстерү өчен дә ярдәм итә. *(Ләкин бу – укучыларга алдан әйтелми.)*
4. 1 нче сыйныфта сюжетлы

рәсемнәр белән эшләү бик отышлы.

**«Тәрәзәле язу» алымы**

– Татар халкының «Өч кыз» әкиятендә төшеп калган сүзләрне язабыз.

*зәңгәр* – эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр;

*кызыл* – предметны белдергән сүзләр;

*сары* – предмет билгесен белдергән сүзләр.

1. Әлеге алым дәрестә текст белән эшләгәндә, алдагы дәрестә үзләштергәнне тикшергәндә һәм яңа материалны өйрәнгәндә отышлы.
2. «Тәрәзәле язу» алымы уйланырга мәҗбүр итә, сүзләрне урынлы файдаланырга этәрә.
3. Сүз байлыгын арттыра.
4. Шулай ук бу алым татар теленең грамматик кагыйдәләрен искә төшерергә һәм ныгытырга ярдәм итә.

**Йомгаклау**

– Алда санап үтелгән барлык алымнар да минем дәресләремдә сыналды.

Диагностика нәтиҗәләре, таблицадан күренгәнчә, уку грамоталылыгының уңай үсеш динамикасын күрсәтә. Бу – уку эшчәнлегендә каралган алымнарны куллануның уңышлы булуы турында сөйли. Дөрес формалашкан уку күнекмәләре – шәхесне алга таба үстерү өчен көчле корал.

Диаграммада да укучыларның регулятив, танып белү, коммуникатив универсаль уку гамәлләренең уңай үсеш динамикасы күренә.

Дәресләрдә күрсәтелгән алымнарны кулланганда, укучыларның фикерләү күнекмәләре формалаша, бу – функциональ грамоталылыкның төп күнекмәсе булып тора.

Шулай итеп, текст һәм мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен үстерү укытучының төп эш юнәлешенә әверелә. Әлеге өлкәдә югары нәтиҗәләргә ирешү өчен бу юнәлештә эш максатчан, системалы һәм өзлексез алып барылырга тиеш.

Бу алымнар укучыларның белем алуга кызыксынуын арттыра, аларның эшкә омтылышын һәм үз-үзенә ышанычын арттыра.

**Рефлексия**

**–** Бу мәгълүматны түбәндәгечә бәяләргә тәкъдим итәм. Мин сезгә «Чемодан», «Иттарткыч», «Кәрзин» дип аталган рефлексия тәкъдим итәм.

– Чатка үз җавабыгызны җибәрегез. *(Шкала.)*

– Сез әлеге мәгълүмат белән нишләрсез, тәкъдим ителгән җавапларның берсен сайлагыз.

– Әгәр сез «Чемодан»ны сайласагыз, мәгълүмат киләчәктә файдалы булачак дип әйтәсез.


– «Иттарткыч» сайласагыз, димәк, сез мәгълүматны эшкәртерсез һәм киләчәктә файдаланырсыз.

– «Кәрзин» – мәгълүматның барысын да ташлыйсыз. Бәялибез!

– Без барлык мәгълүматның «Чемоданга» һәм «Иттарткычка» эләгүен күрәбез. «Кәрзин» буш. Мәгълүмат һәркем өчен файдалы булып чыкты дигән нәтиҗә ясыйбыз.

– Сез дә бу алымнарны үз эшегездә кулланырсыз дип уйлыйм. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

04




# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ

**Гөлназ КАМАЛОВА,**

Мамадыштагы академик К.Вәлиев исемендәге 2 нче лицейның югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Бүген укытучыдан күп нәрсә таләп ителә: үз фәнеңне бик яхшы белү, балаларны яратудан тыш, аларның фикерләү сәләтен үстерү, уку-танып белү эшчәнлеген оештыру, рухи һәм физик үсешен тәэмин итү. Ә моның өчен укытучыдан үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, заман сулышын тоеп, белемне өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшләү сорала. Заман таләбе буенча, укучыларның компьютер технологияләренә булган кызыксынуларын истә тотып, «Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проектын тормышка ашыру өстендә эшлим. Проект эшемне академик Ә.Хуҗиәхмәтовның «Педагогик технологияләр» исемле фәнни эшенә нигезләнеп алып барам.

**Төп максатым**: белем сыйфаты белән идарә итү өчен төрле юллар һәм алымнар кулланып, киләчәктә илнең чын хуҗалары була алырлык белемле, акыллы, сау-сәламәт шәхес тәрбияләү.

**Бурычларым:**

– укучыларның белемгә булган омтылышларын үстерү;

– махсус белем һәм күнекмәләр формалаштыру;

– иҗади эшчәнлекне үстерү мөмкинлеген тудыру;

– укучыларның фикерләү сәләтен үстерү.

**Педагогик проектта катнашучылар:** укытучы, укучылар, ата-аналар.

**Проектны башкару вакыты:** 4 ел.

Ике ел эчендә «Татар теле һәм уку дәресләрендә инновацион технологияләр куллану» проекты буенча эш билгеле бер системага салынды. Ул параллель рәвештә дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш эшләрдә тормышка ашырыла.

Шушы педагогик проект буенча үткәрелгән дәресләр уңай мотивация тудыра. Укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру һәм укучыларда уңай мотивация булдыру өчен төрле эш методлары һәм алымнары кулланып эшлим.

1. Уку материалын аңлатканда:

– сүз белән эшләү методлары (сөйләү, сүзлек эше, әңгәмә һ.б.);

– гамәли методлар (күнегүләр, буклетлар, презентацияләр эшләү, электрон дәреслекләр чыгару кебек методлар) кулланам.

2. Фикерләү, уку эшчәнлеге белән идарә иткәндә исә проблемалы эзләнү методына (проблемалы сорау кую, проблемалы ситуация тудыру, үзаллы, парлы, төркемнәрдә эшләү, фәнни-тикшеренү эшләре) өстенлек бирәм.

Дәрестә дә, өй эше итеп тә эзләнү, тикшеренү, уйлану таләп иткән эшләр бирергә тырышам.

3. Уку эшчәнлеген активлаштыру өчен дәресләрдә эмоциональлеккә ирешү, танып белү уеннары, уңыш ситуациясе булдыру, үзара ярдәм оештыруны отышлы алым дип саныйм.

Эш ике юнәлештә алып барыла: дәрес вакытында халкыбызның телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, күркәм йолаларын, тарихи үткән юлын теоретик яктан тирәнтен өйрәнсәк, сыйныфтан тыш эшләрдә иҗади эзләнү эшенә күбрәк игътибар бирәм. Шул рәвешле, балалар иркен, мөстәкыйль фикер йөртү дәрәҗәсенә ирешә.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне куллануның өстенлекле яклары күп:

– материал югары күрсәтмәле дәрәҗәдә булуы белән отышлы;

– укучының шәхси сыйфатларын ачыкларга мөмкинлек була;

– контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары;

– төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру мөмкинлеге бар;

– укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәреснең эчтәлеген баерак һәм кызыграк итә.

Дәрес үткәргәндә еш кына интерактив тактага мөрәҗәгать итәм, чөнки интерактив такта куллану дәресләрне тагын да мавыктыргыч, нәтиҗәле итә. Төрле темага күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын табарга һәм аларны кат-кат файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә һәм яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.

Яңа стандартлар кертү сәбәпле татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә **проектлар методы**н куллану отышлы, чөнки бу метод **–** укучыларның билгеле бер нәтиҗәгә ирешүен максат итеп куйган ысул. Проектлар методы укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Ул – теге яки бу проблеманы тирәнтен өйрәнү максатында, укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш.

Проект методын куллануның уңай яклары:

1. Тел һәм әдәбият буенча материал белән таныштыру карала.
2. Укучы дәресләрдә төп белем ала, эш төрләре, кагыйдәләр белән таныша.
3. Бу метод кызыксынучанлыкны, һәр яңа эш төрен ихлас, дәртле итеп башкару теләген уята.
4. Проекттагы мәгълүмат һәр дәрестә укучының күз алдында була, кирәк вакытта ул аңа мөрәҗәгать итә ала. Бу исә материалның хәтта йомшак укучылар тарафыннан да үзләштерелүен тәэмин итә.

Күпчелек очракта бу эш төркемнәрдә башкарыла һәм берничә этаптан тора:

**Проект өстендә эш этаплары:**

1. Проект темасын тәкъдим итү. Иҗади эшләрнең тематикасы дәрестә үзләштергән белемнәрне тирәнәйтү, актуальләштерү, гамәлдә куллануны таләп итәрлек итеп сайлана. Мәсьәлә кую.
2. Эш юнәлешен сайлау. Балаларны төркемнәргә бүлү. Мәгълүмат җыю алымнарын сайлау һәм эзләнүне башлау. Беренче нәтиҗәләрне тикшерү.
3. Проектны презентацияләү, бизәү һәм яклау.
4. Йомгаклау, нәтиҗә чыгару.

Проект методикасы куллану түбәндәге бурычларны үти:

– Эш барышы телне өйрәнүгә теләк уята.

– Проект эшен оештыру барышында укучылар үзара аралаша, укытучы тикшерүче ролен түгел, киңәшче ролен үти.

– Укучыны билгеле бер тема өстендә иҗади эшләргә, төрле чыганакларны кулланып, үзаллы мәгълүмат табарга өйрәтә, уку эшчәнлеге активлаша.

– Бөтен уку процессы укучыга юнәлтелә, аның кызыксынуы, тормыш тәҗрибәсе, шәхси сәләтләре искә алына.

Гомумән, проектлау технологиясенең кулланылу даирәсе бик киң, аны дөрес һәм урынлы кулланганда (укытучы үзе кирәкле дип тапканда), укытучыга ышанычлы ярдәмче функциясен үти ала. Ә иң мөһиме шул: схема-проектны һәр дәрестә файдалану үзмаксат түгел, ә проект укучыларның белем алуда активлыгын тәэмин итү, предметка карата кызыксыну уяту, төпле белем бирү чарасы булуын истән чыгарырга ярамый.


Бүгенге көндә мәктәпләрдә төрле предметлардан компьютерлар өчен эшләнгән гамәли укыту программалары бар. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллану өчен дә интерактив дәреслекләр чыгарыла башлады. Миндә видеоматериаллар карауның тәэсирен кабатлауның нәтиҗәле ягы белән берләштерү

теләге туды. Һәм Movie Maker программасына нигезләнеп, «Сайланган сәхнә сынавы» проектын төзедем. Проект өчен 5 – 7 минутлык кыска гына өзек сайлап алына. Балаларга иң якын «Г. Тукай әкиятләре» темасын сайладык. «Кәҗә белән Сарык», «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләре буенча проектыбыз әзер инде. Гомумән, видеоязмалар карауның төрле алымнарын үз эшемдә кулланам. Мәсәлән, 5 – 7 минутлык өзекне алдан карау, аннан тавышны ябып кабатлау барышында укучылардан диалог төзетү яки, киресенчә, рәсемне аерып куеп, тавышка нигезләнеп, әсәрне уйнап күрсәтү. Әсәрнең өзеген карау барышында бирелгән язмадагы бер герой турында репортаж язу һ.б. Сөйләм телен үстерү дәресләрендә куллану өчен презентацион программалар бик кулай. PowerPaint программасында укыган әсәргә иллюстрацияләр эшләргә, принтер аша чыгарып, һәр укучыга таратырга да була. Бу эшләрне дә укучылар бик теләп башкара. М. Җәлил, Г. Тукай, Г. Ибраһимов кебек шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү дәресләре өчен эшләнгән презентацион программаларыбыз да бар.

Әлбәттә, сәләтле балаларга аеруча игътибар итәм. Бу эшнең әһәмияте – шәхеснең перспектив үсешен фаразлауда. Табигать тарафыннан бирелгән иҗат һәм сәләт чаткылары булган балаларны туплау һәм үстерү – төп бурычыбыз.

Мәктәп шартлары миңа дәресләрдә компьютерның мультимедиа мөмкинлекләреннән, видеотехниканы уңышлы кулланырга мөмкинлек бирә. Кабинетым Интернет челтәренә тоташтырылган компьютер, принтер, сканер, медиапроектор белән җиһазландырылган. Ә бу мөмкинлекләр мине даими рәвештә укытуның яңадан-яңа алымнарын эзләргә этәрә. Укытуны интенсивлаштыру өчен тестларны нәтиҗәле кулланам. Укучыларның теманы үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү, белемнәрен бәяләү, ялгышларын ачыклау, аларны анализлау һәм төзәтү юлларын билгеләү өчен тестлар бик уңайлы. Тестны эшләп бетергәч, компьютер, нәтиҗә ясап, билге куя. Укучылар үзләре дә төрле презентацияләр ясыйлар, белемнәрне тикшерү дәресләрендә файдалану өчен Excel, Point программасында тестлар әзерләүдә дә ярдәм күрсәтәләр. Татар теле дәресләре өчен басма күрсәтмә материаллар бик аз, шуңа күрә укучылар, Интернет челтәренә чыгып, татарча сайтлардан төрле кызыклы материаллар бастырып ала.

«Шәкертләрне гыйлем белән тәрбияләү, изге шәригатьтә аңлатылган күркәм холыклар белән таныштыру һәм гадәтләндерү укытучының беренче эше булыр», – дигән Р. Фәхреддин. Бүгенге укучыларның төпле белем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда – балалар язмышы. Укучыларыбыз, Р.Фәхреддин теләгәнчә, бөтен яктан да үрнәк балалар булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.



05

# Ф.ӘМИРХАННЫҢ «АЙ ӨСТЕНДӘГЕ ЗӨҺРӘ КЫЗ» ӘСӘРЕН ОБРАЗЛАР БИРЕЛЕШЕ АША АНАЛИЗЛАУ

**Ләйсән ВӘЛИЕВА,**

Арча районы Иске Чүриле урта мәктәбе-
нең югары квалификация категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**

*Дидактик:* хикәянең эчтәлеген аңлауга ирешү; кирәкле мәгълүматны билгеләү.

*Үстерелешле:* иҗади фикерләү сәләтләрен, игътибарлылыкны үстерү өстендә эшне дәвам иттерү; дәрестә алган белемнәрне кирәкле вакытта куллану.

*Тәрбияви:* мәрхәмәтле, шәфкатьле, ярдәмчел булырга кирәклеген аңларга этәргеч бирү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

*Предмет буенча:* Ф.Әмирханның тормыш юлын белү; әсәрнең образлар системасын билгели, геройларын бәяли алуына ирешү.

*Метапредмет:* баланың әйләнә-тирәне мөстәкыйль бәяли белүенә ирешү.

*Шәхси:* дөньяга гуманлы караш тәрбияләү.

**Универсаль уку гамәлләре формалаштыру**

*Шәхси:* мәрхәмәтле, шәфкатьле, кеше хәленә керә белү сыйфатларын тәрбияләүгә этәргеч бирү.

*Регулятив:* эшчәнлекне планлаштыра, үзалдыңа максат куя белү, нәтиҗә ясау.

*Танып белү*: әдипнең тормышы турында сөйләү, хикәяне аңлап уку һәм кабул итү, тиешле мәгълүматны сайлап ала алу, төп мәгънәне аеру, фикерләрне логик чылбырга салу, образлы фикер йөртә белү күнекмәсен үстерү.

*Коммуникатив:* үз фикереңне җиткерә, башкаларны тыңлый белү, мәгълүматларны таба, куллана алу, туган тел нормаларын саклап сөйләү, әңгәмәдә катнашу.

**Дәрес тибы:** әдәби әсәрне өйрәнү дәресе.

**Ресурслар:** Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. Татар телендә гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа (5–9 нчы сыйныфлар өчен). – Казан, 2013.

Ганиева Ф.А., Сабирова Л.Г. Әдәбият: татар телендә гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014; проектор, компьютер, мультимедиа презентациясе, буклет, Ф.Әмирхан турында өстәмә мәгълүмат, сүзлекчә, тарату материалы, үзбәя карточкасы.

**Эш төрләре**: сыйныф белән эш, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә эш.

**ДӘРЕС БАРЫШЫ**

**I. Дәресне оештыру**

Дәрескә уңай халәт тудыру.

**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Барыбызга да яхшы кәеф һәм уңышлар телим.

**II. Укучылар эшчәнлеген мотивлаштыру**

**Укытучы.** Балалар, сез табышмакларга җавап табарга яратасызмы? Тыңлагыз әле, мин сезгә табышмак әйтәм. Беренчесе:

Ярты икмәк, туп, урак,
Торган җире бик ерак. *(Ай)*

**Укытучы.** Укучылар, сезнең айга игътибар иткәнегез бармы? Нинди ул ай, нәрсәгә охшаган? Гел бертөрле генә буламы? **(1 нче слайд)**

Икенче табышмак:
Төнлә баксам, күк тулган,
Иртән баксам, юк булган.

**Укучылар.** Йолдыз. *(Экранда чыга.)*

**Укытучы.** Укучылар, карагыз әле, бу кем? *(Экранда чыга.)* Нинди әсәрләр күз алдыгызга килде? *(Укучылар җавап бирергә кыенсына.)*

– Ә без бүгенге дәрестә кайсы әсәр турында сөйләшербез? Авторы кем, балалар? *(Ф.Әмирханның «Ай өстендәге Зөһрә*

*кыз» әсәре хакында.)*

– Әйе, сез бу әсәрне өйдә укып килдегез. Әйдәгез, фаразлыйк әле: бүгенге дәрестә әлеге хикәяне анализлау барышында без нәрсәләр эшләрбез? *(Язучының тормыш юлы турында кабатларбыз, хикәянең эчтәлеген искә төшерербез, образлар, аларга хас сыйфатлар һәм аларның башкарган эш-гамәлләренә бәя бирербез.)*

– Ни өчен кирәк булыр соң ул безгә? *(Авторның безгә нәрсә әйтергә теләгәнен белү өчен.)*

– Димәк, бүгенге дәрестә безнең төп максатыбыз нинди? *(Автор позициясен табу.)*

– Сезнең өстәлләрегездә бәяләү карточкалары бар, һәр эшчәнлектән соң шул битләргә билге куеп барырга кирәк булачак. **(1 нче кушымта)**

– Өй эшләрен тикшереп алыйк. Ф.Әмирхан турында нәрсәләр исегездә калды икән? Әлеге эшне без төркемнәрдә башкарырбыз. **(2 нче кушымта)**

| Еллар | Вакыйгалар |
|---|---|
| | Ф.Әмирхан … Яңа Татар бистәсендә мулла гаиләсендә туа. |
| 1895 – 1905 | … мәдрәсәсендә, дин сабакларыннан тыш, дөньяви фәннәрне, Көнчыгыш классик әдәбиятын үзләштерә. |
| | Самарага китеп русча белемен тирәнәйтеп кайта. |
| 1907 | … кайта. |
| | … авыруыннан вафат була. |

**Укытучы.** Укучылар, үз белемнәребезне бәялибез. *(**3 нче слайд** ярдәмендә тикшерү.)*

– Әйе, укучылар, Ф.Әмирхан – көчле ихтыярлы шәхес. Сезнең өстәлләрегездә һәрберегез алдында да буклетлар бар. **(3 нче кушымта)** Беренче битендә Ф.Әмирханның бала чагы турында кызыклы мәгълүматлар бирелде. Өйдә әйбәтләп танышырсыз, бирелгән сайт аша да бик күп өстәмә мәгълүматлар белә аласыз.

**III. Яңа материалны үзләштерү**

**Укытучы.** Укучылар, әсәрне сез өйдә укып килдегез, шулай бит. Сүзлек өстендә дә эшләдегез. Әгәр аңлашылмаган сүзләр очраса, өстәлләрегездә сүзлекчәләр бар, карый аласыз. **(4 нче кушымта)** Әсәрнең эчтәлеген искә төшерик әле. Әйдәгез, бер уен уйныйк. «Дәвам ит» дип атала ул. Мин әйтә башлыйм, сез дәвам итәрсез. Күктәге матур, якты ай барысын да күреп торган… *(Укучылар дәвам итә.)* Берәр генә җөмлә әйтәбез, ахырын укучы йомгаклап куя, аңладыгызмы, балалар? *(Укучылар сөйли.)*

– Димәк, без план рәвешендә генә әсәр эчтәлеген сөйләп чыктык. Буклетларыгызның икенче битендә «Син игътибарлымы?» биреме бар. Анда мин хикәягә план биргән идем, тик бераз буталганмын. Миңа хатамны төзәтергә булышасызмы, балалар? Бу биремне һәркем аерым эшләр.

– Укучылар, үз эшчәнлегебезне бәялибез. *(**5 нче слайд** ярдәмендә тикшерү.)*

– Укучылар, без вакыйгаларны барлап чыктык. Хәзер нишләрбез? Буклетларыгызның 2 нче битен ачыгыз әле.

– Нинди образлар белән таныштыгыз? *(Ай, Зөһрә, үги әни, йолдыз, хикәяләүче.)*

– Хикәя кем исеменнән сөйләнә? *(Автор.)*

– Автор кайсы образны үзәккә куеп

сурәтли? Вакыйгалар кем тирәсендә туплана? *(Зөһрә.)*

– Димәк, укучылар, Зөһрә нинди герой була инде? *(Төп герой.)* Зөһрә турында нәрсә әйтә аласыз? Аның матурлыгы текстта ничек бирелә? *(Табып укыту.)*

– Аңа нинди сыйфатлар хас? Аның тышкы матурлыгы белән эчке дөньясы туры киләме? *(Укучылар фикерен тыңлау.)*

– Буклетларның икенче битен ачыгыз әле. Анда схема бирелгән. Сөйләшү барышында әлеге схеманы тулыландырып барырбыз. Димәк, Зөһрәне кая язарбыз? *(Уртага.)* Анда кайсысына язарбыз? Укучылар, карагыз әле, уртада ак турыпочмак та бар, карасы да.

– Әйе, Зөһрә – чиста күңелле, яхшы кыз, шуңа аны ак турыпочмакка язарбыз.

– Зөһрә образы аша Ф.Әмирхан нәрсә әйтергә теләде икән?

– Зөһрәнең матурлыгы кинәт кенә ничек үзгәрә, укучылар? *(Көннән-көн кипкән, сулган...) (Тексттан таптырып укыту.)*

– Сәбәбе нидә соң? *(Чөнки үги әни аны кыйный, җәберли, караңгы бүлмәгә ябып куеп, көннәр буе ач тота, төпсез кисмәккә су ташыта.)*

– Укучылар, схеманы тутыруны дәвам иттерәбез. Үги әни образын кайсы баганага язарсыз? Ни өчен? *(Чөнки ул начар гамәлләр кылган. Шуңа күрә без аны көрән схемага язарбыз.)*

– Укучылар, ул Зөһрәне нишләп җәберли соң? Берәр сәбәбе юкмы? *(Көнләшү.)* Нәрсәдән көнләшә соң ул? *(Зөһрәнең матурлыгыннан.)* Ни өчен? *(Чөнки аның үз кызы ямьсез була.)*

– Балалар, Зөһрәнең кичерешләре турында нәрсә әйтә аласыз? Сез Зөһрәне кызганасызмы соң? Аңа ничек ярдәм итәр идегез?

– Укучылар, әйдәгез, үзебезнең әниләребез турында сөйләшеп алыйк әле. Безнең әниләребез нинди? *(Укучыларның җаваплары тыңланыла.)*

– Димәк, әниләр яхшы күңелле, мәрхәмәтле, ярдәмчел була, безгә гел яхшылык кына телиләр. Әйе, укучылар, безнең тирә-ягыбызда балалар йортларыннан бала алып тәрбияләп үстергән олы йөрәкле әниләр күп. Алар – бар күңел җылысын, назын сабыйларга бирүче үги әниләр. Аларны балалары да ярата, әни дип өзелеп торалар. Сез, балалар, бик бәхетле, чөнки сезнең мәрхәмәтле, ярдәмчел әниләрегез бар. Димәк, укучылар, нинди нәтиҗә ясыйбыз? *(Начар холыклы, мәрхәмәтсез булырга ярамый.)*

– Ә нинди булырга кирәк? *(Бер-беребезгә мәрхәмәтле, шәфкатьле булырга кирәк.)*

– Балалар, сез үзегезгә үрнәк итеп кемнең сыйфатларын алырсыз, Зөһрәнекенме, әллә инде үги әнинекенме? Тагын үрнәк алырлык образлар бармы, укучылар? Нинди образлар бу? *(Ай һәм йолдыз.)*

**Ял минуты** ***(7 нче слайд,*** *видео куела, видеода йолдызлар, сыйныфта да төрле төстәге утлар кабына.)*

**Укытучы.** Укучылар, карагыз әле, нинди серле күк йөзе, нинди генә йолдызлар юк. Әйдәгез, шул йолдызларга үрелик әле. Алар өстә, бик өстә. Тагын, тагын да югарырак үреләбез.

– Укучылар, карагыз әле, йолдыз атыла түгелме? Йолдызлар атылганда нишлиләр, укучылар? *(Теләк телиләр.)* Әйдәгез, җирдәге йолдызларны сак кына

алыйк та, матур теләк теләп, аны кире күккә җибәрик! *(Укучылар теләкләрне кычкырып әйтә.)*

– Укучылар, без мәрхәмәтле, шәфкатьле образлар турында сөйләшә идек. Кайсы образлар әле бу? Тыңлагыз әле, ай образы аша автор безгә нидер әйтергә тели. *(Ф. Җиһанша башкаруында тыңлау.* ***8 нче слайд****та өч язма да бирелгән.)*

– Әнә шул тулган айга карагыз әле. Ул шундый түгәрәк, шундый тулы һәм якты. Ләкин аның яктысында әллә нинди бер моң, уйчанлык, кайгы бар. Нинди кайгы икән ул, укучылар? *(Укучылар фикерен тыңлау.)*

– Димәк, җирдәге гаделсезлекне күреп, табигать тә кайгыра, борчыла. Беләсезме, борын-борын заманнарда аның яктысы болай моңлы, уйчан булмаган. Кешеләрнең йөрәкләренә, җаннарына авырлык салмаган. Автор нәрсә әйтергә тели, укучылар? *(Элек кешеләр мәрхәмәтлерәк, әйбәтрәк булганнар, хәзер бу сыйфатлар кимебрәк бара дип әйтергә тели.)*

– Без моны төзәтә алабызмы, укучылар? Ничек итеп? *(Укучылар фикерен тыңлау.)*

– Әйе, бер-беребезгә мәрхәмәтле булсак, яхшылыклар гына эшләп торсак, дусларыбыз да яхшылык эшләячәк, аннары аларның дуслары. Шулай итеп, бу яхшы сыйфатларга ия кешеләр тагын да артачак, шулай бит, укучылар.

– Дәвам итәбез. *(**8 нче слайд**, икенче язма.)* Беләсезме, ул ай бик карт бит инде. Ул безнең бабаларыбызны гына түгел, аларның бабаларының, бабаларының… бабаларын да күргән, үзенең биек урыныннан аларның ниләр эшләгәнен, ниләр төзегәнен, ниләр бозганнарын – һәммәсен-һәммәсен карап торган. Бабаларның бабаларын да, безне дә күргәч, ул нәрсә була инде? *(Укучылар фаразлавын тыңлау.)*

– Димәк, ай ул – бүгенге белән үткәнне тоташтыручы да. Әйе, укучылар, кешедә булырга тиешле матур, яхшы сыйфатлар буыннан-буынга күчә барырга тиеш. Ай безне гел күзәтеп торачак.

– Сез ай һәм йолдызны кая язарсыз? Ни өчен? Алар нинди яхшылык эшләделәр соң? *(Ай кызга ярдәм итә, су алганда чиләген җиңеләйтә, елмаеп-көлеп, аның хәсрәтен киметергә тели. Йолдыз аны җирдән күккә менгерә.)*

– Бу нинди йолдыз? *(Зөһрә йолдыз.)*

– Йолдыз турында әсәрдә нинди мәгълүмат бар? Табып укыйк әле. *(Тексттан табып уку.)*

**«Ай өстендәге Зөһрә кыз» әсәреннән өзек**

Кич караңгы, тулган ай болыт астында икән. Үксез кыз чиләген суга чумдырган да тартып ала алмаган. Аның ябык кулларында, арык гәүдәсендә инде анлык көч калмаган икән. Бер тарткан, тагы бер тарткан, тагы бер тартып караган, чиләкне күтәрә алмаган. Кичнең моңлы караңгысы белән күгелҗем-кара төскә кергән елга суы, акрын гына селкенеп, җиңелчә генә дулкынланып киткән, түгәрәкләнеп җыерчыкланган, ләкин чиләкне җибәрмәгән.

Бу арада болытлар арасыннан ай чыккан да, бөтен түгәрәк йөзе белән елмаеп, шаян вә шат балкып тора һәм җир йөзенә нур коя башлаган. Аның яктысы белән елга да көлеп җибәргән. Күгелҗем-кара төсен көмеш сыманга әйләндергән. Ләкин кызның чиләген ычкындырмаган.

– Ай! – дип, үксез кыз елап арыган

күзләрен күккә күтәргән. – Ай, синең өстеңдә үги аналар балаларыннан төпсез кисмәкләргә су ташыталармы? Синең өстеңдә бу газаплар, бу җәфалар бармы? Булмаса, ал мине үз өстеңә! – дигән дә, ярдәм көтеп һәм матурлыгына, нурына, шатлыгына сокланып, айга караган.

Менә шул минутта кинәт аның чиләге җиңеләеп киткән дә ул аны бер дә мәшәкатьсез генә судан тартып чыгарган. Икенче чиләген суга чумдырган, анысы да мәшәкатьсез алынган. Чиләкләр һәр икесе туп-тулы су икән. Боларның шулкадәр тулылыгын күреп, үксез кыз, өметсезләнеп: «Ничек күтәреп кайтам инде мин боларны?» – дип уйлаган һәм ярдәм көткән, хәл сораган шикелле итеп, арыган-талган, өметсез, күңелсезләнгән күзләрен янәдан айга күтәргән дә:

– Ничек күтәреп кайтам инде мин боларны? – дигән.

Ай җавап бирмичә генә ялтырап тора, көлә, елкылдый, һавада шома вә тигез генә йөзә икән. Үксез кыз бик озак аңар карап торган. Аның матурлыгы, аның шат елкылдавы белән үз-үзен, үзенең уңайсыз хәлен онытып карап торган да, үзе дә сизмичә, чиләкләрен күтәреп кайтырга чыккан. Адымнар әллә ничек гаҗәп җиңел атланалар, гәүдә очкан төсле үзеннән-үзе бара, чиләкләр җилтериләр генә икән.

Шулай итеп очынып, шактый вакытлар Зөһрә кыз, үз-үзен онытып, бернәрсә дә уйламыйча барган. Аннан соң аның исенә өендәге төпсез кисмәк һәм үги анасының аны таңга хәтле тутырып бетерергә кушуы төшкән. Аның йөрәге жуылдап киткән. Хәлсез вә өметсез сызланган. Аның арыган-талган күзләренә янәдан яшь килеп тыгылган.

«Ул төпсез кисмәкне таңга хәтле генә түгел, кыямәткә хәтле су ташысаң да тутырып булмый бит инде», – дип калтыранып, уйланып, ул айдан ярдәм сорар өчен, яшьле күзләрен күккә күтәргән икән – аптырап киткән: ай белән үз арасында гаҗәеп матур бер йолдыз күргән. Йолдыз җем-җем итә, Зөһрә кызны үз өстенә суыра икән. Үксез кыз да, үз ихтыярыннан башка, янәдан бер-ике адым атлаган да йолдыз өстендә булган.

Йолдыз, яшен ташы җитезлеге белән атылып, Зөһрә кызны айга илтеп тапшырган да үзе күкнең иң күренә торган бер җиренә барып урнашкан. Үксез татар кызын айга илткән өчен, Ходай Тәгалә аның нурын арттырган һәм фәрештәләр аңар Зөһрә йолдызы дип исем биргәннәр.

– Сезнең аяз күккә карап торганыгыз бармы? Нинди йолдызлар күргәнегез бар? Әйләнә-тирә дөнья дәресләрендә нинди йолдызлар турында белдегез? Кояшның да йолдыз икәнен белә идегезме? Ул – иң кечкенә йолдыз. Нишләп кечкенә? Бүтән йолдызлар бик зур, укучылар. Нишләп алар бик вак булып күренә? Чөнки алар бездән бик ерак урнашкан. Йолдызлар дөньясы бик серле ул. Аларны өйрәнә торган фән ничек атала, беләсезме? *(Астрономия.)*

**IV. Белемнәрне ныгыту**

**Укытучы.** Әле генә анализлап киткән хикәянең сюжеты сез алдагы дәресләрдә укыган кайсы әсәрләрне хәтерләтте? Алар арасында нинди уртаклык бар? *(«Зөһрә кыз» легендасын, «Үги кыз» әкиятен.)*

– Әйе, укучылар, без укыган «Ай өстендәге Зөһрә кыз» әсәренең нигезендә нәкъ шушы легенда һәм әкият ята. Ф.Әмирхан әкияти вакыйгалар, хәлләр турында автор сөйләмендә эзлекле тәр-

типтә хикәяли. Шуңа күрә бу әсәргә хикәя жанрының сыйфатлары хас.

– Укучылар, образларга тагын бер кат әйләнеп кайтыйк әле. Әлеге образларның һәрберсе нәрсә дә булса әйтергә теләде, һәм дәрес барышында без ул фикерләрне билгеләп бардык. Әйдәгез әле, белемнәребезне гомумиләштерик. Димәк, автор бу хикәясе белән нәрсә әйтергә тели? Ни өчен Зөһрә кыз ай өстендә? *(Укучылар җавабы.)*

– Әсәр бүгенге көндә дә әһәмиятлеме? Сез дә автор белән килешәсезме? Язучы булсагыз, сез әсәрне ничек тәмамлар идегез? *(Укучылар җавабын тыңлау.)*

– Әйе, кеше бу дөньяга яхшы гамәлләр кылыр өчен туа. Һәрберебез дә, мәрхәмәтле, шәфкатьле булып, яхшылыклар гына кылып яшик. Сезнең үзегезнең яхшылык эшләгәнегез бармы? *(Укучылар җавабы.)*

– Укучылар, сез мәкальләр беләсезме? Яхшылык, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек турында нинди мәкальләр беләсез? *(Укучылар җавабы.)*

– Буклетларыгызны ачыгыз әле. Анда да мәкальләр бирелгән. Сезгә шулар арасыннан без укыган әсәр эчтәлегенә туры килгәннәрен билгеләп чыгарга кирәк. Бу эшне без төркемнәрдә эшләрбез, төркемнән бер укучы аңлатып китәр.

– Укучылар, шушы мәкальләр арасыннан кайсы мәкальне бүгенге дәреснең девизы итеп алыр идегез? Ни өчен? *(Укучылар җавабы.)*

**V. Өй эше**

**Укытучы.** Укучылар, менә без дәрестә Ф.Әмирхан иҗаты һәм аның «Ай өстендәге Зөһрә кыз» әсәре буенча проект эше эшли башладык. Өйдә сез аны дәвам иттерерсез. Өй эшләрегез буклетта бирелгән. Өч төрле өй эше. Үзегез теләгән өй эшен сайлап эшләп килерсез.

1. Бирелгән план буенча хикәянең эчтәлеген сөйләгез.
2. Образларга чагыштырма характеристика бирегез.
3. Хикәянең үзегезгә ошаган өлешенә рәсем ясагыз.

**VI. Үзбәя**

– Укучылар, бәяләү кәгазьләренә карап, бүгенге дәрестә үз эшчәнлегегезгә бәя биреп карагыз әле. Үзегезгә нинди билгеләр куярсыз икән, ни өчен?

**VII. Рефлексия**

**Укытучы.** Укучылар, әйдәгез әле, бүгенге дәресебезгә нәтиҗә ясыйк. Безгә менә бу серле куб ярдәм итәр. Сез шушы кубны өскә чөясез һәм тотып алабыз. Кайсы як өскә чыга, сез шул җөмләне дәвам иттерерсез.

– Мин дәрестә ... белдем.
– Мин дәрестә ... аңладым.
– Мин дәрестә ... өйрәндем.
– Миңа дәрестә ... ошады.
– Миңа дәрестә ... кызык булды.

– Укучылар, тулган айга озак итеп карап торсагыз, чыннан да, чиләк-көянтә тоткан кызны күрергә була. Бүген дә ул өстән безнең эш-гамәлләребезне күзәтеп тора. Бүгенге дәресебезне Фәнис абый Яруллин шигыре белән тәмамлыйсым килә:- Ходай безне яраткан,// Төрле җиргә таралткан.// Акыл биргән, тел биргән,// Иман биргән, дин биргән.// Кояш биргән, Ай биргән,// Җир дигән зур табынга// Нигъмәтләрен бай биргән.// Эшләр өчен кул биргән,// Сайлар өчен юл биргән.// Килгән кадәр кулыңнан// Яхшылыклар кыл дигән.

Әйдәгез әле, кулларны кулга тотышыйк та яхшы гамәлләр генә кылып яшәргә сүз куешыйк.

06




# ТЕЛЕБЕЗ НИЧЕК БОЗЫЛА?

**Рүзәл ЮСУПОВ,**

Казан федераль университетының атказанган профессоры, академик

Бу язмада сөйләнәчәк сүзем туган телебезнең хәле, тәгаенләп әйткәндә, телебезне куллануда күпсанлы тупас хаталар хөкем сөрүе, аларның барлыкка килү сәбәпләре һәм аларны булдырмау чаралары турында. Мин туган телебезнең кулланылу таләпләре, хаталарга анализ ясау, дөрес сөйләргә һәм язарга киңәшләр бирү, телебезнең табигыйлеген саклауның, аны иркен куллануның гаять әһәмиятле икәнлеге һәм башка мәсьәләләр белән алты дистә ел шөгыльләнәм, аларны игълан итеп, матбугатта йөзләрчә мәкаләләр бастырдым, дистәләрчә китаплар чыгардым (студент чагында ук язылган «*Төгәлсезлекләр күңелне борчый*» дигән мәкаләм 1964 елда «*Социалистик Татарстан*» газетасында басылган иде). Тик иң гаҗәбе шул: ярты гасырдан артык вакыт узып, бу хакта күп сөйләшүләр һәм язулар булуга карамастан, бүгенге мәгълүмат чараларында (матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында), кайбер китапларда, сөйләмдә телне бозып куллану күренешләре бетмәде һәм хәтта кимемәде генә түгел, киресенчә, соңгы елларда арта гына бара. Хәзер телебезнең бозыла баруы халәтенең җитди төс алуын гыйбрәтле мисаллар белән раслап, бу галәмәтнең асылы, табигате, барлыкка килүе һәм аннан арыну юллары хакында фараз кылырбыз.

Телебезне бозып куллану күренешләренең ифрат күпсанлы булуын истә тотып, укучыларны ялыктырмас өчен, аларның аеруча киң таралганнарының кайберләрен генә күрсәтү белән чикләнергә туры килер.

Кайбер каләм ияләренең тел чараларын дөрес кулланмавы аркасында, сөйләмнең, текстның эчтәлеген аңлау кыенлаша, белдерелергә тиешле мәгънә бозыла. Кайбер әйтелмәләрнең һәм сүзләрнең мәгънәләрен автор үзе дә дөрес итеп аңлатып бирә алмаслык язмалар аз түгел. Хәзер күп журналистлар бик яратып куллана торган *кыйммәт* сүзен анализлыйк. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *кыйммәт* – 1. Югары бәяле, зур бәяле; югары (бәя турында) (мәсәлән: әйбер бәясе кыйммәт; ул товарны кыйммәт сата). 2. Билгеле бер әһәмияткә ия булу, нәрсәнең дә булса әһәмияте, мөмкинлеге. *Кыйммәт*нең синонимы – *кыйбат*. Димәк, *кыйммәт* сүзенең төп, туры мәгънәләре – *югары бәяле* (бәһале), *әһәмиятле, мөһим*. Шул ук вакытта ул *хәзинә*, *байлык* дигән күчерелмә мәгънәләргә дә ия (мәсәлән, *рухи байлыклар* яки *хәзинәләр*, *матди байлыклар, культура хәзинәләре*). Ләкин кайчандыр кемнәрдер рус телендәге *ценность* сүзен *кыйммәт* дип ялгыш тәрҗемә иткән дә, шушы ялгыш бүгенге көндә чәчәк ата һәм күп аңлаешсыз, мәгънәсез әйтелмә-тәгъбирләр куллануга сәбәпче була. *Кыйммәт* русча *ценность* түгел, *ценный, ценно, дорого*. Хәзер исә безнең каләм ияләре, русчадагы *ценность* сүзен уйлап тормыйча гына

тәрҗемә итеп, һәр очракта да *кыйммәт* сүзен кулланалар. Алар һәр телдә сүзләрнең дә, нигездә, күп мәгънәле булуын һәм, төрле тел сүзләре бер-берсенә барлык мәгънәләрендә дә туры килмәгәнлектән, тәрҗемә иткәндә оригинал сүзгә тәңгәллекне аның конкрет сөйләмдә, текстта белдергән мәгънәсен генә исәпкә алып билгеләргә мөмкин һәм кирәк дигән иң мөһим кагыйдәне белмиләр яки исләрендә тотмыйлар, һәрвакытта да, һәр очракта да оригинал сүзнең иң күп кулланылыштагы мәгънәсенә туры килгән, ике тел сүзлекләрендә теркәлгән тәңгәллеге (тәңгәллекләре) белән генә эш итәләр. Бу – бүгенге көндә татар телендә хөкем сөргән күп ялгышларга китергән иң зур бәла.

Журналистларны да, тел белән эш итүче башка һөнәр ияләрен дә саташтыра торган тагын бер хәл: аларның күбесе рус телендәге һәр сүзне татарчага аерым сүз аша тәрҗемә итәргә кирәк дигән ялгыш фикер белән эш итәләр. Тәрҗемәдә оригиналның җөмләсендәге һәм сүзтезмә-тәгъбирләрендәге эчтәлекне, мәгънәне тәрҗемә теленең тиешле сүзләре белән бөтен килеш белдерергә кирәк. Болай эшләгәндә, тәрҗемә телендә оригиналның кайсыдыр сүзләренә аерым гына тәңгәллекләр булмаска да, ягъни кайбер сүзләре аерым сүзләр белән тәрҗемә ителмәскә дә мөмкин. Безнең каләм ияләре исә оригиналның һәр сүзен аерым сүз белән тәрҗемә итәргә тырышалар. Нәтиҗә еш кына аяныч булып чыга. Без әле сөйләгән *кыйммәт* сүзе дә күп очракта шулай ялгыш эшләү нәтиҗәсендә шундый язмышка дучар була.

«*Тормышта барысы да гаилә тәрбиясенә бәйле. Гаилә – төп кыйммәт*», – дип яза иң абруйлы булырга тиешле газета. Беренчедән, бар нәрсә дә гаилә тәрбиясенә генә бәйле, дип әйтү бик үк дөрес түгелдер: башка факторлар да бар бит. Икенчедән, «*Гаилә – төп кыйммәт*» дигән җөмләне ничек аңларга? Нәрсә ул *төп кыйммәт*? Аны саф татарча «*Гаилә – иң әһәмиятле нәрсә*» кебегрәк итеп әйтергә буладыр. Менә бу җөмләдәге *гаилә кыйммәтләре*н нәрсә дип аңларга: «Хөкүмәттә *гаилә кыйммәтләрен ныгыту* ... чаралары карала». Аны «...*гаиләне ныгыту*», «*гаиләнең нигезен ныгыту*» яки башкача шулайрак дип, адәм аңларлык итеп язарга булмыймы?! «Ә сугышта башка кыйммәтләр» дип яза шул ук газета. Моны «Сугышта исә башкача (була)» кебегрәк итеп, саф татарча әйтергә мөмкин. *«Рухи кыйммәтләрне* саклау мәсьәләсендә...» (дөресе: «*Рухи хәзинәләрне* саклау мәсьәләсендә...») Мондый «*бәһасез*», мәгънәсез «*кыйммәтләр»* күп очрый хәзерге мәгълүмат чараларында.

«Өендә хайваннар тотучылар җанварларын теркәргә тиеш». Бу җөмләнең авторы *җанвар* сүзенең мәгънәсен белеп бетермәгән, күрәсең: өйдә җанвар тоту бик үк табигый күренеш түгелдер бит. Татарча әйбәтрәк белсә, ул *тереклек ияләре* сүзен кулланган булыр иде, бәлки.

«Авыл һәм район *җирлекләрендә* урын алган җыеннарда...» Беренчедән, бу фразада, башка бик күп очраклардагы кебек, *җирлек* сүзе ялгыш кулланылган:

татар газетасында эшләгән кеше *җирлек* белән *җир* сүзләренең мәгънәләрен, алар арасындагы аерманы яхшы белергә тиеш, ә безнең каләм әһелләре еш кына *җир* сүзе урынына *җирлек* сүзен кулланалар (кайчакта «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә күз салу да зыян итмәс иде). Икенчедән, район җиренә авыл җирләре дә керәдер бит инде. Әйтелмәне «авылларда һәм район үзәкләрендә узган җыеннарда» дип төзергә кирәк булгандыр.

«...1 апрельдән 30 ына кадәр авыр йөк машиналары хәрәкәте чикләнә». Бу җөмләдәге *йөк машиналары хәрәкәте* – русчадагы *движение грузовых автомобилей* сүтезмәсенең ялгыш тәрҗемәсе: *машина хәрәкәте* саф татарча түгел: *машина йөрү* яки *йөреше*. Каләм иясе, *движение* мәгънәләренең татарча, сөйләмгә карап, *хәрәкәт* һәм *йөрү* сүзләре белән белдерелергә тиешлеге турында белмичә яки уйлап та тормыйча, һәр очракта *хәрәкәт* сүзен куллана. Җөмлә «...йөк машиналарын йөртү яки йөк машиналары йөреше чикләнә» рәвешендә төзелергә тиеш була.

Соңгы вакытларда татарча мәгълүмат чараларында *сылтау* сүзенең һәм шул фигыльдән ясалган *сылтама* исем сүзенең мәгънәләрен тупас бозып куллану күренеше киң таралды. Мәсәлән: «РИА Новости «Waschington Post» басмасына сылтап язуынча...» «Бу хакта ... прокуратура хәбәренә сылтама ясап яза». Бу җөмләләрдә сүз газетага һәм прокуратура хәбәренә таянып яки нигезләнеп язу турында бара, һәм аларны «...басмасына нигезләнеп язуынча...», «...прокуратура хәбәренә таянып яза» рәвешендә төзергә кирәк иде. Хәлбуки аларда тиешле мәгънә бөтенләй бирелмәгән. *Сылтау* ул чын татарча «Берәр эшләнмәгән эшне, гадәттә тискәре, тыелган гамәлне эшләгән дип күрсәтергә маташу (мәсәлән, «гаебен бүтәннәргә сылтап калдырырга маташучы») һәм «аклану өчен китерелә торган нигезсез сәбәп» (мәсәлән, «бәйләнергә сылтау эзләү»). Татар телендә *сылтама* дигән исем сүз бөтенләй юк, «гаебеңне яки ялгышуыңны башка кешегә сылтама» дигәндәге *сылтама* фигыль сүзе генә бар. Русча-татарча сүзлектәге *ссылка – сылтама* дигән мәгълүмат ялгыш бирелгән. Димәк, сүзлекләрдә дә ялгышлар булырга мөмкин һәм бар: ялгышлар бигрәк тә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә шактый еш очрый. Сәбәбе: төзүчеләр кайбер урыннарда матбугаттагы русчадан ялгыш калькалаштырып алынган уңышсыз мисалларга таянганнар.

Татар теленнән сабак алган кешеләр хәтерлидер: сөйләмдә сүзләр бер-берсе белән мәгънәви бәйләнешкә керәләр. Ләкин теләсә нинди сүз башка теләсә кайсы сүз белән бәйләнешкә керә алмый, алар үзара мәгънәле мөнәсәбәткә билгеле бер тәртиптә, сөйләм нормасы нигезендә генә керәләр. Мәсәлән, *тыйнак кеше* дип әйтеп була, ләкин *тыйнак йорт* дип әйтелми. Бу мәсьәләдә ике тел белән эш итүчеләр өчен бер бик әһәмиятле нәрсәне белү зарур: бер телдәге үзара табигый мәгънә мөнәсәбәтендәге сүзләрнең икенче телдәге тәңгәллекләре тәрҗемә телендә

бер очракта, оригиналдагы кебек, табигый мәгънә бәйләнешендә була ала, икенче очракта оригиналда табигый бәйләнештәге сүзләрнең тәңгәллекләре андый бәйләнештә тора алмый. Мәсәлән, русча *работа* белән *диссертация* табигый бәйләнешкә керә (*работа над диссертацией*), татар телендә исә аларның тәңгәлекләре оригиналдагы кебек бәйләнешкә керә алмый: татарча *диссертация өстендә эшләү* дөрес булмый, *диссертация язу* яки *диссертация язарга әзерләнү* (*диссертация язарга материал туплау* һ.б.) дип әйтелергә тиеш. Әмма безнең татар журналистларының бер зур бәласе шунда: аларның күбесе төрле телләр нисбәтендәге мондый үзенчәлекне белмиләр, рус теле сүзтезмәсендәге сүзләр бәйләнешен һәрвакыт диярлек механик рәвештә аларның татарча тәңгәллекләренә дә күчереп куялар. Нәтиҗәдә еш кына татар теле сүзләренең үзара табигый бәйләнеш тәртибе (нормалары), икенче төрле әйткәндә, туган телнең үзенә генә хас синтаксик төзелеше бозыла.

Бүгенге татарча мәгълүмат чараларында татар, рус телләре нисбәтендәге шушы специфик үзенчәлек сакланмау аркасында, телебездә күпсанлы тупас хаталар хөкем сөрә. Аларның кайберләре, бик еш кулланылып, татар теленең табигый нормаларын кысрыклап чыгаралар һәм туган телнең нигезен какшатуга китерәләр. Мәсәлән, татарча гомер-гомергә *гармун уйнау*, *чаңгы шуу* рәвешендә сөйләгәннәр һәм язганнар, соңгы елларда ике тел белән эш итүче каләм ияләренең татар һәм рус телләренең үзенчәлекләрен тиешле дәрәҗәдә белмәүләре һәм тәрҗемә теориясеннән хәбәрдар булмаулары аркасында, *гармунда уйнау*, *чаңгыда шуу* формалары татар телендә урнашып килә. Бу уңай күренеш түгел, әлбәттә, телнең табигый төзелеше: кагыйдәләре, тәртибе (нормалары) бозылырга тиеш түгел.

Рус һәм татар сүзләре нисбәтенең үзенчәлекләрен белмичә эш итү аркасында, соңгы елларда телебезне чүпләгән гайре табигый тәгъбирләрдән берничә мисал: «... әнә шундый фикер *яңгырады*», «Рөстәм Миңнехановның ... юлламасы *яңгырады*», «...теләкләр дә *яңгырады*», «шул *яңгыраган* мәсьәләләр», «спектакльдә *яңгыраган* җырлар»... Мондый тузга язмаган «*яңгыраган*» сүзтезмәләрнең исемлеген озак дәвам иттерергә мөмкин. Нинди хәл бу, җәмәгать?! Ничек итеп *максатлар яңгырады, яңалык яңгырады, теләкләр яңгырады, фикерләр яңгырады, темалар яңгырады, бурычлар яңгырады, утырышта яңгыраган мәсьәләләр* һ.б. дип әйтеп була?! Ни өчен *максатлар куелмый, теләкләр белдерелми* яки *теләнми, фикерләр белдерелми, әйтелми, максатлар билгеләнми* һ.б.? Башың белән уйламыйча, автомат рәвешендә эш итү, телне фәкыйрьләндерү бит бу! Саф татарча фикер генә түгел, хәтта җыр да һәрвакыт яңгырамый: «бик матур (моңлы) *җыр җырлады*» ди чын татар кешесе, *җыр яңгыратты* дими.

Каләм ияләренең ныклап уйламыйча эш итүләре адым саен күренеп тора. «Тәкъдимнәр белән уртаклашу», хатирәләр (истәлекләр), тагын әллә нәрсәләр белән уртаклашу дип язалар. Дөрес түгел бу: тәкъдимне ясыйлар яки кертәләр, хатирәләрне (истәлекне) сөйлиләр һ.б.

«...фронт сызыгына барып... концертларда катнаша». Кайда һәм нинди була ул *фронт сызыгы*? Ни өчен *фронтка барып* түгел?

«Тамашачыны яратырга кирәкми, аны хөрмәт итәргә кирәк», – дип, бик зур хәрефләр белән яза баш газета Фәрит Бикчәнтәев исеменнән. Хөрмәт итәргә кирәк дип әйтүе белән килешеп була, ә ни өчен яратырга ярамый икән? Аны тыярга кемнең хакы бар?

«Чишмәле авыллар картаймый»,– дип яза эчтәлеге белән юньле генә бер газета журналисты. Әмма ул татарча яхшы белми: җанлы нәрсәләр – кешеләр һәм башка тереклек (җан) ияләре генә картая, җансыз нәрсәләр (предметлар) искерә, туза, чери, җимерелә, югала (юкка чыга) һ.б.

«2025 елга кадәр пенсиянең тупланма өлешен «катыру» турында (закон)». Бу җөмләнең авторы, рус телендәге *заморозить* сүзен туры мәгънәсендә ялгыш тәрҗемә итеп, *катыру* сүзен кулланган, һәм көлке хәл килеп чыккан. Әмма ул *заморозить*ның «оставить на прежнем уровне или неиспользованным» дигән күчерелмә мәгънәсе дә барлыгын белмәгән: «...тупланма өлешен файдаланмый тору турында» яки «тупланма өлешен түләүне туктатып тору турында» дип язарга кирәк иде. Сүз уңаенда шуны да әйтеп китик: журналистларның күбесе аңлатмалы һәм ике тел сүзлекләреннән файдаланмый, күбесендә алар юк та. Тел белән эш итүче җитди карашлы журналистның сүзлекләрдән файдаланмыйча эшләве – нонсенс (нормаль хәл түгел). Тел ул шундый катлаулы һәм шулкадәр бай хәзинә: аны гомерең буена өйрәнәсең, шулай да бөтен тулылыгы белән белеп бетереп булмый. Беләм дигән нәрсәләрне дә, вакыт-вакыт тиешле сүзлеккә карап, белемеңнең дөреслеген тикшереп тору артык булмый.

«Әгъзаларның тыйнак кына ташламалары да бар иде». *Тыйнак* дип кешеләргә карата гына әйтелә. Бу җөмләдә исә «гади генә яки кечерәк кенә ташламалар» дип әйтергә кирәк. «Мондый шикләнүләр Девятаевны әле 12 ел дәвамында озатып бара». Бу русчадан шыксыз, мәгънәсез калька. Татарча әйбәт белгән кеше шулай «шикләнүләр (кемне дә булса) озатып бара» дип сөйләр идеме икән?!

Рус телендәге *призвать (призывать)* сүзен хәзер барысы да диярлек *чакыру* дип тәрҗемә итә: «Төркия ... Русия белән авиаэлемтәләрне туктатырга чакыра» (дөресе: ... туктатырга кирәк, ди яки туктатырга куша һ.б.); «...аны солдат хезмәтенә чакыралар» (чакырмыйлар, алалар – армиягә алалар). Шулай итеп, элементар сөйләм нормаларын бозалар.

«...без Иҗтимагый пулатта түгәрәк өстәл җыеп тикшерербез». Пулат ул – гадәттә, таштан салынган зур бина – ташпулат. Бу җөмләдә сүз *Иҗтимагый палата* дигән оешма турында бара лабаса!

Хәзер кыскартулар заманасы: тормышта да кыскартулар күп, матбугатта да дистәләрчә сүз урынына *кыскарту* сүзен генә кулланалар: укытучыларны да, мәктәпләрне дә, татар теле дәресләрен дә, хезмәт хакын да, тагын әллә ниләрне кыскарталар, телләрен белмәгән каләм ияләрен генә кыскартасы калды. Чын татарча: укытучыларны эштән

алалар яки чыгаралар, мәктәпләрне ябалар, хезмәт хакын, дәресләрне киметәләр...

«Гомер – иң нечкә чор», – дип яза бер газета. Нинди була икән ул *нечкә чор*?! Нечкәсе булгач, юаны да буладыр инде аның!

«Фольклорны белүче нечкә музыкант», – дип язганнар эчтәлеге белән күркәм бер журналда. Кай җире нечкә икәнен дә әйткән булсалар ул музыкантның, әйбәт булыр иде!

«Япониядә яше 3–5 елдан арткан автомобильләрне тоту икътисади яктан отышлы түгел». *Яшь* сүзе кешеләргә һәм хайваннарга карата гына кулланыла. Ә бу җөмләне «Япониядә 3–5 ел йөргән автомобильләрне тоту файдалы түгел» рәвешендә төзергә кирәк иде.

«Михаил Девятаев, дошман самолёты штурвалы артында утырып, ... әсирлектән кача». Бу җөмлә авторы самолёт штурвалы артына утырып булмаганлыгын, «самолёт штурвалын кулына алып» дип әйтергә кирәклеген белмәгән.

Журналистларның һәм ике тел белән эш итүче башка һөнәр ияләренең, төрле телләр үзенчәлекләрен белеп бетермәүләре һәм тәрҗемә принципларыннан, методларыннан хәбәрдар булмаулары аркасында, татар теленең табигый сөйләм нормаларын бозуларына бик гыйбрәтле мисалларның бер төре – *эре* сүзе белән ясалган әйтелмә-тәгъбирләр. Төп мәгънәләре белән тәңгәллекләр булып саналган *крупный* һәм *эре* сүзләре мәгънә күләмнәре буенча бер-берсеннән нык аерылалар: *крупный* сүзенең мәгънәләре, *эре*некенә караганда, күпкә артыграк. Татар каләм ияләре, аларның шушы үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, русчадагы *крупный* сүзен һәр очракта да *эре* дип тәрҗемә итәләр һәм, бик аяныч, үзләренең никадәр зур хата ясаганлыкларын сизмиләр. *Эре* татар телендә, нигездә, бөртекле, бүлбеле һәм башка үзенчәлекле үсемлекләргә, әйберләргә карата гына кулланыла: *эре орлык, эре бәрәңге, эре суган* һ.б. Рус телендә исә *крупный учёный, крупный разговор, крупный талант, крупное хозяйство* һәм *крупный* сүзе белән килгән башка күптөрле әйтелмәләр дә кулланыла. Татарча *эре галим яки язучы, эре талант, эре хуҗалык* һ.б. дип әйтелми, әйтелергә тиеш тә түгел, ләкин безнең каләм һәм сүз әһелләре шулай язалар һәм сөйлиләр: *эре шәһәр, эре отряд, эре һәлакәт, эре эшләр*... Мәгълүмат чараларында мондый «эре» нәрсәләргә бик еш тап буласың. Сөяксез тел ни сөйләмәс тә, телне чиле-пешле белгән кеше кулындагы каләм ни язмас, дип әйтергә генә кала.

Бик гаҗәп: ни өчен (нәрсәгәдер) «күзлектән карау», «тәнкыйть белән карау» яки «тәнкыйть күзлегеннән карау» дип адәм рәтле итеп әйтергә мөмкин була торып, «күзлектән чыгып карау», «тәнкыйть күзлегеннән чыгып карау» дип язалар һәм сөйлиләр икән? «Ярдәм итәргә кирәк», «Укытучы даими рәвештә белемен күтәреп (камилләштереп) торырга тиеш», «Яңа теманы өйрәнү», «Хаталарны төзәтү» дип әйтмичә, «Ярдәм итү өстендә эшләргә кирәк», «Укытучы һәрдаим үз өстендә эшләргә тиеш», «Яңа тема өстендә эш», «Хаталар өстендә эшләү» дип сөйли һәм язалар? Бу татар сүзләре белән русча сөйләү булып чыга бит!

Сәгать исәбен кайчанга кадәр рус теле өлгесендә «Утырыш 10 сәгатьтә

башлана», «Кояш 5 сәгать 03 минутта чыга» дип язарлар икән (татарчасы «Утырыш сәгать 10 да башлана, «Кояш сәгать 5 тулып 3 минутта чыга» яки «Кояш сәгать алтынчы 5 минутта чыга»).

Мәгълүмат чараларында тел хаталарының бик күбесе әйтелмәләрдәге сүзләрне бәйләү чараларын дөрес куллана белмәү аркасында барлыкка килә, һәм бу күренеш рус теле предлогларын күп очракта ялгыш хәрефкә-хәреф тәрҗемә итү – калькалаштырып алу: рус телендәге *под* предлогын, уйлап тормыйча гына, *аст* бәйлек сүзе, *за* предлогын *арт* бәйлек сүзе, *с* предлогын *белән* бәйлеге һ.б. белән тәрҗемә итү нәтиҗәсендә килеп чыга. Мисаллар:

Күзәтү астында яшибез (дөресе: күзәтүдә яшибез), изү астында яшәү (изүдә яшәү), Мәскәү астында барган сугышлар (Мәскәү тирәсендә барган сугышлар), төрле сәбәпләр астында (төрле сәбәпләр белән) һ.б.

Мәктәпләр турында кызыксыну (дөресе: мәктәпләр белән кызыксыну), аның хезмәтләренә кызыксыну (аның хезмәтләре белән кызыксыну), сәнгатькә кызыксыну (сәнгать белән кызыксыну) һ.б.

Түгәрәк өстәл артында сөйләшү (түгәрәк өстәл янында сөйләшү), исерек килеш руль артына утыручылар (исерек килеш машина йөртүчеләр), парта артында утыру (партада утыру) һ.б.

Шатлыгы белән уртаклашу (шатлыгын уртаклашу), фикерләре белән уртаклашу (фикерләрен уртаклашу), киңәшләре белән бүлешү (дөресрәге: киңәшләрен бирү) һ.б.

«Ул су артыннан үзегез бара идегезме?» (Дөресе: «Ул суга үзегез бара идегезме?»)

«Үз йортыбыз белән яшибез» («Үзебезнең йортыбызда яшибез»).

«Әти телефон белән куллана белгән» («Әти телефонны куллана белгән»).

«Үземнең кыяфәтем белән канәгать идем» («Үземнең кыяфәтемнән канәгать идем»).

«Тәрәзәгә шакыдылармы?..» (Тәрәзә шакыдылармы?)

«Үз артыннан байтак баянчыларны ияртте» (Үзенә ... ияртте).

Кайбер каләм әһелләре, кирәкмәгән тырышлык күрсәтеп, татар телендәге табигый сүз төзелешен бозып, яңа сүзләр ясап маташалар. Шундый ялгыш ясалган неологизмнарга *эшчәнлек, ассызыклау, дәүләтчелек, кызчык, оныкчык, икетуган* һәм башка шундый сүзләрне мисал итеп китерергә мөмкин. Болар һәм башка мәсьәләләр турында бу язма авторының мәкаләләрендә һәм китапларында тулы итеп язылган.

Телебезнең бүгенге торышы һәм аны куллануыдагы проблемалар турында сөйләр сүз күп. Туган телебезне бозып куллану күренешләренең бу язмада күрсәтелгәннәре бик азы гына. Аларны бер мәкаләгә генә сыйдырып бетереп булмый, әлбәттә, һәм андый бурыч куелмады да. Әмма шушыларына нигезләнеп һәм үзебез белгән башка мәгълүматка да таянып, татар теленең шактый нык бозыла баруының сәбәпләрен, телебезнең сафлыгын саклау ихтыяҗын, бурычларын күрсәтеп нәтиҗәләр ясарга һәм кайбер тәкъдимнәребезне белдерергә мөмкин һәм кирәк.

Мин журналистлык вазифасының җаваплы, авыр, бик кирәкле һәм мактаулы эш икәнлеген аңлыйм

(үзем дә берничә ел журналист булып эшләгән кеше) һәм бу һөнәр ияләре эшчәнлегенә зур бәя бирәм. Шулай да алар миңа үпкәләмәсен, гражданлык бурычым шуны әйтергә куша: матур тел белән оста язучы һәм сөйләүчеләр булса да, бүгенге матбугатның һәм радио-телевидениенең теле, гомумән алганда, канәгатьләнерлек түгел, димәк, журналистларның татар телен белүе тиешле дәрәҗәдә түгел. Бу хәлнең объектив һәм субъектив сәбәпләре бар, әлбәттә. Шуларны һәм аларга бәйләнешле кайбер бурычларны игълан итик.

Беренчедән, мәктәптә татар телен укыту методикасы хәзерге икетеллелек шартлары һәм коммуникатив принципларны исәпкә алып төзелмәгән. Туган тел күренешләрен, категория, формаларын, үзенчәлекләрен бүгенге сөйләм практикасына нык бәйләп, язма һәм сөйләм телендәге күпсанлы ялгышларга анализ ясау һәм төзәтү җирлегендә өйрәтергә кирәк. Шулай ук хәзер туган телнең милләтләр аралашу чарасы рус теле белән даими бәйләнештә булуын һәм журналистларның даими рәвештә рус теленнән тәрҗемә итеп эшләүләрен истә тотып, татар теле дәресләрендә тәрҗемә эшенең иң әһәмиятле принцип һәм методларын да өйрәтү зарур.

Икенчедән, югары уку йортында татар журналистларын әзерләгәндә, аларга татар телен һәм тәрҗемә теориясен яхшы итеп өйрәтергә кирәк. Югыйсә әлегә бу бурыч үтәлми булса кирәк.

Өченчедән, безнең журналистларга үзлегеннән татар теленнән белемнәрен күтәрү, камилләштерү мөһим. Хәлбуки аларның телгә игътибары җитми: аны эшләрендә бик әһәмиятле нәрсә дип санамыйлар, белгәнебез җиткән, телне яхшы итеп өйрәнүнең кирәге юк, дип уйлыйлар, күрәсең, һәм, болай уйлап, нык ялгышалар. Хаклы булмасам, гафу үтенермен, ләкин мин шундый фикердә: безнең каләм ияләре тел культурасы, дөрес сөйләм, тәрҗемә мәсьәләләренә караган мәкаләләрне дә, китапларны да укымыйлар. Хәтта шундый парадокс хөкем сөрә: кайчакта кайсыдыр газетада мәгълүмат чаралары телендәге проблемалар турында мәкалә басылган була, һәм кайсыдыр бер журналист газетаның шул ук санында әлеге мәкаләдә күрсәтелгән тел ялгышлары белән язылган материалын урнаштыра.

Дүртенчедән, мәгълүмат чаралары өчен җаваплы органнар тарафыннан журналистларга телләренең дөреслеген, сафлыгын катгый саклау таләбе җитми, дөрес, матур, аһәңле, үтемле телдән башка яхшы матбугат, радио-телевидение материаллары була алмавы искәртелми.

Бишенчедән, республика җитәкчелегенең татар матбугатына, радио-телевидениенең татарча тапшыруларына игътибары, ярдәме, шулай ук халыкның рухи тормышы икътисад мәсьәләләре кебек үк әһәмиятле дигән принцип белән эш итү җитәрлек түгел. Тагын бер мөһим искәрмә: хакимият органнары милли мәгърифәтнең эшен җанландыру, абруен һәм нәтиҗәлелеген күтәрү белән җитди шөгыльләнергә тиеш. Шунсыз татар телендәге мәгълүмат чараларын да тиешле дәрәҗәдә тоту кыен булачак, ихтимал, мөмкин дә булмас.

Шулай да өметебезне өзмик, дәүләт җитәкчеләренең, рухи тормышыбыз өчен җаваплы кешеләрнең акыл белән эш итүләренә исәп тотыйк һәм аларга уңышлар телик.



# «ӘЙТЕЛӘСЕ СҮЗЕМ ЧИШМӘ ЧЕЛТЕРӘВЕНӘ ТИҢ»



**Энҗе НУРИСЛАМОВА,**

Чаллыдагы М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Татарстанның атказанган укытучысы




Тизлек заманында яшибез: картының да, яшенең дә кулында смартфон, телефон. Көн дә галиҗәнап Интернет челтәреннән ил-көн яңалыкларын, блогерларның шәхси тормышларын күзәтәбез. Хәзерге буын – клипик фикерләүче буын, ягъни аларның игътибары кыска вакытлы, аны тотып калырга кирәк. Соңгы вакытта Интернет челтәрендә кешеләрнең психологик халәтенә туры килгән аффирмацияләр, канатлы гыйбарәләр, танылган фикер ияләренең цитаталары, хикмәтле фикерләрнең таралуы, мөгаен, шушы сәбәптәндер. Татарча газета-журналларның рәсми сайтларында танылган шәхесләрнең фикерләре шәрехләнеп барыла, бу үз чиратында татар укучысын тәрбияләүнең бер чарасы булып тора.

Педагогика фәннәре докторы, профессор, Россиянең табигать фәннәре академиясе академигы Җәүдәт Абдулла улы Хөсәенов безне гаҗәпләндерүдән туктамый. Аның күп еллар дәвамында Интернетта дөнья күргән һәм моңарчы матбугатта басылмаган афоризмнарын, мәкальләрен, фәлсәфи, кызыклы фикерләрен, хикмәтле һәм канатлы сүзләрен туплап, «Әйтеләсе сүзем чишмә челтерәвенә тиң» җыентыгы дөнья күрде.

Татар әдәбиятында мәкальләр, фәлсәфи, кызыклы фикерләр, хикмәтле һәм канатлы сүзләр XI йөздә яшәгән Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» китабында теркәлгән.

Татар укучысы XV гасыр дастаннарында кулланылган мәкальләрне, XVII гасыр әдибе Мәүла Колыйның хикмәтле сүзләрен һәм инде «Татар теле ул – урам теле, ломовойлар теле, әдәби-гыйльми тел булырга сәләте юк аның» дигән карашлар яшәгән заманда татар реформаторы К. Насыйриның туган телен кайнар яклап чыгуын: «Ялган, яла бу! Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел, эшләнмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган», – дигән ялкынлы фикерләре белән эш алып баруын бик яхшы беләдер.

XX гасырда Н. Исәнбәт татар халкының мәкаль-әйтемнәрен туплап өч томда чыгарды, бу – галимнең татар халкы өчен эшләгән иң саллы хезмәте буларак бәяләнде, тел хәзинәсен бөртекләп җыюның гүзәл үрнәге булды.

Рузилә Галләмованың «Табышмаклар. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Сынамышлар» дигән җыентыгы, балаларның сөйләм телен баетуны күздә тотып, ата-аналар, укытучылар һәм укучыларга файдалы булсын дигән максаттан 2014 елда нәшер ителгән иде.

Җ. Хөсәеновның «Әйтеләсе сүзем чишмә челтерәвенә тиң» исемле китабына кереш сүз язган язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Хәмзин: «Гомере буе гаделлек эзләгән, намус-вөҗдан тәгълиматларына тугры калган Җәүдәт Абдулла улы гаҗәпләндерде мине. Дөресрәге, сокландырды: никадәр зур эш башкарылган! Афоризмнар җыеп кына да бөеклеккә ирешкән

булыр иде ул. Хәер, язмышына язылган сынауларны үтмичә, мондый мәгълүмат, мондый белем хәзинәсе җыя алмас иде», – дип язган. Хактан да, методик кулланмалар, дәреслекләр, фәнни мәкаләләр язып танылган галим күптән түгел «Яшьлегемә кире кайтыр идем» китабы белән үз укучысын шаккатырган иде, инде килеп, әлеге хезмәте Җәүдәт Хөсәеновның, татар кешесе буларак, туган телен яратуының, кадерләвенең иң югары чагылышы буларак кабул ителә. Табигатьне күзәткән, аның мавыктыргыч дөньясын өйрәнүгә тормышын багышлаган галим күңеленең нечкә, сизгер булуы; үз максаты итеп, татар баласына үз туган телендә фәннәр өйрәтү вазгыятеннән дәреслекләр төзүе барышында, яшәү дәверендә тупланган фикер-нәтиҗәләренең бер җыентык булып әзерләнүе – гаять зур батырлык.

Авторның әлеге китабы ул – тормышның һәртөрле җил-давыллары эчендә, безне аталарча кайгырткан галимнең киңәшләреннән; белем-тәҗрибәсен һич түләүсез чын күңелдән гүзәл мисаллар һәм матур тел белән әйтелүче хикмәтле фикерләреннән; дөньядан алданмыйча, озак һәм сәламәт яшәргә, ничек бәхет-моратка ирешергә, үзе кебек яши белергә чакырган изге теләкләреннән; киң җәмәгатьчелек фикерен, гомумхалык карашын, уртак акылын туплаудан туган хезмәте. Китапта тупланган мәкальләр дәлил булып та, хөкем булып та, кәфил булып, кисәтүче яки гыйбрәт булып та, типик бер мисал булып та тормышның һәр ягына катышып, дөрес һәм гадел якны табарга, уртак мәслихәткә килергә, безне тоткарлыктан чыгарырга тырыша. Автор фикеренең мәгънәсе куәтле, нык дәлилле һәм ритмик сөйләмле, шигъри кинаяле, тәэсирле булып чыга. Чөнки һәр сүзнең артында акыл көче, үз халкының тарихи тәҗрибәсе, хикмәте, акыл һәм иҗат көче тора.

Әлеге китап – шул ягы белән телчеләр, әдип-шагыйрьләр, матбугат һәм хезмәткәрләре, укытучылар өчен зур байлык. Бигрәк тә безнең шикелле телебезнең культурасын өйрәнергә соң тотынган халык өчен сүз байлыгын саклап килгән хәзинә буларак кабул ителә.

Китап туган тел, тәрбия, гаилә, мәхәббәт, сәламәтлек, яшәү кадере, дуслык, ялгызлык, вакыт кадере, кылган эш, бәхет, язмыш, мәрхәмәт, күңел чисталыгы, намус, акыл, байлык, табигать һ.б. турында. Шушы урында тагын бер тапкыр Алмаз Хәмзин фикеренә тукталыйк: «Җәүдәт Абдулла улы әлеге китабында кеше холкына акыл кертә торган зирәк фикерләр, сокландыргыч ачышлар, сискәндерердәй әхлакый тәгълиматлар, иманга килердәй, денгә кертердәй сихәтле, шифалы алты меңгә якын нотык теркәгән. Эчтәлеге, рухи кыйммәте ягыннан караганда, әлеге җыентыктагы мәкальләр, фәлсәфи, кызыклы фикерләр, хикмәтле һәм канатлы сүзләр татар халык мәкальләренә аваздаш, бу – табигый хәл. «Туган телем – Тукай теле» бүлегендәге «Дөньядагы һәр кешегә үз иле, үз халкы, үз теле, үз дине кадерле. Татар теле – искиткеч гүзәл һәм камил тел», «Татар теле – нык үсеш алган, бай, тарихлы, мәдәниятле, бик аңлаешлы тел. Аны дөрес итеп куллана белү генә кирәк» дигән автор фикере югарыда телгә алган К. Насыйри фикере белән аваздаш. «Бик язасың килсә – кирәген яз, бик сөйлисең килсә – аз сөйлә» дигән фикерне татар халкының «Кешенең акылы камилләнгәч, сүзе азая» дигән мәкале янәшәсенә куясы килә. «Әгәр гаиләдә ана теле юк икән – туган тел юк» дигән мәкальне «Ананың балага биргән иң зур бүләге – тел» мәкале шәрехли. Авторның «Милләт буларак

халкыбыз юкка чыкмасын өчен тел, җыр һәм диннең саклануы кирәк» дигән җөмләсе бүгенге вазгыятьнең асылына туры килә. «Татар халкына хас сыйфатлар: алдашмый, хыянәт итми, байлыкка табынмый, ачык йөзле, гади, чиста, тәртипле, эшчән» дигән җөмләне укыгач, Карл Фуксның татарларга биргән бәясе искә төшә. Шушы бүлектә тирән педагогик тәҗрибәсе булган галим тарафыннан туган телне саклау юлы ачыклана: «Мәктәптә барлык фәннәр татар телендә укытылмаса, тел үсми. Бары тик татар теле дәресе белән генә телне үстерү ул – хыял». Бөек педагог К. Ушинскийның «Кеше иң беренче чиратта үз телен, аннан гына чит телләрне өйрәнергә тиеш» дигән фикерен үстереп, автор: «Бала туган телен никадәр тирәнрәк белсә, аның акылы рус һәм инглиз телләрен үзләштерүгә әзерлекле була», – дигән хикмәтле фикерен әйтә.

Җәүдәт Хөсәенов туплаган мәкальләр арасында нәзирә формасында, ягъни әзер мәкальгә ияреп, дәвамы язылганнар да очрый, мисал өчен: «Туган телем, иркә гөлем, ачып бирче миңа дөнья серен», «Бер казанга – ике тәкә башы, бер йөрәккә ике мәхәббәт сыймый» һ.б.

«Әхлакый тәрбия – матур чәчәк, таҗ яфракчылары – укыту-белем бирү» бүлегендә белем-тәрбиягә нисбәтле фикерләр әйтелә. «Яшь буынга тәрбия һәм белем бирүче укытучының электән килгән изге, тыныч һөнәре бүген иң куркыныч һөнәргә әверелде», «Бала смартфонга кызыкмасын. Дәреслек укыган бала дөрес язарга өйрәнә. Эчтәлегендә булган уңай сыйфатларны үзенә кабул итә», «Элек укытучы-педагог иң дәрәҗәле зат иде. Бүген аның җәмгыятьтә дәрәҗәсе юк. Нәтиҗәдә киләчәк җәмгыять үзе дә тискәре якка үзгәрәчәк», «Яшь буынның белемле булуга караганда тәрбияле булуы мөһимрәк. Чөнки тормышта белемле җинаятьчеләр саны арта бара» дигән җөмләләрдә бүгенге көн белем-тәрбия системасының төп проблемалары чагылыш таба. Авторның җор теле белән әйтелгән: «Оныгым белән дәрес әзерләгәндә, үземне депутат шикелле итеп тоям. Үзем берни белмим инде, белгән булып кыланам», я булмаса, «Мәктәптә укыганда, минем бердәнбер «репетиторым» әтәйнең перәшкәле каешы иде» җөмләләрен укыганда, ирексездән елмаясың.

«Гаилә – бәхет ачкычы» бүлегендә бала тәрбияләүдә ата-ана роленә басым ясала: «Бүгенге бала – киләчәк җәмгыять кешесе, киләчәк тормышны тудыручы, аны дәвам итүче. Ата-ананың эше никадәр күп, вакыты да бик тар булуга карамастан, үз баласына вакыт калдырырга тиеш», – дип яза автор.

«Мәхәббәт бер генә, килми ул гел генә» бүлегендә Җ. Хөсәенов, тормыш тәҗрибәсенә таянып, психологлар биргән киңәшләргә тиң фикерләрен китерә, мисал өчен: «Тормышта аерым кешегә бәйлелек аркасында, аны югалтырмын дигән уй туып, тынычсызлык барлыкка килә», «Кеше яшь вакытта тирәнтен фикерли белми, өстән уйлый, шул сәбәпле киләчәк тормышында ялгыша, алдагы хыялларын югалта», «Әйтергә иң кыен сүзләр: «Мин сине яратам», «Гафу ит», «Миңа ярдәм итә алмассыңмы?» Автор үз милләтен зурлавын дәвам итеп, «Французлардан чибәр, японнан күндәм, испаннан кайнар, чукчадан күңелле, чегәннән хәйләкәр ул – татар кызы» дигән олы бәясен бирә. Әлеге бүлектә китерелгән афоризмнарны өлкән сыйныф укучылары белән тәрбия сәгатьләрендә өйрәнү файдалы булачак.

«Кешенең иң зур бәхете – сәламәтлек һәм күңел тынычлыгы» исеменнән күренгәнчә, дөрес сәламәт яшәү рәвешенә кагылышлы фикерләрдән тора. «Гомер елгасы ике ярдан

гыйбарәт. Аның берсе – исәнлек, икенчесе – саулык», «Аз ашыйсың– тәнең тыныч, гөнаһың аз – җаның тыныч, аз сөйлисең – башың тыныч» җөмләләрендә Конфуций карашлары да чагылып китә.

«Яшь барган саен, яшәү кадерен ныграк тоясың» бүлегендә яшьлек һәм картлык төшенчәләренең асылын ача торган образларга бай афоризмнар китерелгән. «Йөрәк тирәнлегеңдә бала булып кал, шул вакытта яшьлегеңә кире кайтырсың» дигән фикернең әле беркайчан да әйтелгәне юк иде. Шәп бит! «Яшьлек– ялгыша, урта яшь – көрәшә, картлык– үкенә» – гаҗәеп төгәллек белән әйтелгән фикер.

«Яхшы дус авырлык килгәндә беленә» бүлегендә дуслык мәгънәсе акыллы төшенчәләр аша ачыла, әлеге бүлектә бик үтемле фикерләр әйтелә. «Яхшы кое – коры елда, ә яхшы дуслар кыен минутта беленә».

«Көчле кеше ялгызлыктан курыкмый» бүлеге исеменә салынган мәгънә белән үк кызыксыну уята. «Ялгызлык – көч билгесе, көчсезләр һәрвакыт төркемгә тартыла», «Көчле кешене яратмыйлар, чөнки аның белән идарә итеп булмый», «Ялгызлык яратырга, югалту бәяләргә өйрәтә» кебек фикерләрне тирән тормыш тәҗрибәсе булган фикер иясе генә әйтә ала.

«Юл турында кайгыртма – юлдашың турында кайгырт» бүлегендә: «Комы юк – су, хуҗасы юк – ил, якасы юк – тун, законы юк йорт булмый» фикере образлылык, гомумиләштерү көче белән аерылып тора.

«Вакыт белән санлашабыз – вакыт безнең белән санлашмый» бүлегендә тормыш, гомер агышы турында фәлсәфи карашлар тупланган. Без бер өлешен генә кулланырга ярата торган әйтемнең дәвамы үстерелеп, сәбәп-нәтиҗә формасына җиткерелгән: «Вакыт дәвалый, диләр. Вакыт дәваламый. Билгеле бер вакыт дәвамында кешенең фикерләре үзгәрә».

«Күңел биреп эшләгән эш уңай бәяләнә» бүлегендә үз эшенә бирелгән хезмәтнең тәмен тойган укучы хикмәтле фикерләрне рәхәтләнеп укый ала. «Үз хезмәтеңә генә түгел, кеше хезмәтенә бәя бирү өчен дә, башыңдагы уй-фикерең җитәрлек дәрәҗәдә булырга тиеш», «Хәзерге заман чынбарлыгы: хезмәт кешесе – түбәндә, ә җырчы, шамакай, сәүдәгәр һәм алдакчы – үсеп килүче буын өчен үрнәк» кебек фикерләр көн кадагына туры килә. «Бәхетле кеше– бәхет, бәхетсез кайгы-хәсрәт алып килә» бүлегендә көн аффирмациясе форматындагы фикерләр очрый, гомумән, «бәхет» төшенчәсе күптөрле итеп ачыла, арада үземә иң ошаганы: «Кешенең тормыштагы шатлыклы рухи һәм сәламәт хәле – бәхет ул» дигәне.

Укучыга кызыклы булыр, алдагы бүлекләрнең исемнәреннән күренгәнчә, нинди эчтәлектәге фикерләр белән танышачагын үзе теләп укыр: «Яхшылык та, яманлык та үзеңә кайта», «Усаллыкка елмай, начарлыкка җавап бирмә», «Күңелең чиста булса – уең изгелектә», «Намуслы кеше алдашмый», «Юләр белән сугышканчы, акыллы белән гәпләшеп утыр», «Байлык өчен яшәмә – байлык синең өчен яшәсен», «Табигать кешедән көчле, саклый белмәсәң үчле», «Виртуаль дөнья – алдагыч дөнья», «Тормыш барысын да үзе җайлый». Әлеге бүлекләргә мин махсус тукталмыйм, укучы үзе укып ләззәт алырга, авторның ачышларына сокланырга урын калдырам.

Кыскасы, «Әйтеләсе сүзем чишмә челтерәвенә тиң» җыентыгы кеше затының йөрәгеннән чыккан 21 төрле тәмгә ия, ләкин һәрберсе кешене савыктырыр көчкә ия акыл чишмәсенә тиң. Бу җыентык – тынгы белмәс галимнең үз туган теленә хөрмәте, мәхәббәте, киләчәк буынга тапшырылырга тиешле әхлак тәрбиясе, тормыш тәҗрибәсе тупланган хезмәте, шуңа күрә әлеге хезмәт аеруча кыйммәтле.

08




# СҮЗ ЯСАГЫЧ КУШЫМЧАЛАР

## *(5 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Лилия ИБРАҺИМОВА,**

Казандагы 183 нче гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү, өйрәнү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**

*Предмет:* сүз ясагыч кушымчаларны аера һәм сөйләмдә таба белү; һөнәрләр темасы буенча лексиканы ныгыту.

*Метапредмет:* төрле сүз төркемнәре ясый торган кушымчалар белән яңа сүзләр ясау күнекмәләрен формалаштыру; күнегүләр эшләү нәтиҗәсендә осталык һәм күнекмәләр булдыру.

*Регулятив:* укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти, анализлый, уку эшчәнлеген оештыра белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә алу.

*Танып белүдә:* уку максатын мөстәкыйль билгеләү; тиешле мәгълүматны табу; сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә салу; объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

*Коммуникатив:* фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; янәшәдәге кешеләргә игътибарлы булу.

*Шәхескә кагылышлы:* балаларда белемгә омтылыш булдыру; үз мөмкинлекләреңне бәяләү; хезмәт иясенә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** компьютер, интерактив такта, биремле карточкалар, дәреслек (Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теле. 5 нче сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015).

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше**

**Укытучы өчен максат:** балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.

**Укучылар өчен максат:** дәрескә игътибар булдыру.

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Хәлләрегез ничек?

**Укучылар.** Кояшлы иртә кебек.
Туган телне – Тукай телен
Өйрәнергә дип килдек!

**Укытучы.** Бүген кем укытучы була?

**Укучы.** Мин булам.

**Укытучы.** Минем ярдәмчем нишләргә тиеш?

**Укучылар.** Ял минуты үткәрә. Командага бүлә.

**Укытучы.** Укучылар, мин сезгә үзбәя битләре бирәм. Сез үзегезгә билгеләр куеп барырсыз. Ничек куясын сез инде беләсез. Яңа теманы үзләштерүдә уңышлар телим.

**II. Өй эшен тикшерү**

**Укытучы өчен максат:** һөнәр ияләренең исемнәрен, аларның шөгыльләрен әйтә белүләрен ачыклау.

**Укучылар өчен максат:** һөнәр ияләренең исемнәрен, аларның шөгыльләрен дөрес әйтү.

**Укытучы.** Укучылар, сез нинди һөнәрләр беләсез? Алар нишлиләр?

**Укучылар** *(күмәк җавап)*. Эшче заводта эшли. Сатучы кибеттә сата һ.б.

**Укытучы.** Бик яхшы, укучылар. Булдырдыгыз!

**III. Яңа белем һәм күнекмәләр формалаштыру**

**1.** Төп этапта булачак актив

эшчәнлеккә әзерлек. Уку мәсьәләсен кую.

**Укытучы.** Укучылар, тактага карап әйтегез әле. Бу нәрсә?

**Укучылар.** Агач тамыры.

**Укытучы.** Әйе, дөрес. Ә агачның тагын нәрсәләре була?

**Укучылар.** Агач үзе (үзәге), ботаклары, яфраклары.

**Укытучы.** Ә иң мөһим җире нәрсә? Нәрсәсез үсә алмый?

**Укучылар.** Тамыры.

**Укытучы.** Бик дөрес әйтәсез. Агачның тамыры – иң кирәкле урыны. Ә бу рәсемдә нәрсә күрәсез?

**Укучылар.** Бу – бакча. *(Бакча сүзе языла.)*

**Укытучы.** Ә бу рәсемдә кем?

**Укучылар.** Бу – бакчачы. *(Бакчачы сүзе чыга.)*

**Укытучы.** Бакчачы кем ул?

**Укучылар.** Һөнәр исеме.

**Укытучы.** Бу ике сүз арасында нинди аерма бар?

**Укучылар.** *Бакчачы* сүзендә *-чы* кушымчасы бар. Ул яңа сүз ясый.

**Укытучы.** Сүзнең лексик мәгънәсе үзгәрдеме?

**Укучылар.** Әйе, үзгәрде, яңа лексик мәгънәле сүз барлыкка килде. Димәк, татар телендә яңа сүзләр ничек (нинди юллар белән ) ясала икән?

**Укучылар.** Ясагыч кушымчалар ялганып.

**Укытучы.** Дәресебезнең темасы нинди булыр инде? Без бүген нәрсә турында сөйләшербез?

**Укучылар.** Сүз ясагыч кушымчаларны өйрәнербез.

**Укытучы.** Әйдәгез, агачыбызны яфраклы итик! *(Агачның яфракларында сүз ясагыч кушымчалар килеп чыга.)* Агачның яфраклары күпме?

**Укучылар.** Бик күп.

**Укытучы.** Сүз ясагыч кушымчалар, чынлап та, бик күп. Аларны менә бу таблицада карап китик.

**2.** Яңа теманы аңлату.

1. Таблицада сүз ясагыч кушымчалар аерып күрсәтелә.

| Исем ясагыч кушымчалар | Сыйфат ясагыч кушымчалар | Фигыль ясагыч кушымчалар |
|---|---|---|
| -чы/-че | -лы/-ле | -ла/-лә |
| -лык/-лек | -сыз/-сез | -ыш/-еш |
| -даш/-дәш | -гы/-ге | -лан/-лән |
| -таш/-тәш | -кы/-ке | -лаш/-ләш |
| -гыч/-геч | -чыл/-чел | -а -ә/-ай/-әй |
| -кыч/-кеч | | |

2. Сүзләрдән ясалма сүзләр ясау.

**Укытучы.** Бирелгән сүзләргә кушымчалар өстәп әйтергә, җөмлә төзергә кирәк.

**Сүзләр:** *җыр, тәрбия, бию, эш.*

**Көтелгән җаваплар.** Җырчы сәхнәдә җырлый. Тәрбияче балалар тәрбияли. Биюче матур бии. Эшче заводта эшли. **(Үзбәя)**

3. «Домино» уены. Дәфтәрдә эш.

**Укытучы.** Без хәзер «Домино» уены уйнарбыз. Һәр төркемгә дә берәр сүз бирелә. Сүз ясагыч кушымчаларны кулланып, яңа сүзләр ясарга, дәфтәргә язарга кирәк. Кайсы төркем күбрәк сүз уйлап табар икән? Бергә киңәшләшеп эшләгез. Бу биремгә бер минут вакыт бирелә. *(Ком сәгате 1 минутка куела.)* Иртәрәк эшләп бетерсәгез кулыгызны күтәрегез. *(Дәфтәрләренә язалар. Тактага чыгып, зур кәгазь битләренә язылган сүзләрне домино кебек тезәләр.)*

**1 нче төркем:** *таш* сүзенә яңа сүзләр. *Ташчы, ташлык, ташлы, ташсыз, ташла, ташлаш.*

**2 нче төркем:** *юл* сүзенә яңа

сүзләр. *Юлчы, юлдаш, юллы, юлсыз, юлла, юллаш.*

**Укытучы.** Бу биремгә нәтиҗә ясыйк. **(Үзбәя)**

4. Ял минуты.

*(Укытучы ролендәге укучы уен уйната.)*

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

**1.** «Әйтмим, бел!» уены.

*(Ишек шакыган тавыш ишетелә.)*

**Укытучы.** Кем бар анда? Керегез!

*(Әкиятче керә. Кулында зур тартма. Үзенең кем икәнен әйтми.)*

**Укучылар.** Син кем?

**Әкиятче.** Әйтмим, бел!

**Укучылар.** Син җырчымы?

**Әкиятче.** Юк. Мин җырчы түгел. *(Шул рәвешле укучылар сорау бирәләр.)*

**Укучылар.** Син әкиятчеме?

**Әкиятче.** Әйе, мин – әкиятче. Сез әкиятләр яратасызмы?

**Укучылар.** Яратабыз.

**Әкиятче.** Мин сезгә бүләк алып килдем. Ул бүләкне табу өчен тартма эчендәге биремнәрне үтәргә кирәк. Биремнәрне ике төркемгә бүленеп эшләгез. Миңа китәргә кирәк. Сезгә уңышлар телим!

**2.** Беренче тартманы ачу. «Җавабын тап» уены *(-лык/-лек сүз ясагыч кушымчаларын ныгыту).*

**Укытучы.** Укучылар, беренче тартмада нинди бирем бирелгән икән?

**Укытучы ролендәге укучы** *(биремне укый).* Табышмакларның җавабын табыгыз. *(Ике төркемгә дә конвертлар бирелә. Анда табышмаклар. Табышмакларның җавапларын бирелгән битләргә язалар. Тактага чыгып укып, магнит белән ябыштыралар.)* **(Үзбәя)**

1. Үзе атка атланган,
Аякларын арт якка салган. (*Күзлек*)
2. Апа бәйли алын,
Әни сарысын,
Әби ярата агын. *(Яулык)*
3. Тышы – калын, бу – китап,
Анда сүзләр – бихисап. *(Сүзлек)*
4. Айрат та кия,
Алсу да кия,
Аны кимәсәң,
Тиз салкын тия. *(Башлык)*

**3.** Икенче тартманы ачу. «Мәкальләрне туры китер!» биреме *(-лы/-ле, -сыз/-сез кушымчаларын ныгытуга).*

**Укытучы.** Монда мәкальләр бирелгән. Аларны туры китерегез. Дөрес җавапларны әйтеп, тактага беркетегез.

| | |
|---|---|
| Тәмле дә тел, | мәкальсез сөйләмәс. |
| Акыллы сүзгә | кояшсыз көн. |
| Акыллы кеше | тәмсез дә тел. |
| Китапсыз йорт – | ни җитә! |

**Дөрес җавап** *(укучылар тактага чыгып ябыштыралар).* Биремгә нәтиҗә ясау. **(Үзбәя)**

| | |
|---|---|
| Тәмле дә тел, | тәмсез дә тел. |
| Акыллы сүзгә | ни җитә! |
| Акыллы кеше | мәкальсез сөйләмәс. |
| Китапсыз йорт – | кояшсыз көн. |

**4.** Өченче тартманы ачу. «Әкиятне таны!» дигән проект эше.

**Укытучы.** Пазлны дөрес итеп төзеп, нинди әкияткә туры килүен әйтергә кирәк. Пазлның арткы ягында сораулар бар. Шул сорауларга җавап та бирегез.

**1 нче төркемгә:** «Сертотмас үрдәк» әкияте.

**2 нче төркемгә:** «Өч кыз» әкияте.

*(Укучылар, пазлны төзегәч, сорауларга тактага чыгып җавап бирәләр, сөйләргә чыгалар.)*

**5.** Дүртенче тартманы ачу, андагы бүләкне алу.
*(Бер укучы тартмадан имән чикләвеген ала, укучыларга нәрсә икәнен күрсәтми. Укучылар сораулар бирәләр.)*
**Укытучы.** Әйдәгез, укучылар, сораулар биреп, тартмада нинди бүләк яшеренгәнен белик.
**Укучылар.** Ул зурмы, кечкенәме? Түгәрәкме? Шакмаклымы? Кызылмы? Сарымы? Ул үсәме?
**Укытучы ролендәге укучы.** Әйе, аннан бер агач үсә. Без ул агач турында сөйләштек.
**Укучылар.** Ул имән чикләвегеме?
**Укытучы ролендәге укучы.** Әйе.
**Укытучы.** Әйдәгез, әлеге бүләкне барыбыз да кулдан-кулга йөртеп чыгыйк. Безнең кулларның җылысы белән ул тизрәк үсәр, нык имән агачы булыр. Әйдәгез, аны утыртып куйыйк. *(Гөл чүлмәгенә бергәләп имән чикләвеген утырталар, су сибәләр.)*

**V. Өй эше бирү**
**Укытучы.** Укучылар, һәрвакыттагыча, мин сезгә өч төрле өй эше тәкъдим итәм.
1. Кагыйдәне укырга.
2. Сүз ясагыч кушымчалы сүзләр булган ике табышмак язып килергә.
3. Кагыйдәгә таянып, кроссворд яки ребус төзергә.

**VI. Рефлексия**
**Укытучы.** Бүген без нәрсә турында сөйләштек?
**Укучылар.** Сүз ясагыч кушымчалар турында. Һөнәрләр турында.
**Укытучы.** Әйе, укучылар, бик дөрес әйтәсез. Нинди сүз ясагыч кушымчалар исегездә калды? Һөнәрләр турында нәрсә әйтә аласыз? Сезнеңчә, кайсы һөнәр кирәкле?
**Укучылар.** Барлык һөнәрләр дә кирәкле һәм мөһим.
**Укытучы.** Әйе, укучылар, бөтен һөнәр ияләре дә хөрмәткә лаек.

**VII. Дәресне йомгаклау**
**Укытучы.** Инде дәрестә алган билгеләрегезне йомгаклап, тулаем дәрес өчен билге куяр вакыт җитте. Ягез, кемнәр ничәле алыр икән? *(Укучыларның үзбәяләре тыңлана, кирәк булса, төзәтмәләр кертелә.)*
Үзбәя битләрен алып эшегезгә нәтиҗә ясагыз. Кем үзенә «5»ле куйды, кулыгызны күтәрегез. Кем «4»ле, «3» ле куйды? Нәрсәне аңлап җиткермәдегез? Нәрсәне бигрәк тә уңышлы булды дип саныйсыз? Кайсы бирем күбрәк ошады? Бүген үзләштергән белемнәр сезгә киләчәктә кирәк булырмы?

**ТЕСТ**
1. Ясагыч кушымчасы булган сүзләр рәтен билгелә:
а) агачлык, дуслаш, кибетче;
ә) урманнар, китабым, табигать.
2. Модальлек кушымчасы булган сүзләр рәтен билгелә:
а) хуҗасы, яфрагын, тәрәзәдә;
ә) саргылт, унынчы, йөгерә.
3. Бәйләгеч кушымчасы булган сүзләр рәтен билгелә:
а) әнкәй, китапчык, алтышар;
ә) күлмәгем, мәктәптә, авылыбыз.
4. Тамыр нигезле сүзләр рәтен билгелә:
а) йортта, урманнарга, тауларыбыз;
ә) биючеләр, яңалык, күңелле.
5. Ясалма нигезле сүзләр рәтен билгелә:
а) күңелдә, чиләкләр, яфраклары;
ә) яңгырлы, эшчән, шатлык.

**ТЕСТЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ**
Хатасы булмаса – «5»ле
1 хатасы булса – «4»ле
2 – 3 хатасы булса – «3»ле
**Җаваплар:** 1-а; 2-ә; 3-ә; 4-а; 5-ә.



09

# БЕЗ – ТУКАЙЛЫ ХАЛЫК

## (Әдәби-музыкаль кичә)

**Ләйлә ЗӘЙДУЛЛИНА,**

Әлмәттәге 25 нче урта мәктәпнең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Эльвира АБДРАХМАНОВА,**

Әлмәттәге 25 нче урта мәктәпнең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат:** укучыларда Г.Тукай иҗатына һәм туган телгә кызыксыну уяту; аның әсәрләре аша балалар күңелендә шәфкатьлелек, түземлелек, батырлык, горурлык кебек сыйфатлар тәрбияләү; матур сөйләм телен үстерү; сәхнәдә чыгыш ясау күнекмәләре булдыру.

**Җиһазлау:** язучының портреты, китаплар күргәзмәсе, плакатлар, рәсем күргәзмәсе, интерактив такта, презентация, урман күренеше өчен агачлар, куаклар, чәчәкләр.

*(Көчле музыка, дөбердәгән тавыш ишетелә.)*

*(Сәхнәгә заманча киенгән малай керә.)*

**Малай.** Ай, кая килеп эләктем соң мин, менә сиңа мә! Кая эләктем мин? Монда бөтен нәрсә дә бик сәер күренә. Кая соң мин? *(Тирә-якны карап йөри, фотога төшерә, сәхнә уртасындагы кешене күреп сискәнеп китә.)*

**Тукай.**

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ! Оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.
Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад.
Һәр олугълар эшләгәнлектән олугълыклар таба,
«Уйнады» дип бирмиләр ушбу җиһанда мәртәбә.
И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкаддәс нәрсә – эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.

*(Малайны күреп сискәнеп китә.)*

**Тукай.** Сиңа ни кирәк, хезмәтче малай? Кайсы бай җибәрде? Әллә тагын Шәрык клубына чакырасы иттеләрме үземне?

**Малай** *(бераз аптырап, тамашачыларга карап шыпырт кына).* Хезмәтче? Бу ни дигән сүз инде... Киемнәре дә бик сәер күренә моның. Артист халкына охшап тора үзе... Ай-яй ролен бигрәк яхшы уйный бу абый.

Абый! Әйтегез әле, ә сез кайсы театр артисты? Ә, туктагыз, әйтмәгез, үзем белән хәзер. Камал театрыннан, ә юк Тинчуриннан. Сез Габдулла Тукай ролен уйныйсызмы? *(Янына килеп җентекләп карый.)* Бигрәк яхшы грим салганнар үзегезгә! Нәкъ чын Тукай инде менә! Коеп куйган Тукай.

**Тукай.** Нинди театр артисты, нинди грим... Соң мин Габдулла Тукаев үзем бит инде.

**Малай.** Чын шагыйрь? Тукай үзе? Мин һич кенә дә берни аңламыйм?! Ничек була соң инде бу? *(Тамашачыларга.)* Өнемме бу, төшемме? Йоклыймдыр мин! Саташудыр бу! *(Үзенең битенә суккалый, чеметеп ала. Авыртудан кычкырып җибәрә.)* А-а-а-абый, әйтегез әле, ә хәзер ничәнче ел ул?

**Тукай.** 1910 ел.

**Малай.** 1910 ел?! Соң мин нәкъ 113 елга үткәнгә кайткан булып чыгам лабаса. Ышана торган түгел. Төштер бу валлаһи! *(Тамашачыларга гына ишетелерлек итеп.)* Айрат дустым үткәнгә җибәрә ала торган җайланма уйлап таптым дигәч, ышанмыйча гына уйнап, шуның бер төймәсенә баскан идем... Менә сиңа тамаша... Ярый әле, ул төймә минем кулда калган, димәк, кире өйгә кайтып булачак...

**Тукай.** Гел аптыраштa калдырдың бит әле син мине, энем. Кем атлы буласың син? Каян килеп чыктың соң әле син?

**Малай.** Тукай абый, бик беләсең килсә хәзер сөйлим. Мин үткәннән килдем бирегә. Аңлыйсыңмы, үткәннән... Төгәлрәк әйткәндә, 2023 елдан?

**Тукай.** 2023 елдан? *(Аптырап урындыкка утыра.)* Гел аптыраштa калдырдың бит әле син мине.

**Малай.** Мин үзем дә шаккатам әлеге хәлләргә. Минем каршымда татар халкының бөек шагыйре Тукай үзе торсын әле! Шаккатмалы хәл ич бу!

**Тукай.** Йә, кечкенә дустым, сөйлә инде хәзер, киләчәктә мине беләләрме, шигырьләремне укыйлармы? Гомерем заяга узмаган дип ышанасым килә.

**Малай.** Кая ул, Тукай абый. Беләләр, бик яхшы беләләр. Бик күп шигырьләрегезне хәтта яттан өйрәнәләр. Менә мин сезнең «Пар ат» шигырен аеруча яратам. Сөйлимме үзегезгә?

**Тукай.** Рәхим ит, дустым!

**Малай.**

Җиктереп пар ат, Казанга туп-
туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер,
суккалап та тарткалап.
Кич иде. Шатлык белән нурлар
чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак,
агачлар калтырый.
Һәр тараф тын. Уй миңа тик
әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм
тәмам баскан йокы.
Берзаман ачсам күзем, бертөрле
яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә
бер тапкыр күрәм.

**Тукай.** Афәрин, булдырдың!

**Малай.** Ә беләсезме, без хәзер сезнең белән нишлибез?! Киләчәккә барабыз! Үзегезнең мәңге үлмәс шагыйрь булуыгызны үз күзләрегез белән күрерсез. Сез ризамы?

**Тукай** *(бераз уйланып)*. Риза!

**Малай.** Әйдәгез, кузгалыйк алайса.*(Чыгалар.)*

*(Кара урман янына килеп чыгалар.)*

**Малай.** Ай, без кая килеп чыктык соң әле? Тирә-якта бары тик кап-кара урман гына. Йөрәк яргыч урын бу. *(Шикләнеп, куркынып кына баралар.)*

*(«Шүрәле» әкияте яңгырый.)*

Билгеле, бу кап-кара урманда
һәр ерткыч та бар,
Юк түгел аю, бүре; төлке –
җиһан корткыч та бар.
Һәм дә бар монда куян, әрлән,
тиен, йомран, поши,
Очрата аучы булып урманда
күп йөргән кеше.
Бик куе булганга, монда җен-
пәриләр бар диләр,
Төрле албасты, убырлар,
шүрәлеләр бар диләр.

*(Каршыларына Шүрәле килеп чыга. Куркып читкә сикерә.)*

**Шүрәле.** Ай, харап булдым, кешеләр! Ничәмә дистә еллар үзләреннән качып йөрдем ич инде. Юк, барыбер таптылар үземне. У-у-у.

**Малай.** Йә, Шүрәле, курыкма инде бездән, без сиңа һич начарлык эшләмәбез.

**Шүрәле.** 100 елдан артык вакыт үтте, ә сез һаман миңа ышанасыз, шуннан берәр почмактан килеп чыгармын дип өметләнәсез. Ә сез мине ахмак дип уйлыйсызмы әллә. Ә мин күренмичә йөрим. Теге юлы

Былтырыгыз кыскан бармагым әле һаман сыкрый. У-у-у. Исемә төшсә йөрәкләрем сыкрап куя. Эһ, шундый кети-кети уйныйсы килә кайчак, ә мин түзәм! Нишлим, мин бит шундый ялгыз, шундый ялгыз.

**Малай.** Шүрәле дустым, чынлыкта кешеләр син уйлаганча ук явыз түгелләр. Ә телисеңме син моңа үзең дә инанырсың. Әйдә безнең белән.

**Шүрәле** *(башын кашып)*. Шулаймы? Алдамассызмы соң?

**Малай.** Сүз бирәм. Әйдә инде, тизрәк кузгалыйк. *(Чыгып китәләр.)*

*(Сәхнә уртасына бәйрәмчә киенгән балалар чыга. Малай, Тукай, Шүрәле бәйрәмне читтән генә сәхнә читенә утырып күзәтеп торалар.)*

*(«Бәйрәм белән» җыры башкарыла.)*

**Алып баручы.** Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Бүген без бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган кичәгә җыелдык. Ул 1886 елның 26 апрелендә туып, 1913 елның 3 апрелендә дөньядан китеп тә барган. Шулай да Тукай бүген дә безнең арабызда кебек. Аның иҗаты, аның геройлары мәңге безнең күңелләрдә.

**1 нче укучы.**
Бөек Тукай – татарларның
Иң кадерле баласы.
Уена да килмәгәндер
Шулай бөек буласы.

**2 нче укучы.**
Умырзая чәчәгедәй
Гомере кыска булган,
Әмма иҗат җимешләре
Гасырларга сузылган.

**3 нче укучы.**
Шигырьләрен яттан белә
Барлык татар баласы,
Бик яратып укыйлар
«Шүрәле», «Су анасы»н.

**4 нче укучы.**
«Әллүки»не, «Пар ат»ларын
Белми соң кемнәр генә?
Шигырьләре уйландыра,
Укыгыз әле менә.

**5 нче укучы.**
Укыган саен укыйсы
Килә әкиятләрен.
Сокландыргыч иҗатының
Бик татлы җимешләрен.

*(Татар халкының «Шома бас» биюе)*

**2 нче алып баручы.** Г. Тукай, 27 ел гына яшәп, бары 8 ел гына иҗат иткән. Шулай булса да бәя биреп бетермәслек рухи байлык калдырган. Тормышы һәм иҗаты – халкыбыз тарихында иң якты, иң изге сәхифәләрнең берсе. Сабый чактан күңелләребезгә кергән Тукай безне гомеребез буена озата бара. Бала чагыбызга кайтып, Тукай әкиятендә яшәп алыйк әле!

*(«Кәҗә белән Сарык» әкиятеннән өзек сәхнәләштерелә.)*

*(Су анасы керә.)*

**Су анасы.** Үзләре бәйрәмгә җыелганнар, Сарык белән Кәҗәне дә чакырганнар, ә мине чакырырга да онытканнар… Кемне диген әле, Тукайның иң танылган әкият героен онытканнар бит!

**1 нче алып баручы.** Онытабызмы соң инде Су анасы. Юк ла инде. Сине онытырга һич мөмкин түгел!

**2 нче алып баручы.** Әйдә, түрдән уз, рәхим ит!

**Су анасы.** Карап-карап торам да иң зур кунагыгыз кая соң сезнең?

**1 нче алып баручы.** Кем турында әйтәсең син?

**Су анасы.** Әйдәгез әле, мин сезгә табышмак әйтәм, ә сез аның нәрсә икәнен белегез. Шайтан да, җен дә түгел түгелен, тик маңгаенда бардыр бер мөгезе. *(Укучылар*

*җавабы.)*

**Су анасы.** Әлбәттә, Шүрәле бу. Ә Шүрәлебез үзе кайда соң безнең? Шүрәледән башка нинди Тукай бәйрәме үтсен ди инде?!

*(Тукай белән малай Шүрәлене сәхнәгә этеп кертеп җибәрәләр. Шикләнеп кенә керә. Соңрак батыраеп китә.)*

**Шүрәле** *(җырлый).*
Бигрәк озын кулларым,
Күзләрем йөреп тора.
Килеш-килбәтемне күргәч
Көләсең килеп тора.
Мин Шүрәле, Шүрәле,
Чакыргач килдем әле.
Онытып үпкәләрне
Көлдереп алыйм әле. *(Кытыклый башлый.)*

Әй, шаяртам гына ич инде, дусларым, курыкмагыз сез миннән. Усал түгел лә мин. Кытыклыйсым килсә дә түзәм бүгенгә мин.

**1 нче алып баручы.** Әй Шүрәле. Без сине күптән көтәбез ич инде, рәхим ит, түрдән уз!

**2 нче алып баручы.** Әйдәгез, хөрмәтле кунаклар, укучылар белән бергә уен уйнап алабыз.

*(«Кәрия-Зәкәрия»* уены уйнала.*)*

**6 нчы укучы.**
Бик еракта балкып аткан
Бер гүзәл апрель таңы.
Бирде сине бу җиһанга
Әй шагыйрьләр солтаны!

**7 нче укучы.**
Саклый мәңге истәлегең
Син яшәп киткән урын.
Нур булып калды йөрәктә
Һәр синең язган җырың.

**8 нче укучы.**
Азмы какканны вә сукканны
Күтәрдең син, ятим?!
Җырладың шуңа халкыңның
Моң тулы хиссиятен!

**2 нче алып баручы.**
Тынмый сазың, моңлы сазың,
Кем тыя алсын аны!
Син яшәрсең, мең яшәрсең,
Син – шагыйрьләр солтаны.

**Тукай** *(сәхнә читендә басып тора)***.** Афәрин, яшьләр! Булдырдыгыз! Иманым камил, мондый талантлы балалар булганда, киләчәгебез ышанычлы кулларда, ә безнең иҗатыбыз мәңге яшәр. Ә мин китәм, чын күңелемнән шатланып китәм. Хушыгыз!

**2 нче алып баручы.** Тукай – милли шагыйрь. Татар халкы бар җирдә Тукай бар, халкыбыз яшәгәндә, Тукай яшәячәк.

**1 нче алып баручы.** «Татарда Тукай туган өчен куанам. Рухымның Тукай белән очрашуына куанам. «Шагыйрь кем?» дигән сорауга җавапны Тукайдан таптым. Тукай миндә үзенең милли рухы белән яши. Шул яздыра, шул эчке энергиягә әйләнде», – дип язган Сибгат ага Хәким.

**1 нче укучы.**
Юк, үлмәдең, гакыллы ир, мәшһүр Тукай!
Тавышың яши кабатланып һәр буында,
Халкың кебек бөек, матур җырларыңдай
Даһилыгың яңгырап барыр гасырларга.

**2 нче укучы.** Тукай безне туган көнебездән алып гомер буе озата килә. Ул безнең күңелгә беренче иман орлыклары салучы да әле.

**3 нче укучы.** Чыннан да, кечкенәдән күңелебезгә «Су анасы» шом сала, төштә «Шүрәле»се кытыклап теңкәгә тия. «Туган тел»ен көйләп юанасың.

*(Зал басып, «Туган тел» җырын җырлый.)*

10

# УКУЧЫЛАРДА ТЫҢЛАП АҢЛАУ, УКУ, ЯЗУ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕ БУЛДЫРУ

## *(6 нчы сыйныф дәреслеге мисалында)*



**Лилия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,**

филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты милли мәгариф бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре



**Гөлназ ГАЙНУЛЛИНА,**

филология фәннәре кандидаты, доцент

Методика фәнендә сөйләм эшчәнлеге дип тел системасы белән аралашу системасына бәйле хәбәр тапшыру һәм хәбәр алуга караган, билгеле бер максатны күздә тоткан процессны атыйлар. Кешенең эшчәнлеге – иҗади характердагы күнекмәләр системасы һәм бу система төрле коммуникатив биремнәрне хәл итүгә юнәлтелгән.

Билгеле булганча, сөйләм эшчәнлегенең 4 төрен аерып чыгаралар: тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу. Татар теле дәресләренең төп максаты – укучыларны татарча дөрес укырга һәм язарга өйрәтү, татар сөйләмен дөрес аңларга (тыңлап аңлау), сөйләм процессында катнашырга (кара-каршы сөйләшү), үзең күргән яки ишеткән вакыйгалар турында, яки укытучы биргән тема буенча сөйләргә һәм сөйләшергә (монолог, диалог), икенче төрле әйткәндә, һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре буенча да биремнәр нигезендә аларда белем һәм күнекмәләр булдыру.

Тыңлап (ишетеп) аңлау – аерым авазларны, сүзтезмәләрне, грамматик калыпларны ишетеп таный белү дигән сүз. Туган тел дәресләрендә укучыларда бу төр күнекмәләрне булдыру бик мөһим, чөнки телдән аралашканда кеше бер-берсенең фикерләрен ишетеп, тыңлап аңлый, шулай әңгәмә кора.

Яңа «Туган тел (татар теле)» дәреслекләре, һичшиксез, сөйләм эшчәнлегенең шушы дүрт төренә нигезләнергә тиеш. Әлеге мәкалә кысаларында тикшеренү объекты буларак алынган М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов авторлыгындагы 6 нчы сыйныф өчен төзелгән «Туган тел (татар теле)» дәреслеге әлеге таләпләргә тулысынча җавап бирә.

Дәреслекләрдә, беренче сыйныфтан ук башлап, текст белән эш өчен аерым дәресләр каралган. Бу дәресләрдә укучылар төрле текстларны тыңлыйлар, укыйлар, алда өйрәнелгән темаларга бәйле биремнәр эшлиләр. Биремнәр сөйләм эшчәнлегенең дүрт төрен дә үз эченә ала, алар укучыларда тыңлап аңлау, уку, язу һәм сөйләм күнекмәләре булдыруга юнәлтелгән.

Бәйләнешле сөйләмне тыңлый һәм аңлый белү сөйләм эшчәнлегенең башка төрләренә өйрәткәндә нигез булып тора. Тыңлап аңлаганда, укучылар аудитив күнекмәләрне формалаштырырга, әйтелгән сүзнең текст артындагы мәгънәсен аңларга, яңгыраган хәбәрнең гомуми идеясен аңларга һәм аңа үз мөнәсәбәтен белдерә алу сәләтенә ия булырга тиеш.

Тыңлап аңлау укучыларның сөйләм эшчәнлегенә стимул була, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру чарасы булып тора. Укучы белән укытучы арасындагы үзара бәйләнешнең һәм үзконтрольнең бәясен күтәрә.

Укучыларда тыңлап аңлау күнекмәләре булдыру өчен дәреслектә төрле эш төрләре тәкъдим ителә.

Укучылар, текстны тыңлап, сорауларга җавап бирәләр. Текстны тыңлаганнан соң, төрле биремнәр эшлиләр.

*Текстны тыңла һәм биремне*

*эшлә.*

Дөрес җавапны сайла.

а) Иң күңелле эш?
1) чәчәкләр үстерү
2) ашарга пешерү
3) иске сәгать төзәтү

ә) Кем сәгать турында сөйләшергә яратмый?
1) Галимулла абый
2) Кәримулла әфәнде
3) Шәмсетдин абзый

б) Шәмсетдин абзый кайсы сәгать белән горурлана?
1) стена сәгате
2) Лондон сәгате
3) «Восток» сәгате

в) Җомга көнне Шәмсетдин абзый дусларына нәрсә күрсәтергә тели?
1) ком сәгате
2) Лондон сәгате
3) стена сәгате

г) Сиңа кайсы бүләк күбрәк ошый?
1) планшет
2) кул сәгате
3) портфель

[6 класс, 1 кисәк, 87 бит]

*Текстны тыңла һәм биремне эшлә.*

Маэмай нәрсәләр турында хыяллана?
1)
2)
3)
4)
5)
6)

[6 класс, 1 кисәк, 135 бит]

*Текстны тыңла. Биремне эшлә.*

Текстның эчтәлегенә туры килмәгән җөмләләрне сайлап ал.
1) Русь белән Болгарны Кама елгасы тоташтырган.
2) Руслар Болгарга бал, балавыз, тире алып килгәннәр.
3) Болгарлар ювелир әйберләре, бал, тире сатканнар.
4) Болгар җирләре кара туфраклы булган.
5) Болгарда ашлык уңмаган.
6) 1924 елда Суздаль җирендә ачлык башланган.
7) Болгар әмире, Юрий Всеволодовичка бүләк итеп, 30 көймә белән икмәк җибәргән.

[6 класс, 2 кисәк, 176 бит]

Уку ярдәмендә язма тексттагы мәгълүмат алына. Укуның максаты язма хәбәрне күреп аңлау һәм төшенүдән гыйбарәт.

Уку сөйләм эшчәнлегенең рецептив төренә керә, чөнки ул язма текстагы информацияне кабул итүгә нигезләнгән. Башка сөйләм төрләренә караганда, уку җиңелрәк санала, чөнки текст инде әзер. Сүзнең язма кыяфәте дә хәтердә җиңелрәк саклана. Укучы текстны кире кайтып укый да ала.

Уку кешенең сөйләмен баета, матурайта. Уку ярдәмендә укучылар яңа сүзләрне отып калалар, ягъни сүзлек запасын баеталар, яңа синтаксик төзелмәләр үзләштерәләр, хәтердә калдыралар.

Укый башлаганда, кеше төрле максатлар куеп укый, шуңа бәйле рәвештә укуны дүрт төргә бүлеп карыйлар:
1) карап чыгу максаты белән уку;
2) танышу максаты белән уку;
3) өйрәнү максаты белән уку;
4) эзләнү максаты белән уку.

Текстны карап чыгу максаты белән укыганда, анда бирелгән тема турында гомуми күзаллау, яңа мәгълүмат табу күз алдында тотыла. Шуңа күрә карап чыгу максаты белән укыганда, зуррак текстларны файдаланалар. Текстның мәгълүмат тулылыгы бу төр уку өчен әллә ни әһәмиятле түгел.

Өйрәнү максаты белән укыганда, тексттагы мәгълүматны тулырак кабул итү күз алдында тотыла. Укучы тексттагы мәгълүматның күп өлешен истә калдырырга тырыша. Шуңа күрә мондый текстларның күләме кечерәк булырга, монда тасвирлау текстлары күбрәк сайланырга тиеш.

Эзләнү максаты белән уку билгеле бер темага караган газета мәкаләләрен, әдәбиятны уку өчен кулланыла. Аның төп бурычы – тексттан кирәкле фактларны табу.

Танышу максаты белән укуны «үзең өчен уку» дип әйтәләр. Чөнки бу текстны укыгандагы бурыч төп мәгълүматны ачыклаудан гына гыйбарәт була. Монда хикәяләүче, сюжетлы текстларны файдалану яхшы була.

Дәреслектә өйрәнү һәм эзләнү максаты белән уку өчен тәкъдим ителгән текстлар күп. Текстны укыганнан соң, укучыларга еш кына сорауларга җавап бирергә тәкъдим ителә, текстның эчтәлеге белән эш алып барыла. Укучылар текст ярдәмендә проблемалы сорауларга да җавап эзлиләр, логик фикерләү сәләтләрен дә үстерәләр.

*Шигырьне укы.*

Алтынчы класстагылар

Алтынчылар...
Унөч, ундүрт яшьтә.
Киләчәктә сездән кем чыгар?
Инженерлар, врач һәм, әлбәттә,
Космонавтлар чыгар, җырчылар.
Үсеп килгән галәм хуҗалары!
Килер көнгә шулар барасы.
Ә бүгенгә менә минем алда
Орбиталар – парта арасы.
Унөч-ундүрт яшьтә...
Алтынчылар...
Тик башлана озын юлыгыз.
Киләчәктә сездән кемнәр чыгар?
Кем булса да –
Кеше булыгыз! (*К. Булатова*)

1) *Кеше булыгыз* дигәнне ничек аңлыйсың?

2) Ни өчен автор алтынчы сыйныфта укучыларын *Үсеп килгән галәм хуҗалары* дип атый?

[6 класс, 2 кисәк, 7 бит]

*Текстның дәвамын укы.*

Барый абый Алексей Толстой китабын алды да бер җөмлә күрсәтте:

– А Роза упала на лапу Азора. Менә бу җөмләне сулдан уңга, аннан уңнан сулга укып карагыз әле, – дип тәкъдим итте ул.

Мондый уен белән бөтен класс мавыгып китте. Арабызда иң остасы Ильяс булып чыкты. Бер-ике көннән ул мондый җөмләләр күрсәтте:

– Акчага ал кадак, кадакла агачка. Таза егет кебек теге Азат.

Көннәрдән бер көнне безнең хөкемгә Хатыйп та үзенең ачышын күрсәтте. Аны укып карагач, Ильяс көлеп җибәрде:

– Нинди әбрәкадабра яздың син, Хатыйп?

Анда мондый сүзләр язылган иде:

– Адамтыкрук, адамшалру, реьно, карб, рачаннис, расабли, расаблю, ныкчынәдр, әллүк!

Без дә көлешергә тотындык:

– Марсиан телендәге язма.

*(Т. Нәбиуллиннан)*

1) *А Роза упала на лапу Азора* җөмләсен син дә уңнан сулга укып кара. Бу нинди җөмлә?

2) Ильяс язган җөмләләрне кирегә укысаң, нинди җөмләләр килеп чыга?

3) Хатыйп уйлаган җөмләнең сере нәрсәдә?

[6 класс, 2 кисәк, 11 бит]

Дәреслеккә кертелгән текстлар, әдәби әсәрләрдән өзекләр бик җентекләп сайланды, классик әсәрләр дә, яшь авторларның әсәрләре дә урын алды. Тагын бер үзенчәлек – аерым бер өзекне алдык та текстны оныттык түгел. Бер әсәрдән алынган өзекләр берничә дәрес дәвамында файдаланыла ала.

Язу телне өйрәнгәндә әһәмиятле урынны алып тора. Ул берәр нинди ситуациягә бәйле мәгълүматны язма формада хәбәр итү өчен кирәк.

Ф. С. Сафиуллина язма сөйләмдә катнашучы механизмнарны түбәндәгеләргә бүлә:

1. Мәгънәгә төшенү.

2. Алдан күрү синтезы механизмы. Язучы язарга кирәкле һәр сүзне эчке сөйләм аша үткәрә, аның артикуляцион һәм интонацион формалашуын тоеп тора. Сүзне әйткәннән соң, аның артындагы сүзләрне һәм аларның бәйләнеш формаларын язып куя.

3. Хәтер механизмы. Җөмләне һәм текстны язганда, сөйләм предметы һәрвакыт хәтердә булырга тиеш.

Укучыларның күп язуы: тактадан күчереп язу, таныш булмаган сүзләрне язу, өй эшен язып эшләү – болар барысы да балаларның сөйләм телен үстерүгә дә ярдәм итә.

6 нчы сыйныф «Туган тел (татар теле)» дәреслегендә язу күнекмәләре камилләштерү өчен биремнәр күп. Әлеге биремнәр өйрәнелә торган фонетик, лексик, грамматик материал белән дә бәйләнештә тәкъдим ителә.

*Тексттан мисаллар табып яз.*

Ирен гармониясенә буйсынган бер сүз:

Рәт гармониясенә буйсынмаган бер сүз:

[ғ], [қ], [w] авазлары булган берәр сүз:

Ике аваз белдерә торган хәреф булган бер сүз:

Яңгырау тартыклар гына булган бер сүз:

Саңгырау тартыклар гына булган бер сүз:

Татар телендә генә булган сузык авазлар кергән бер сүз:

Ачык иҗек булган өч сүз:

Ябык иҗек булган өч сүз:

*Сүзләрнең транскрипцияләрен яз.*

Карчык, буяу, өстендә, юка.

[6 класс, 2 кисәк, 6 бит]

*Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләрен куеп, текстны күчереп яз.*

Күренекле археолог болгар тарихы белгече А.П. Смирнов Суар шәһәре урынында бик кыйммәтле мәгълүматлар туплады. Тикшеренүчеләр шәһәрлек уртасында кирпеч корылма калдыкларын таш сарайны табалар. Сарай ике катлы булган һәм үзәктән ягып җылытылган. Бу сарай X–XI йөзләрдә төзелгән монголлар явы вакытында җимерелгән әмма тиздән торгызылган.

Археологик казулар да төрле эзләнүләр дә Болгар

шәһәрләренең хәрби ныгытмаларын күзалларга булышты. Болгар дәүләтенең үзәк өлешендә Төрек Тукчын һәм Нократ шәһәрләренең булганлыгы да билгеле.

[6 класс, 2 кисәк, 162 бит]

*Шигырь ярдәмендә 10 җөмлә төзеп яз.*

Выступает Фокус-Покус!
Маг! Волшебник! Чародей!
Восхищает Фокус-Покус
В цирке взрослых и детей:
Достаёт он из ушей
Двадцать пять карандашей!
Вынимает из кармана
333 банана!
Из перчаток белых-белых,
Снега белого белей,
Фокус-Покус может сделать
Белоснежных голубей.
Он снимает быстро шляпу:
«Милым зрителям поклон!»
А из этой самой шляпы
На манеж выходит слон!
Вот что значит ловкость рук!
«На арене Фокус-Покус,
Мастер фокусных наук!»

[6 класс, 1 кисәк, 30–31 битләр]

Изложение һәм сочинениеләр шулай ук язма сөйләмгә өйрәтәләр, һәм алар сөйләм күнегүләре булып саналалар. Мондый эш төрләрендә балалар дөрес язарга, эчтәлектән кирәкле мәгълүматны чүпләп алырга, икенчел мәгълүматны төшереп калдырырга, үз фикерләрен язарга өйрәнәләр.

*Шигырьне үзлектән укы.*

«Уфалла» арбасы

Әнием иелгән, бөкрәйгән,
Тартадыр «уфалла» арбасын.
Шул чаклар исемә төшә дә
Кузгата йөрәгем ярасын.
«Уфалла» арбасы – йөрәгем ярасы.
Чокырлы юллардан ерак ла
барасы.
Тормышның нужасы төялгән
арбаны
Тартадыр хыялый бер авыл
баласы.
Эчертте, ашатты, яшәтте,
Аңладык без аның файдасын.
Шуңа да зарланмый, бирешми
Тарттык без «уфалла» арбасын.

*Э. Флүн*

*Алдагы дәресләрдә укыган текстларны, шигырьне файдаланып, «Сугыш чоры балалары» дигән темага сочинение яз.*

[6 класс, 1 кисәк, 60 бит]

Язу күнекмәләренә өйрәтүгә сорауларга җаваплар да кирә. Укылган текст буенча сораулар бирү яисә картина, рәсем буенча сораулар биреп, җавапны язмача алу сөйләм теленә өйрәтүнең бер өлеше булып тора.

Сөйләшү – сөйләм эшчәнлегенең иң актив формасы, аралашуның икенче бер мөһим төре. Сөйләм күнегүләре түбәндәгеләргә бүленәләр:


1) сорау-җавап күнегүләре;
2) ситуатив күнегүләр (укыту-сөйләм ситуациясе ярдәмендә күнегүләр төзү);
3) репродуктив күнегүләр (тыңланган яки укылганны сөйләп бирү);
4) дискутив күнегүләр;
5) дескриптив күнегүләр (күрсәтмәлелеккә нигезләнеп);
6) инициатив күнегүләр (рольләргә бүлеп уйнау, интервью);
7) уен күнегүләре (викториналар);

8) тәрҗемә итү күнегүләре. [Сафиуллина,159 б.]

Бу күнегүләр ярдәмендә сөйләшә белү, иркен сөйләшә алу күнекмәләре барлыкка килә.

Дәреслектә сөйләм күнекмәләрен булдыруга, камилләштерүгә дә зур игътибар бирелә, төрле биремнәр тәкъдим ителә: укыган текстның планын төзү, шул план ярдәмендә текстның эчтәлеген сөйләү, әзер план биреп, шуңа таянып, текст төзеп сөйләү, парлап диалог төзү, төркемләп әңгәмәдә катнашу һ.б.

*Картина ярдәмендә Болгар шәһәре турында сөйлә.*



Н.М. Лукиянов. Рассвет в Булгаре

[6 класс, 2 кисәк, 163 бит]

*Мәкальләрнең башын ахыры белән тоташтырып укы.*

| | |
|---|---|
| 1. Идел буе – | бәрәкәтле җир. |
| 2. Илгә таянган – | Идел кичәр. |
| 3. Илен белмәгән | игелексез, |
| Халкын белмәгән | холыксыз, |
| Нәселен белмәгән | нәсәпсез. |
| 4. Үз халкын сөймәгән | башка халыкны да сөймәс. |

*Бер мәкальне сайлап ал. Әдәби әсәрдән, тормыштан алган бер мисал ярдәмендә аның мәгънәсенә туры китереп сөйлә.*

*Түбәндәге темаларның берсен сайлап алып, хикәя төзеп сөйлә.*

1. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк.
2. Идел.

[6 класс, 2 кисәк, 182–183 битләр]

Шул рәвешле, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә өйрәтү түбәндәгеләрдән гыйбарәт: телне вакыт ягыннан билгеле бер эзлеклелек нисбәтендә өйрәнү; уртак тел материалында, махсус күнегүләр җыелмасы ярдәмендә өйрәтү. Сөйләм эшчәнлегенең төрләренә өйрәтү махсус күнегүләр сериясе ярдәмендә башкарылырга тиеш.

**Әдәбият исемлеге**

1. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: «Хәтер» нәшрияты, 2001.

2. Туган тел (татар теле). 6 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы Андрей Шляпкин]. – Казан, 2020. – 172 б.: рәс. б-н.

3. Туган тел (татар теле). 6 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов; [рәссамы А.Б. Шляпкин]. – Казан, 2020. – 192 б.: рәс. б-н.



# СҮЗНЕҢ ТАМЫРЫ

## *(2 нче сыйныфта татар теле дәресе)*

**Люция ЮНЫСОВА,**

Буа районы Алших урта мәктәбенең I квалификация категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы

**Максат:**
**–** укучыларны сүзләрнең тамырын табарга өйрәтү;
**–** укучыларның уйлау, фикерләү сәләтен, иҗади активлыгын, дөрес язу күнекмәләрен үстерү;
– балаларда үзара дуслык, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне «ачу» дәресе.

**Җиһазлау:** дәреслек, дәфтәр, көндәлек, карточкалар, таблица, презентация.

**Эш төрләре**: фронталь, индивидуаль, төркемләп, парлап эшләү.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы**

Эшкә кызыксыну тудыру. **(2 нче слайд)**

**Укытучы.** Хәерле көн, балалар! Дәресебезне түбәндәге сүзләр белән башлап җибәрәсем килә:

Тыныч үтсен көнебез!
Көләч булсын йөзебез!
Дөрес, матур утырыйк,
Тырышып җавап бирик!

Балалар, сезгә күтәренке кәеф, уңышлар телим.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

Фронталь эш. **(3 нче слайд)**

**Укытучы.** Ә хәзер уйнап алабыз. Менә сезгә сүзләр: *күз, яңгырлы, килде, салкынча*. Шул сүзләрне кулланып, кайсыгыз матуррак, төгәлрәк җөмлә төзеп күрсәтер икән?

**Укучылар.** Салкынча көз килде. Вак-вак яңгырлары белән салкынча көз килде. Салкынча көз яңгырлар алып килде.

**Укытучы.** Булдырдыгыз, укучылар! Ә иң матур җөмлә кайсыбызныкы булды соң? Барыбыз да матур җөмлә төзеде. Менә Алиянеке аеруча игътибарга лаек булды.

Җөмләләрне нәрсәләрдән төзедек?

**Укучылар.** Сүзләрдән.


**Укытучы.** Әйтегез әле, сүз турынданиләр беләсез?

**Укучылар.** Сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзеп була. Сүзләр авазлардан тора. Бер генә аваздан торучы сүзләр дә була.

**Укытучы.** Әйтеп карыйк әле: *у, и, ә.*

**III. Уку мәсьәләсен кую**

**Укытучы.** Экранга карагыз әле. **(4 нче слайд)** Хәзер сезнең белән бер ребус чишеп алыйк әле.




**Укытучы.** Нинди сүз килеп чыкты?

**Укучылар.** Тамыр.

**Укытучы.** Бик дөрес. Ә шул тамыр сүзен кушып һәм алдан сүзләр турында сөйләшкәннән соң, бүгенге темабызны әйтеп бирә алырсызмы?

**Укучылар.** Сүзнең тамыры. **(5 нче слайд)**

**Укытучы.** Дәресебезнең максаты нидән торыр соң?

**Укучылар.** Сүзләрнең тамырын таба белергә өйрәнербез, фикерләргә, уйларга тырышырбыз һәм тагын әле дуслык, ярдәмләшү турында сөйләшербез.

**Укытучы.** Бәяләү таблицасын тутыру безнең бурычыбыз булып тора. *(Таблицаны тарату.)*

Әгәр дә сез дәреснең темасын, максатын куя алдым дип уйласагыз, бәяләү таблицасында үзегезгә бер балл куясыз.

**IV. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү**

**Укытучы.** Уйлагыз әле, нәрсә соң ул тамыр? Нәрсәләрнең тамырлары була икән?

**Укучылар.** Кан тамыры, үлән тамыры, нәсел тамыры һ.б.

**Укытучы.** «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *тамыр* сүзенең 16 төрле аңлатмасы бар. Без аны хәзер Интернеттан, сүзлекләрнең электрон фондына кереп, карап китә алабыз. *(Электрон сүзлеккә сылтама куела.)* **(6 нчы слайд)**

**V. Яңа тема өстендә эш**

**Укытучы.** Ә хәзер экранга карыйбыз һәм текстны укыйбыз. **(7 нче слайд)** *(һәр төркемнән бер укучыдан укыту.)*

Очрашканнар, ди, агач тамыры белән сүз тамыры:

– Исәнме. Мин тамыр! Ә син кем? – дигән агач тамыры.

– Мин дә тамыр! – дигән сүз тамыры.

– Син нинди тамыр инде. Миннән зур агачлар үсә, синнән нәрсә үсә ала дигән?

– Миннән яңа сүзләр үсә ала! – дигән сүз тамыры.

**Укытучы.** Сез нәрсә укыдыгыз?

**Укучылар.** Әкият, текст...

**Укытучы.** Әкият икәнлеген кайдан белдегез?

**Укучылар.** Бу өзектә агач тамыры белән сүз тамыры сөйләшә.

**Укытучы.** Шулай, дөрес. Агач тамырын беләм, ә сүз тамыры нәрсә һәм ул ничек үсә?

**Укучылар.** Яңа сүзләр белән үсә. Ул яңа сүзләрне тамырдаш сүзләр дә дип атыйлар.

**Укытучы.** Ягез, балалар, без дә сүз үстереп карыйк әле! *(Карточкалар белән эшләү.)*

**Төркемнәрдә эш.** «Яңа сүзләр» уены.

**1 нче төркем.** Юл *(юлчы, юлдаш, юлсыз, юллар)*.

**2 нче төркем.** Иптәш *(иптәшләр, иптәшем, иптәшсез, иптәшле)*.

**Укытучы.** Менә никадәр яңа сүзләр яки тамырдаш сүзләр килеп чыкты.

**Ял итү**



**Укытучы.** Ял итеп алабыз, укучылар. Уен «Дустыңны макта» дип атала. **(8 нче слайд)** Кулны кулга куя барып, бер матур җөмлә төзеп, дустыңны мактарга кирәк була. Бер-беребезне яратып, мактап яшик, дусларым. Мисал: *Минем дустым Дилә – акыллы кыз...* Дәвам итәбез.

Дуслык турында берәр мәкаль дә әйтик әле.

**Укучылар.** Дустың үзеңнән яхшырак булсын. Чын дуслык – зур байлык.

**VI. Уку мәсьәләсен чишүне дәвам иттерү**

Парларда эш.

**Укытучы.** Мин сезгә хәзер карточкалар бирәм. Җөмләләрдәге сүзләрнең тамырын табыгыз һәм астына сызыгыз.

**1 нче төркем.**

– Исәнме, мин тамыр! Ә син кем? – дигән агач тамыры.

– Син нинди тамыр инде. Миннән зур агачлар үсә, синнән нәрсә үсә ала? – дигән.

**2 нче төркем.**

– Мин дә тамыр! – дигән сүз

тамыры.

– Миннән яңа сүзләр үсә ала! – дигән сүз тамыры.

*(Җаваплар документ-камера белән тикшерелә.)*

**Укытучы.** Укучылар, бу тамыр сүзләрне тагын башка мәгънәле кисәкләргә бүлеп буламы?

**Укучылар.** Юк.

**Укытучы.** Ә тамыр сүзләр сүзләрнең төп мәгънәсен аңларга ярдәм итәме?

**Укучылар.** Әйе.

**Укытучы.** Димәк, укучылар, сүзнең тамыры турында нинди нәтиҗәгә килә алабыз?

**Укучылар.** Сүзнең төп мәгънәсен аңлата торган һәм башка мәгънәле кисәкләргә бүленми торган кисәге тамыр булыр.

**Укытучы.** Ә хәзер дәреслекнең 101 нче битендәге кагыйдәне укып, үзебезнең нәтиҗә белән чагыштырып үтик әле.

**Укытучы.** Тамырның тамгасы ничек икән? Кайсыгыз миңа тактада язып күрсәтә ала? *(Бер укучы тактада яза.)*

**Укучылар.** Тамыр сүзләр дуга (⌒) белән тамгалана.

**Укытучы.** Бәяләү таблицасында үзебезгә бәя куябыз.

**Индивидуаль эш**

**Укытучы.** Укучылар, монда язылганны укыгыз.

**Укучылар.** Дуслык таулар күчерә.

**Укытучы.** Нәрсә укыдык?

**Укучылар.** Мәкаль.

**Укытучы.** Парларда бер-беребезгә мәгънәсен аңлатыйк әле.

**Укучылар.** Дус булсак авыр эшләр дә эшләнә.


**Укытучы.** Мәкальне дәфтәргә язабыз, сүзләрдәге тамырны дуга белән күрсәтәбез. *(Дәфтәрләрдә эшлиләр. Җаваплар документ-камера белән тикшерелә.)*

**VII. Рефлексив бәяләү этабы**

1. Рефлексив кабатлау.

**Укытучы.** Бүген дәрестә алган белемнәрне модельләштереп куябыз.

Укучылар, без тамыр турында нәрсәләр белдек?




2. Бәя. Үзбәя.

**Укытучы.** Бәяләү таблицасында үзебезгә бәя куябыз.Әгәр 5 балл җыелса, «5»ле куясыз, 4 балл «4»ле була, 3 балл куйган булсагыз, әлбәттә, «3»ле куябыз. Тик мин безнең арада андыйлар юктыр дип уйлыйм.

**VIII. Өй эше**

1. Дәреслектәге 103 нче күнегүне эшләп килергә. *(Мәҗбүри)*
2. Дуслык турында өч мәкаль язарга, тамырын билгеләргә. *(Иҗади)*
3. Тамырдаш сүзләр кулланып, дуслык турында хикәя язарга. *(Иҗади)*

**Укытучы.** Укучылар, дус, тату булыйк. Бер-беребезгә ярдәм итик. Дусларыгызны татарча котларга онытмагыз. Туган телебез – татар телен кадерлик, яклыйк, саклыйк.



# ШИГЪРИ ҖАНЛЫ УКЫТУЧЫМ

*Укытучылар һәм остазлар елы*



**Гөлия ЧИГВИНЦЕВА,**

Әгерҗе районының
Бертуган Бубилар исемендәге
Иж-Бубый урта мәктәбенең
рәсем һәм технология
укытучысы

Дөньяда һәр кешенең иң матур, иң җылы истәлекләре аның бала чагы белән бәйле була торгандыр. Иң күңелле, кызыклы хатирәләр исә мәктәп елларына барып тоташа. Мәктәп диюгә, күз алдына укытучы килеп баса. Ә мин исә яраткан укытучым Нәсимә Мидехәт кызы Сипованың дәресләренә бик еш әйләнеп кайтам.

Укытучы булу җиңел түгел. Әлеге хезмәт зур сабырлык та, балаларга карата олы мәхәббәт тә, сайлаган һөнәреңә карата чиксез бирелгән булуны да таләп итә. Ә минем остазым – боларның барысына бердәй ия булуы өстенә, нечкә күңелле, шигъри җанлы олы шәхес тә. Ул үзе бу халәтен «Мин Әгерҗе районының Барҗы авылында туганмын. Су астында калган авылымның сихри табигате, әти-әниләргә, авылдашларыма булган тирән хөрмәтем, сагыну моңнары булып, шигырьләремә күчә», – дип аңлата. Чыннан да, аның шигырьләрендә туган як табигатенең гүзәллегенә соклану да, яшьлекне, сабакташларны сагыну да, әти-әниләргә мәдхия дә, тормыш, заман турында фәлсәфи уйланулар да, борчылулар да бар. Укытучым иҗатында Иж-Бубый авылын бөтен дөньяга таныткан бертуган Бубилар темасы да бар.

*Мөхлисәне биргән Бубый*
*җире,*
*Сокланырлык рухи*
*мирасың.*
*Бик тә килә яктылыгын*
*аның*
*Киләчәккә алып барасы,* –

дигән шигъри юллары бүген дә мәгърифәтчеләргә багышланган бик күп кичәләрдә яңгырый. Бераз алга китеп, шунысын да әйтим: бәлки, нәкъ шушы юллар мине, технология һәм рәсем укытучысы буларак, Бубилар белән бәйле яңадан-яңа композицияләр ясарга этәрәдер дә. Мөгаллимә Мөхлисә Бубиның асылмалы эскәмиядә Коръән укып утыру мизгелен сурәтләгәндә дә нәкъ шушы юллар хәтеремә килгән иде бит.

«Укытучылык һөнәрен сайлап ялгышмаганмын. 25 ел буе Иж-Бубый мәктәбендә яратып туган тел фәнен укыттым, күп укучыларымда иҗатка мәхәббәт тәрбияләдем, яшәү мәгънәсен аңлатырга тырыштым», – дигән сүзләр дә минем укытучымныкы.

Чыннан да, мин Нәсимә Мидехәт кызының һәр дәресен түземсезлек белән көтеп ала идем. Әнә ул татар теленең матурлыгы, байлыгы белән таныштыра. Ә без, дөньябызны онытып, аны тыңлыйбыз. Әдәбият

дәресләрендә һәр әсәрне энәсеннән алып җебенә кадәр аңлатып, автор әйтергә теләгән иң кирәкле тәрбияви моментны җиткерә белә иде ул. Шушы әңгәмәләр аша безгә зур тәрбия – тормыш тәрбиясе бирде. Нәрсә начар, нәрсә яхшы – бөтенесен дә тәфсилләп аңлата иде. Китап укырга, матур әдәбиятны яратырга да ул өйрәтте. Үзебез өйрәнгән әсәрләр аша без тормыш, яшәеш асылын аңладык. Дөрес, мин укытучым кебек кулыма каләм алып шигырьләр иҗат итә алмыйм, әмма мин аның кебек үк укытучылык юлыннан китә алуым белән бәхетле. Нинди генә эшкә тотынсам да, Нәсимә Мидехәт кызының якты йөзен, алай гына да түгел, туган телебезгә, милләтебезгә мәхәббәт тәрбияләү, матур гореф-гадәтләребезне буыннан-буынга тапшыру уе белән янган очкынлы күзләренең яктысын тоям. Шуңадырмы, үзем белем бирә торган балаларым белән технология дәресләрендә нәрсә генә ясасак та, аларга кул җылысы белән бергә күңел яктылыгын да салырга өндим. Чөнки укытучыбыз безне һәр нәрсәдә матурлык күрергә өйрәтте. Ә инде үзебезнең татар курчакларын ясый башласак, укытучымның татар кызлары, милләтебез турында әйткән шигъри юллары хәтеремә килә:

*Татар кызы ак калфактан,*
*Назлы әйткән һәр сүзе.*
*Кояшны да гашыйк итәр*
*Тулган ай кебек йөзе...*

Укытучымның менә шушы юллары, әлбәттә, курчак образын да нәкъ шигырьдәгечә гүзәл һәм кабатланмас итеп тудырырга этәрә.

Менә шулай шигъри җанлы укытучым мине гомерем буе өйрәтә һәм тәрбияли килә. Аның кебек укытучылар күбрәк булса, яңа буын да күпкә тәрбиялерәк булыр иде дип уйлыйм. Шундый укытучыда укып, дөрес тәрбия алып, аның эшчәнлеге яктылыгында хезмәт итүем белән бәхетле мин. Барысы өчен дә зур рәхмәт сезгә, мөгаллимәм! Язмамны укытучымның «Дәвам – балаларда...» исемле шигъри юллары белән тәмамлыйсым килә:


*Эш калдыру җирдә – изге гамәл,*
*Җылы эзең калсын юлларда.*
*Гомер иткән эш коралың калсын*
*Ышанычлы, тырыш кулларда.*

Без мөгаллимәбез узган җылы һәм кабатланмас эздән тайпылмыйча атларга тырышырбыз, ул – өйрәтүчебез дә, юл күрсәтүчебез дә.

13



# ТАРИХТА ҖУЕЛМАС ЭЗЕ БАР



**Ләйсән НИГЪМӘТУЛЛИНА,**

Арча районы Социалистик Хезмәт Герое Габдрахманова Стелла Закиевна исемендәге Яңа Кенәр урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Җуелмас эзләр... Тарих... Мәктәп... Укытучы... Шул рәвешле үткәннәр белән киләчәк тоташа. Бер гасыр узуга карамастан, туган мәктәбемнең диварлары бала-чаганың күпме күңелле тавышын үзенә сеңдергән, күпме күңел җылысы, изгелек бөркелә ул диварлардан! Ә инде мәктәпкә җан өрүче укытучыларны искә төшерсәң, күңелне горурлану, соклану хисе биләп ала. Әйе, бүгенге көндә үзем акрын гына алар сукмагыннан атлап барсам да, дистәгә якын «Мәгариф отличнигы» исемен йөртүче, бер Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган укытучыларым булуы белән горурланам, аларның рухи яктан көчле, сабыр, ышанычлы булуларына сокланам.

Яңа Кенәр мәктәбе – гасыр кичкән мәктәп. Ул үзенең укытучылары, укучылары белән чын мәгънәсендә горурлана. Авыр, фаҗигале вакыйгалар дулкынында кайнаган һәм нинди генә сынауларга да бирешмичә хезмәт куйган мөгаллимнәрем күз алдына килә. Рәгыйб Усман улы Халитов – РСФСРның атказанган укытучысы, Бөек Ватан сугышы ветераны, егерме елдан артык мәктәп директоры булып эшләгән көчле шәхес. Сабыр, тырыш Фәния апа – Рәгыйб абыйның тормыш иптәше, үзенең моңлы тавышы, серле сөйләме белән таң калдырган, тәҗрибәле татар теле укытучым. Татарстанның атказанган укытучылары – Хәбир Фәйзрахман улы Габдрахманов, Рәфыйк Гатаулла улы Гатауллин, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Диләрә Әсәт кызы Иванова, 35 елдан артык балаларга белем биргән, Ленин ордены, Почёт Билгесе кавалеры, Социалистик Хезмәт Герое Габдрахманова Стелла Зәки кызы... Үзенең бар гомерен балалар укытуга, киләчәк өчен алмаш тәрбияләүгә багышлаган әлеге шәхесне һәркем зур хөрмәт белән телгә ала. Мәктәбебез 2022 елдан Социалистик Хезмәт Герое Габдрахманова Стелла Зәки кызы исемен йөртә.

Ә хәзер авыл мәктәбе, замана баласы, замана укытучысы дибез... Чыннан да, техника, ясалма интеллект үсеш алган заман укытучы алдында бик зур таләпләр куя. Ләкин баланың күңелен аңлый белүче, белемгә омтылыш уятучы, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче, кечкенә генә уңышларын да күреп сөенүче укытучыны бер генә супертехника да, электрон мәктәп тә алыштыра алмый. Яхшы укытучы энҗе бөртегенә тиң, кайда гына булса да, үз сыйфатларын югалтмый. Кояш юмартлыгы белән күңел җылысы өләшә, пәйгамбәрләр ихласлыгы белән белем тарата, аналар сабырлыгы белән шәхес тәрбияли.

Нинди заманда гына яшәсәк тә, татар теле укытучысы ана теле сакчысы булып кала. Хәзер бертуктаусыз зарланабыз, фәнебезне кирәккә санамыйлар, әдәби китаплар укымыйлар, методик ярдәм юк дибез, ләкин алай түгел бит. Эзләнү, өйрәнү

өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Интернет киңлекләрендә, башка фәннәр белән беррәттән, тел һәм әдәбият укытучылары өчен бик күп сайтлар бар.

Минемчә, педагогик стажы булган һәр укытучы, үзенә генә хас эш алымнары кулланып, иҗади рәвештә эшли. Педагогик технологияләрнең төрлесен тикшереп карый, аларга үзгәрешләр кертә, кечкенә ачышлар ясый. Хаталар да ясый, әлбәттә. Шулар нәтиҗәсендә аның «үз технологиясе» туа.

Мин сезне үз тәҗрибәмдә кулланган һәм уңышлы дип санаган бер алым белән таныштырасым килә.

«Укучылары үз укытучысыннан аның төп вазифасы турында сорыйлар. Укытучы җавап бирми, балаларны тауларга алып чыгып китә. Бераз йөргәннән соң, боларның тамаклары кибә. Эчәргә яраклы су чыганагы эзли башлыйлар. Тирә-якта берни табылмый. Кабат укытучы янына кайталар. Акыл иясе – укытучы – балаларга тау артында чишмә барлыгын әйтә. Балалар туйганчы салкын су эчәләр. Укытучыны да онытмыйлар: аңа да салкын чишмә суы алып киләләр. Карасалар, укытучының алдында туп-тулы сулы савыт утыра.

– Сез ни өчен безгә бу суны бирмәдегез? – дип, гаҗәпләнеп сорыйлар балалар.

– Мин үз бурычымны үтәдем, – дип җавап бирә акыл иясе. – Башта мин сезне сусаганчы тауларда йөрттем, аннары су эзләргә мәҗбүр иттем. Чишмәгә юлны күрсәтеп, кыенлыкны чишәргә булыштым. Үзем белән су алуым юкка түгел: моның белән үзең турында алдан кайгырта белергә өйрәнү кирәклеген аңлатырга теләдем.

– Димәк, Сезнең төп вазифагыз – проблеманы тудыру, аны чишәргә булышу һәм үрнәк күрсәтүме? – дип сорый укучылар.

– Хөрмәтле хезмәттәшләр, ә менә сез укучыларның соравына нәрсә дип җавап бирде дип уйлыйсыз? Укытучының төп бурычы нидә? **(Минем төп бурычым – сездә кешелеклелек һәм киң күңеллелек тәрбияләү. Кайгыртучанлык күрсәтеп, миңа эчәргә су алып килүегез минем үз бурычымны әлегә кадәр төгәл башкара алуым турында сөйли...**)»

Укытучы мисалыннан күренгәнчә, чыннан да, бүгенге тел һәм әдәбият укытучы алдында да йөз, мең еллар элек куелган, бүгенге көндә бик аксый торган бурыч тора: кешелекле, игелекле шәхес тәрбияләү. Аның өчен без бала белән үткәргән һәр минутыбызны, һәрбер дәресебезне тәрбия дәресе итеп карарга бурычлы. Шуны истә тотып, без һәр әдәбият дәресен бала өчен кызыклы, алар чишә алырдай проблемалар белән «бизәп» төзергә тырышабыз. Әлбәттә инде, төп булышчым булып, Риза Фәхреддиннең балаларга багышланган үгет-нәсыйхәтләре тора. «Кешенең матурлыгы – аның тәрбияле, эшчән, намуслы булуында, олыларны олы, кечеләрне кече итеп яши белүендә» икәнлеге дәрестән дәрескә сеңдерелә бара. Алга таба үземнең дәресләрдә

Риза Фәхреддин әсәрләрен куллану тәҗрибәсе белән уртаклашасым килә.

Ана һәм бала... Гасырлардан-гасырларга күчеп килә торган мәңгелек проблема. Әлеге тема татар әдәбиятында тоташ кызыл җеп булып сузылган. Һәр сыйныфта диярлек, укучы әлеге проблема белән очраша, аны чишү юлларын эзләү өстендә эш алып бара. 9 нчы сыйныфта укучылар күренекле язучы Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәрен яратып укыйлар. Андагы геройларның хис-кичерешләрен, уйлануларын үз йөрәкләре аша үткәреп карыйлар. Укытучы буларак, мин балаларга «ана хакы» төшенчәсен җиткерү өстендә эш алып барам. Әсәрдәге Бибинур, аның иреннән калган өч баласы арасындагы мөнәсәбәтләрне анализлаганда укучыларга Р.Фәхреддиннең «Тәрбияле ана», «Тәрбияле бала», «Ата-аналар белән аралашу әдәпләре», «Туганнар белән аралашу әдәпләре»ннән мисаллар китерәм.

Мәктәп программасында шагыйрь Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы өйрәнелә. Укучыларның бәхәсле фикерләре төп геройлар – Зөбәйдә һәм Мәхмүт образларына карата мөнәсәбәттә чагылыш таба. Аларны Фәхреддин хезмәтенең «Никах вә өйләнү» бүлеге белән таныштыру, әңгәмә кору дәресләренең нәтиҗәлелеген күтәрә, балаларны мөстәкыйль тормышка әзерли. «Никах һәр милләтнең нигезедер. Никахлашып өйләнешү бетсә, милләт тә бетәр, бу бер илаһиканундыр», – ди Риза Фәхреддин. Әлеге дәресләрдә шулай ук бүгенге көндә һәр мөселман гаиләсен борчыган олы тема – катнаш никахлар темасы да күтәрелә. Татар гаиләләрендә тәрбияләнүче балалар арасында бу тема да шактый бәхәсле урынны биләп тора. Берәүне дә үпкәләтми генә проблеманы ничек уңай якка чишәргә? Кулыбызда Риза Фәхреддиннең «Өйләнү әдәпләре» әсәреннән китерелгән юллар: «Иргә барган чагында ир булачак кешенең акчасыннан элек холкын, нәселеннән элек динен, гүзәллегеннән элек һөнәрен сорагыз вә үзегезгә тиңдәш булганнарны сайлагыз». Яшьләребезнең башка дин вәкилләре белән никахка керүе массакүләм төс алган заманда укучының күңеленә Риза Фәхреддин киңәшләрен җиткерү үзе үк актуальлек түгелмени?

Сүземне тәмамлап әйтәсе килгән фикерем шулдыр: күренекле галим, мәгърифәтче, олуг педагог Риза Фәхреддиннең кайсы гына әсәрен алма, аларның һәркайсы бүгенге көндә шәхескә җитешмәгән тәрбияне тулыландыруда иң актуаль хезмәт буларак кулланыла. Бу хезмәтләр – бөртекләп җыелган җәүһәрләр...

Хөрмәтле мөгаллимнәр, һәр көн укучыларыбызның күңелләренә миһербанлык, хаклык, мәхәббәт орлыклары чәчик, милли рухыбыз белән сугарыйк, шытып чыккан хисләрне күңел җылыбыз белән саклап кына үстерик. Еллар узгач, бу үсентеләр, һичшиксез, чәчәк атарлар, җимешләре белән куандырырлар.

14



# УКЫТУЧЫ ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛЫЙ

**Гөлназ МУЛЛАГАЛИЕВА,**

Актаныш районы
Пучы урта мәктәбенең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Мәктәп ул – җәмгыятебезнең, уңышлы яшәвебезнең, алга баруыбызның нигезен билгели. Татар мәктәбе – татар халкының иминлеген, телен, мәдәниятен саклаучы һәм үстерүче оешма.

Хәзер җәмгыятебез глобаль үзгәрешләр чоры кичерә, көнләп түгел, сәгатьләп үзгәрә. Яңадан-яңа мәгълүмати технологияләр кертелә. Хәзерге заман кешесенә шушы темпка ияреп бару өчен, мәктәптәге укучыларны укыту һәм тәрбияләү шартларын да үзгәртергә кирәк була. ФДББС шартларында балаларны бүгенге көн таләпләренә җавап бирердәй, көндәшлеккә сәләтле, һәрьяклы үсешкә ирешкән шәхес итеп тәрбияләү көнүзәк мәсьәлә булып тора.

Моның өчен укытучы заман белән бергә атларга тиеш. Яшерен-батырын түгел, кәгазь боткасына күмелгән татар теле һәм әдәбияты укытучысының газета-журнал укырга да вакыты калмый, ә хәзерге көн әдәбияты белән хәбәрдар булу турында сүз дә юк. Бу очракта ул әдәбият һәм мәдәният өлкәсендәге көн кадагына суга торган яңалыклардан мәхрүм.

XX гасыр ахырындагы тел һәм әдәбият фәннәрен укыту белән хәзерге көндәге укыту системасының аермасы нидә соң? Бу чордагы укытучы әзер материалны үзе бирә, кагыйдәләрне ятлата, күнегүләр эшләтә иде. Максатны да үзе куеп, нәтиҗәләрне үзе ясады, укытучы-укучы хезмәттәшлегенә басым ясалмады, дидактикага өстенлек бирелде. Хәзерге интерактив-мәгълүмати технологияләр алга киткән чорда укучы матур әдәбият әсәрләрен укымый, чөнки әзер материалны Интернет киңлекләреннән табарга була. Әдәби әсәрне кулына тотып укымаган, андагы геройларның хисләрен үз күңеле аша кичермәгән укучыны әсәр дулкынландыра алмый. Билгеле, безнең монда хәзерге буын язучыларының колагына да әйтәсе фикерләребез бар. «Гаеп атта да, тәртәдә дә бар», – диләр. Ни өчен З. Кадыйрованың китапларын бирелеп кулдан-кулга йөртеп укыйлар, ә кайбер профессиональ язучыларның әсәрләре читтә кала килә.

Хәзерге көндә 10–11 нче сыйныфлардагы әдәбият дәресе атнага 1 сәгать кенә калдырылды. Әдәби әсәрне бер-ике сәгать эчендә генә бөтен нечкәлеге белән укучы үзләштереп бетерә алмый. Гомумән, туган тел әдәбияты дәресенең атнага 1 сәгать кенә калуы, әдәби әсәрләрнең саны күп булуы аркасында аларга тиешле дәрәҗәдә анализ ясап, нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек калмый.

ФДББС шартларында социальләштерү һәм коммуникациягә басым ясау укытучыга зур җаваплылык өсти. Бүгенге көндә укытучы-укучы хезмәттәшлегенә басым ясала. Мөгаллим дәресләрдә балаларда яңа белемне үзләштерүгә кызыксыну, мотивация уятырга тиеш. Укытучыдан балага дөрес юнәлеш бирерлек дәрәҗәдәге киң эрудициялелек, укучыны үз артыннан ияртерлек югары һөнәри осталык таләп ителә.

Бу очракта укучы, максатны үзе куеп, аерым бер нәтиҗәгә ирешәчәк. «Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк» гыйбарәсен дә күз уңыннан ычкындырмаска кирәк. Яңалык артыннан куып, үткәндәге уку-укыту алымнарын да гамәлдән сызып ташларга тиеш түгелбез. Чөнки хәзерге укыту системасында кулланыла торган алымнар М. Мәхмүтовның проблемалы укыту алымына нигезләнгән ич. XX гасыр ахырында әдәбият дәресендә әсәрләрне уку, аны анализлау барышында тәрбиялелек беренче урынга куела иде, бу чорда сәясәтнең әдәбиятка тәэсире көчле иде, ә хәзерге шартларда тәрбиягә тиешле дәрәҗәдә игътибар ителми кебек. Тәрбия һәм белем бергә алып барылса гына, ниндидер нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Әдәби әсәрләр аша телебезгә мәхәббәт тәрбияләнгәнен онытмасак иде. Мәктәп программасына кертелгән туган тел әдәбияты буенча материаллар кайбер сыйныфларда артык фәнниләштерелгән. Яңа ФДББС таләпләренә туры китерелгән 2023 елда 5 нче сыйныф программасына кертелгән әсәрләрне дә уңышлы дип әйтеп булмый. Гади, халыкчан, хәзерге көн укучыларына барып җитәрлек, аларны дулкынландыра торган әсәрләр бирелсә, күпкә отышлы булыр иде. Чөнки бүгенге көндә балаларда әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Ә югары уку йортларында укытылырга тиешле фәнни терминнар, киресенчә, аларны әдәбияттан читләштерә. Дәреслекләрдәге әдәби әсәрләр дә укучыларның яшь үзенчәлегенә туры килеп бетми кебек.

Хәзерге көндә мәктәпләрдә белем бирүче татар теле һәм әдәбияты укытучыларына бик күп вазифа һәм бурычлар йөкләнгән. Ә сыйныфтагы барлык балаларның да мөмкинлекләре, үзләштерү дәрәҗәләре төрлечә булганлыктан, сыйфат артыннан куу нәтиҗәсендә, бер төркем укучылар күләгәдә кала бирә. Мондый хәл булмасын өчен, укучы фикеренә колак салып, дәресләрне дискуссия формасында оештыру отышлы. Шул рәвешле, үземнең дәресләрне балаларның тәнкыйди фикерләү сәләтләрен үстерү максатын күздә тотып оештырам. Чаллы дәүләт педагогика университетының регональ инновацион мәйданчыгында «Сәләтле балалар һәм яшьләргә ярдәм чаралары: гамәлгә ашыру тәҗрибәсе» темасы буенча эшләвем, шул ук уку йорты доцентлары тарафыннан рецензияләнгән «Уеңны уйдырып сал» электив курсы авторлык программасын эшләп, тормышка ашыруым да балалар өчен үтемле һәм файдалы булды дип саныйм. Узган уку елында укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, дәрестән тыш вакытта тылсымлы каләм серләрен өйрәндек. Нәтиҗәдә укучыларымның эшләре «Актаныш таңнары», «Көмеш кыңгырау», «Сабантуй», «Мәйдан» газета-журналлары битләрендә дөнья күрә. «Көмеш кыңгырау» газетасы оештырган бәйгеләрдә укучыларым җиңү

яулыйлар. «Илһам» Бөтенроссия иҗади бәйгесендә бихисап күп укучыларым катнашып, 1 нче һәм 2 нче урыннарны алуга ирештеләр. Т. Миңнуллин, Ф. Садриев, Г. Кариев, Г. Тукай, М. Җәлил укулары һәм конференцияләрендә җиңүче һәм призлы урыннарны, һәр елны «Йолдызлык»-«Созвездие» фестивалендә «Иң яхшы җыр сүзләре» номинациясендә дә мактаулы урыннарны бирмиләр. Үзебезнең район җирлегендә оештырылган Г. Афзал исемендәге «Яшьләр каләме» фестивалендә катнашучылар һәм җиңү яулаучылар саны арта бара. Мәртәбәле, олпат язучыларның кулларыннан бүләк алу балаларны тагын да иҗатка илһамландыра. Укучыларымның иҗади эшләре тупланган «Илһам чишмәләре», «Илһам чишмәм – белем бишегем», «Илһам канатында», «Күңелемдә ургый хисләр» җыентыклары Актаныш басмаханәсе тарафыннан чыгарылды.

Уку елы дәвамында бер төркем балалар белән «Без – фронтовик-шагыйрь Нур Баян варислары» дигән проект өстендә эшләдек. Нәтиҗәдә аларның иҗат җимешләре 360 битлек җыентыкта басылып чыкты. 2022 елның җәендә дәрестән тыш шөгыль вакытында иҗат итеп тупланган эшләрдән «Сүз көче» дип исемләнгән җыентык дөнья күрде. Быелгы җәйге каникулда иҗат белән шөгыльләнүче балаларның аерым җыентыкларын чыгару өстендә эшләргә җыенабыз.

2020/2022 уку елында «Без – сәләтлеләр» дип исемләнгән проект та киң колач белән алып барылды. Шушы проект кысаларындагы эшчәнлегебез нәтиҗәсе тел һәм әдәбият фәннәреннән оештырылган муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиадаларда бер төркем укучыларның җиңүләрендә күренде. Шунысы куанычлы: әлеге олимпиадаларда берничә ел рәттән Алинә Газетдинова, Сөмбел Кашапова, Эльвина һәм Эльза Закировалар алдынгылар сафында бара. Сөмбел Кашапова исә 2021 елда VIII халыкара олимпиадада призлы урын яулады. Әлеге нәтиҗәләр укучыларыбыз белән аңлашып, үзара хезмәттәшлек итү җимешләре дип саныйм.

Мәктәбебездә укыту-тәрбия эше туган телдә алып барыла. Татарстаныбызда 2021 ел – Президентыбыз тарафыннан «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» дип игълан ителгәч, телебезгә дәүләткүләм мөнәсәбәт үзгәрер дип, зур өметләр баглаган идек баглавын. Киләчәктә, алдагы елларда телебезне саклау өлкәсендә уңай үзгәрешләр булыр, телебезгә карата мөнәсәбәт үзгәреп, уку йортларында дәрес саннары артыр дип өметләнәм.

Ә туган тел әдәбияты мөгаллиме – беренче чиратта, балаларда үз-үзләренә ышаныч уятып, кыенлыклар аша җиңүләргә ирешергә омтылыш тудыручы рольдә. Каршылыклар аша уңышларга ирешү укучыны тормыштагы уңышларга әзерли.

16



# «СОЛАБАШ УНИВЕРСИТЕТЫ» МӨДӘРРИСЕ

## *Хәсәнгата Габәшинең тууына 160 ел*

**Ләлә МОРТАЗИНА,**

Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Х.Фәезханов исемендәге Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты

Мәшһүр татар галиме, тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, җәдитчелек хәрәкәте тарафдары Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши 1863 елда Казан губернасы һәм өязе Кече Солабаш авылында (хәзерге Татарстанның Биектау районында) дөньяга килә. Аның әтисе Мөхәммәт Гобәйдулла улы да, әнисе Халия Мөхәммәтшәриф кызы да заманы өчен шактый гыйлемле кешеләр була. Гаилә башлыгы ата-бабалардан кәсеп булып килгән китаплар күчереп язу, кабер ташлары әзерләү белән шөгыльләнгән. Бу исә аңа уртача тормыш кичерергә мөмкинлек биргән.

Хәсәнгатаның әтисе генә түгел, бабалары да зыялы, укымышлы кешеләр була. Бабасы Гобәйдулла бине Кәлимулла 1812–1821 елларда Бохарада белем эстәгән, авылында гына түгел, тирә-юньдә дә яхшы билгеле дин әһеле була.

Хәсәнгатаның беренче укытучылары әти-әнисе булган, алар малайны укырга-язарга өйрәткәннәр, Коръән турында башлангыч мәгълүматны биргәннәр. Унбер яше тулганнан соң, әтисе Хәсәнгатаны Казанга, Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсенә укырга җибәргән. Мәдрәсәгә ул 17 ел гомерен багышлый – баштагы 12 елын белем алса, соңгы 5 елын хәлфә булып, ибтидаи (башлангыч) сыйныфларда укучы шәкертләргә белем бирә.

Мәдрәсәдә укыган чорда Хәсәнгата үзлегеннән дә күп укый, әле бу вакытта мөселман уку йортларының программаларына кермәгән фәннәр буенча гыйлем туплый. Рус телен үзләштерә, математика, география, табигать белеме фәннәрен тирәнтен өйрәнә. Шул чорның күренекле шәхесләре, акыл ияләре, мәгърифәтчеләр Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Мөхәммәтгали Мәхмүдов, Исмәгыйль Гаспралы, Галимҗан Баруди, шәркыятче-галимнәр, профессорлар Иосиф Готвальд, Николай Катановлар белән танышу һәм аралашу кызыксынучан егеткә тагын да тирәнрәк белемнәр тупларга мөмкинлек бирә, киләчәк тормышын һәм эшчәнлегенең юнәлешен билгеләргә ярдәм итә.

Бу елларда ул төрки халыклар тарихы белән кызыксына башлый. Татарларның килеп чыгышы, күчмәннәрнең иген эшкәртүче утрак халыклар белән үзара бәйләнешләрен өйрәнү теләге белән гарәп һәм фарсы чыганакларына, рус тарихчылары Н. М. Карамзин, С. М. Соловьёв һ.б.ның хезмәтләренә мөрәҗәгать итә. Ш.Мәрҗани яшь галимгә үзенең төпле киңәшләрен бирә; остазының хезмәтләрен өйрәнеп, Габәши үзенә бик күп яңалыклар ача, тарих гыйлеме өлкәсендәге күзаллаулары киңәя. Аның алдагы эзләнүләрендә, хезмәтләрендә Ш.Мәрҗанинең тәэсире ачык чагыла – Х.Габәши дә, Ш.Мәрҗани кебек үк, бер үк методологик принципларга таяна, бер үк бурычларны куя. Аның иң атаклы хезмәтләренең берсе «Мөфассал тарих кауме төрки»дә («Төрки халыкларның җентекле тарихы») Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабының йогынтысы

аеруча нык сизелә.

Тарих фәнен өйрәнүнең әһәмиятен ассызыклап, Х.Габәши: «Төрки телдә язылган тарих китаплары бик аз. Танылган галимнәр өчен бу «вак» эш белән шөгыльләнү әдәпсезлек билгесе санала. Минем үземә дә әллә кайчангы вакыйгаларны һәм инде юкка чыккан халыкларның тормышын өйрәнеп вакыт әрәм итмәскә киңәш бирүчеләр булды. (...) Тарих бит кешенең дини яктан һәм рухи үсеше өчен дә зур әһәмияткә ия, шуңа да дини язуларда төрле халыкларның үткәне һәм билгеле шәхесләрнең тормышы турында мәгълүматлар китерелә», – дип яза.

1889 елда Х. Габәши, мәдрәсәдән китеп, агалы-энеле Юнысовларның мөселман балалар приютында дин гыйлемен укытырга алына. Казанда беренчеләрдән буларак, җәдитчә укыта башлый. Бу вакытта яңа ысул нигезендә укыту өчен дәреслекләр бөтенләй булмый, һәм педагог үзе бу эшкә алына – төрле фәннәр буенча уку кулланмалары, педагогика һәм тәрбия мәсьәләләренә багышланган методик әсбаплар («Тәрбияле бала», «Сагълык» һ.б.) яза.

1890 елда Х.Габәши туган авылы Кече Солабашка имам-хатыйп итеп билгеләнә. Ә бер елдан аның улы – татар һәм башкорт профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучыларның берсе Әхмәтсолтан (Солтан Габәши) дөньяга килә. Бу чорда Габәши Казан арты авылларының тарихын ныклап өйрәнә башлый, бер үк вакытта төрки халыклар тарихына багышланган уку китаплары язу эшен дәвам иттерә. 1897 елда ул тарих укытучылары һәм мәдрәсә шәкертләре өчен тәгаенләнгән «Төрек ыруглары», 1899 елда «Мохтәсар тарих кауме төрки» («Төрки халыкларның кыскача тарихы») дәреслекләрен бастырып чыгара. Соңгысы мәдрәсәләргә яңа фәннәр кертә башлаучы «Мәдрәсәи Мөхәммәдия» мөдәррисе Галимҗан Барудиның соравы буенча әзерләнә.

Туган авылында Х.Габәши үз йортында балаларга белем бирү белән шөгыльләнә. Бу вакытта әле татар мәктәпләренә яңа керә башлаган экскурсия ысулын куллана, шәкертләрен Сибириягә, Урал тауларына, Свердловскига һәм Омскига кадәр үк алып бара, бергәләп илне, аның тарихын, табигатен, халыкларын өйрәнәләр. Киң карашлы, төпле акыллы, гыйлемле дин әһеле һәм яңача эш алымнары кулланган мәгърифәтченең казанышларын татар-мөселман җәмгыяте таный – 1895 елда аны Диния нәзарәтенә казый итеп сайлыйлар.

Сәламәтлеге какшау сәбәпле, Х.Габәши кире туган авылына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була (Диния нәзарәтенә казый итеп кабат 1908 елда сайлана), яңа җәдиди мәктәп ачу максатын тормышка ашырырга керешә. Оренбург миллионеры Әхмәт бай Хөсәеновның матди ярдәме белән мәктәп бинасын торгыза, парталар, кара такталар урнаштыра, рус теле, география, тарих, туган тел һ.б. фәннәрне укытуны кертә– кыскасы, чын мәгънәсендә җәдит мәктәбе итеп төзи. Җәдитче заманының иң алдынгы педагогик ысулларын кулланып, гадәти авыл мәдрәсәсен Казан артының үрнәк уку йорты итеп үзгәртеп

кора. Дистәләрчә мөгаллим тәрбияләгән бу мәдрәсәне хәтта «Солабаш университеты» дип тә атый башлыйлар. Нәтиҗә дә озак көттерми: авыл балалары арасында укый-яза белмәүчеләр бөтенләй диярлек калмый.

Икенче тапкыр казый итеп сайланганнан соң, Х.Габәши иҗат эше белән шөгыльләнүен дәвам иттерә, Диния нәзарәте органы булган «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» журналын редакцияләүдә катнаша. Уфада ярлы гаиләләрдән чыккан балалар өчен «Хезмәт сөючеләр йорты», татар балалары өчен һөнәр мәктәбе ача, «Госмания» мәдрәсәсендә укыта. Уфа хәйрия җәмгыятьләрендә әгъза булып тора, «Мөселманнар җәмгыяте»н оештыра, тарих буенча зур эзләнүләренең нәтиҗәсе булган, Евразия халыклары тарихы һәм этнографиясе энциклопедиясе итеп танылган «Мөфассал тарих кауме төрки» хезмәтен бастырып чыгара. Бу китап Россия төрки-мөселман җәмгыяте тарафыннан бик җылы кабул ителә, аның турында татар газеталарында гына түгел, Төркия, Төркестан матбугатында да котлаулар, мәкаләләр басылып чыга.

Хәсәнгата Габәши үзенең дәреслекләрендә яшьләр өчен тарих фәнен өйрәнүнең әһәмияте зур булуын ассызыклый. «Тарих кешегә тәҗрибә һәм дәрес бирә, шулар ярдәмендә ул алдагы тормышында күп кенә күңелсезлекләрдән котыла алачак», – дип саный. Акыллы кеше, ди ул, үткәннәрдән сабак ала һәм бары тик файда китерәчәк гамәлләрне генә кылачак. Шул рәвешле, ул тарих фәненең, беренче чиратта, гамәли ягына игътибар итеп, аның кешелек өчен төп ярдәмче булуы турындагы фикерне үткәрә.

Х.Габәши һәр халыкның, иң беренче чиратта, үз милли тарихын белү һәм өйрәнү кирәклеген әйтә, бары тик шундый гыйлемнәр белән коралланганнан соң гына, башка халыклар тарихына мөрәҗәгать итәргә кирәк дип саный.
Ш. Мәрҗанинең дә бит үз телен өйрәнгән, ислам дине нигезләрен яхшы үзләштергән кешенең башка телләр өйрәнүе, башка илләргә барып, чит милләтләр белән аралашуында файдадан башка берни юк дигән фикере билгеле. Бу очракта Х. Габәши дә милли тарихны татарларны милли рухта тәрбияләүнең үтемле бер чарасы буларак күрә. Шуның өстенә ул барлык төрки халыкларның бер үк уртак тамырдан чыгуларын, уртак мәдәнияткә ия булуларын, бөтендөнья тарихында «бөеклеген» күрсәтергә тели, үз заманының яшь буынын да шул рухта тәрбияләүне, тарихи хәтерне саклауны максат итә.

Октябрь революциясеннән соң Х.Габәши фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнә, төрле уку йортларында укыта, ТАССР Үзәк музееның татар-мөселман коллекциясен туплауда катнаша. 1932 елның гыйнварында кулга алына, Архангельск өлкәсенә төзәтү эшләренә сөрелә. 1936 ел башында сәламәтлеге нык какшаган Хәсәнгата Габәши иреккә чыгарыла. Тик бу вакытта аның инде күп гомере калмаган була – озак та тормый, шул ук елның 7 августында, татарның зур галиме, педагог һәм мәгърифәтчесе Хәсәнгата хәзрәт вафат була. Ул Кече Солабаш авылы зиратына җирләнгән.

16




# НИ ӨЧЕН БУҺӨНӘРНЕ САЙЛАДЫММЫ?



**Лилия ҖӘЛӘЛОВА,**

Буадагы М. Вахитов исемендәге гимназиянең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Мин ни өчен укытучы һөнәрен сайладым, моңа кем этәргеч бирде? Җир йөзендә һөнәрләр бик күп. Башта мең төрле сорау кайный. Кем булырга? Туганнарыбыз арасында «Хәзерге заманда акыллы кеше укытучы булырга хыялланамы?!», «Сеңлем, син нәрсә, әниеңнең төннәр буе дәфтәр тикшереп утыруын күрмисеңме әллә?», «Яхшылап уйла, кызый, үкенерлек булмасын!» диючеләр күп булды. Аларга каршы «Сез беләсезме? Әнием үз эшен бик ярата. Өйгә кайткач та, балаларын сөйләп туя алмый», – дип җавап биргәнем хәтеремдә. Чыннан да, ул вакытка өч дистә ел мөгаллимлек стажы булган әниемнең бер генә тапкыр да уфтанганы булмады бит. Әнием, Әхмәт авылы башлангыч мәктәбендә 38 ел эшләп, лаеклы ялга чыкты. Укытучы һөнәрен сайлавымның төп сәбәбе, мөгаен, әниемнең үз эшенә зур җаваплылык, олы хөрмәт белән каравы булгандыр.

Мин ни өчен укытучы һөнәрен сайладым? Ни өчен татар теле һәм әдәбияты укытучысы? Башлангыч белемне үз авылымда алганнан соң, Яңа Чәчкап урта мәктәбенә килдем. Анда татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә утырулар... Декрет ялына киткәч, укытучыбызны сагынулар, башка укытучыга ияләшә алмыйча йөдәп бетүләр... Аның кабаттан эшкә килүен зар булып көтүләр... Әйе, Гөлсания Насыйр кызы Сәләхова безне серле әдәбият дөньясына алып керде. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, югары уку йортына барырга теләвемне белгәч тә, «Борчылма, син, һичшиксез, укырга керәчәксең», – дип канатлар куйды. Зур рәхмәт аңа. Безне шигърият серләренә өйрәтте, үзе дә шигырьләр яза иде. Әйе, иде... Остазым хәзер якты дөньяда юк инде. Бүген менә истәлекләргә бирелдем, ак дәфтәр битенә төшкән язуымны күз яшьләрем юа. Әйе, мин укытучы һөнәрен сайладым һәм бер тапкыр да моңа үкенгәнем булмады. Миндә туган тел һәм әдәбиятка тирән мәхәббәтне остазым тәрбияләгән икән ләбаса!

Һәр заман, һәр чор үз авырлыклары белән килә. Туган тел әти-әниләр ризалыгы белән укытыла башлагач, татар теле һәм әдәбияты укытучысы зур сынау алдына басты. Укытучы гына түгел, телебез дә авыр хәлдә калды. Бу вакыйгаларга алты ел үтеп бара, ә ул чорда туган балаларның мәктәпкә барыр вакытлары җитә. Ә нәрсә күрәбез? Бала туган телендә сөйләшми, чөнки әти-әни еш кына үзе үк «үрнәк» күрсәтә, телне өйрәтүне кирәксенми, баласына авырлык тудырмас өчен, уңай җаваплы гариза да язмый. Ярый ла баланың әби-бабасы булса, баланы тәрбияләүдә катнашса... Менә шушы өендә бер авыз сүз өйрәнмәгән баланы укытучы ничек итеп сөйләшергә

өйрәтсен дә, ничек итеп телгә мәхәббәт уята алсын соң?! Бу турыда еш уйланам мин. Тагын 10, 20 елдан безне нәрсә көтә? Телебез нинди хәлдә булыр? Мин еш кына 90 нчы еллар ахырында мәктәпне тәмамлаган элекке укучыбызны искә төшерәм. Аның университетны тәмамлап, чит ил кешесенә кияүгә чыгуын, Испаниядә яшәүләрен, ике улының үсеп килүен, чит җирдә әниләренең туган теле – татар телендә аралаша алуларын мисал итеп китерәм. Чит илдә шулай кабул ителгән: бала әти-әнисенең туган телен белергә тиеш! Тик менә бу язылмаган закон безнең милләтебезгә кайчан килеп җитәр дә бездә кайчан милли үзаң формалашып бетәр икән?!

Дөньяны әйләнеп чыгу өчен, 14 телне белү җитә, ди галимнәребез. Шул исемлектә туган телебезнең дә булуы минем күңелемдә горурлык хисләре уята. Менә шуны әти-әниләр дә, балалар да аңласын иде.

Сүз дә юк, яңа буын белем стандартлары кергән чорда, җитәкчеләребез туган тел һәм әдәбиятны башка предметлар белән бер дәрәҗәдә булдыру өчен күп тырышлык куйдылар. Туган телебездә төп дәүләт имтиханнарын тапшыру мөмкинлеге булдыру, яңа программалар төзү, дәреслекләр бастыру, аларны федераль исемлеккә кертү, кулланма әсбаплар – болар барысы да телебезнең җәмгыятьтә лаеклы урынын алу өчен, галимнәр һәм белгечләрнең фидакяр хезмәтен күрсәтә.

2017 елга хәтле укучыларыбыз ел саен татар теле буенча төп дәүләт имтиханы сайлый иде, хәтта эшләрен 100 % ка башкаручылар да булды. Берничә ел тоткарлык булса да, узган уку елында сигез укучымның туган телдән имтихан сайлаулары, уңышлы гына тапшырып чыгулары – минем өчен зур шатлык.

Төрле чараларга әзерләнү, очрашулар уздыру, ачык дәресләр күрсәтү җаваплылык сорый. Эш барышында еш кына 40 елга якын гомерен балалар укытуга багышлаган, хәзер лаеклы ялда булган коллегам – татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия Габделхак кызы Галимовага мөрәҗәгать итәм. Кечкенәдән мөгаллим булырга хыялланган кыз, Кукмара районы Зур Сәрдек мәктәбен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогия институтының татар теле бүлегенә юл тота. Уку йортын тәмамлаган яшь укытучы Буа районына килен булып төшә. Алших урта мәктәбендә, соңрак шәһәребезнең Мулланур Вахитов исемендәге гимназиясендә хезмәт куя. Укучыларында ана теленә һәм әдәбиятына мәхәббәт тәрбияли. Ата-аналар белән нык элемтәдә торып, бөтен күңелен биреп эшли. Тырыш хезмәте өчен коллегамны мәктәп җитәкчелеге, Буа районы администрациясе, мәгариф бүлеге, Мәгариф министрлыгы Мактау грамоталары белән бүләкле. Гомере буе халык педагогикасына нигезләнеп эшләгән педагогка 2003 елда «Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы» дигән исем

бирелде.

Әлфия Габделхак кызы бүгенге көндә дә актив: үзе укыткан укучылары, хезмәттәшләре белән әледән-әле очрашып тора, истәлекләре белән уртаклаша, киңәшләрен бирә. Ул – шәһәребезнең «Гөлҗамал» фольклор төркеме солисты, алып баручысы. Сәнгатьле сөйләм, мөнәҗәтләр бәйгеләрендә катнаша, спектакльләрдә уйный. 2012 елдан бирле уздырылып килүче «Балкыш» республикакүләм фестивале лауреаты. Шундый коллегам-остазым булу белән горурланам мин!

...Әле кичә генә тәүге дәресемне бирдем кебек. Уйлый китсәң, 30 ел вакыт үткән. Район, республика этабы олимпиадалары, укучыларымның минем юлны сайлавы... Гади генә укытучы өчен моннан да зуррак куаныч бармы икән? Ел артыннан ел үтә, гомер уза. Минемчә, укытучы беркайчан да картаймый. Ул һаман укучы яшендә кала. Кечкенәләр белән сабый булып бетсәм, бу уку елында 11 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларым мине яшьлегемә кайтарды. Ел дәвамында «Иң әһәмиятле нәрсәләр» турында сөйләштек. Күпме чаралар әзерләдек; тәрбия сәгатьләрендә әдәп-әхлак, гаилә, сайланачак һөнәрләр турында күпме сөйләшүләр үткәрдек!.. Әдәбият үзе үк тормыш дәреслеге ләбаса.

Күңел биреп, киңәшләшеп башкарган эш кенә җимеш китерә, диләр. Мин бу яктан бик бәхетле укытучы. Яраткан укучыларым, хезмәттәшләрем, белән бәхетле мин. Һәрьяклап булышырга әзер торган хезмәттәшләрем, остазым, сездән башка кем мин? Кирәк чакта киңәшче дә, таләпчән дус һәм гадел тәнкыйтьче дә, нык таяныч та сез миңа. Сезнең белән бер юлдан баруым белән бәхетле мин! Шуңа да уңышларымны күмәк хезмәт җимеше дип санавым юкка түгел. Шулай булмаса укучыларыбыз район һәм республика олимпиадаларында җиңү яулый алыр идеме?! Авырлыкларны бергә күтәргәндә генә эшләве җиңел ул.

Район һәм төбәкара семинарларда күрсәтелгән ачык дәресләр, дәреслекләргә язылган рецензияләр, атналыклар, китап укучылар конференцияләре; Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Кәрим, И. Юзеев, Д. Хәбибуллин юбилейлары уңаеннан район күләмендә үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләр... Ә үз төбәгебезнең Ә. Рәшит, Р. Харис, Р. Рахмани, Г. Айзат кебек бөек затлары белән укучылар күңелендә тирән эз калдырган очрашулар... Гимназия укучыларының «Сабантуй» газетасында басылган шигырьләре...

Укучыларымның туган телне яратуларын, халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен хөрмәт итүләрен телим, аларны һәрьяктан үсешкә ия булган зыялы татар шәхесе итеп тәрбияләүне эшемнең максаты дип саныйм. Максатымны тормышка ашыруда көчемне кызганмам.

17



# ЧЫН ДУС НИНДИ БУЛА?

## *(6 нчы сыйныфның рус төркемендә татар теле дәресе)*

**Римма ГАБСАБИРОВА,**

Баулы районы Поповка урта мәктәбенең I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Максат**:

– үткән дәресләрдә алынган белемнәрне актуальләштереп, «Зәңгәр яфраклар» тексты аша үзара аралашу өчен шартлар тудыру;

– укучыларда әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аның белән аралашу, парларда һәм күмәк эшли белү, тема буенча диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;

– кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә дуслыкның иң мөһим сыйфатларының берсе булуына ышаныч тәрбияләү.

**Бурыч**: укучыларның иҗади фикерләү сәләтен, аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыруга йогынты ясау.

**УУГ**

**Регулятив:**

– укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;

– кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып, гамәлләр кылу.

**Танып белү:**

– тиешле мәгълүматны табу, билгеләү;

– үз фикерләрен дәлилли белү;

– нәтиҗә ясау.

**Коммуникатив:**

– хезмәттәшлектә башкаларның фикерләрен исәптә тоту һәм карашыңны яклый белү;

– бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү.

**Шәхси:**

– үзара аралашу культурасы тәрбияләү;

– үз фикерләрен дәлилли белергә өйрәтү.

**Җиһазлау**: ноутбук, экран, проектор, карточкалар, үзбәя картасы,презентация, колонкалар.

**Материаллар:** 6 нчы сыйныф өчен Р. З. Хәйдәрова авторлыгында татар теле дәреслеге.

**Методлар:** белемнәрне системалаштыру, анализ, проблемалы укыту.

**Алымнар:** карточка белән эшләү, үзбәя картасы белән эшләү, дәреслек белән эшләү, укытучы сөйләме, сорау-җавап әңгәмәсе, рефлексия, критик фикер йөртү.

**Эш төрләре:** төркемнәрдә, парларда эш.

**Дәрес тибы:** белемнәрне системалаштыру.

**Предметара бәйләнеш:** татар әдәбияты, рус әдәбияты.

**Дәрес барышы**

**I. Кызыксындыру**

1. Оештыру, уку эшчәнлегенә мотивация булдыру.

**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар! Сезне күрүемә мин бик шат.

Дуслар елмаеп карaса,
Дөнья яктырып китә.
Я, кайсыгыз дусларына
Елмаю бүләк итә?

– Укучылар, сезнең парталарда **үзбәя** карталары ята. Сез һәр эшкә үзегезгә билге куярсыз. Шуңа күрә дәрестә тырышыгыз һәм актив булыгыз. Сез бик күп беләсез, булдырасыз, укучылар.

2. Дәрес темасын ачу, уку мәсьәләсен кую, проблема формалаштыру.

**Укытучы.** Укучылар, хәзер җыр тыңлап китәрбез. Игътибар белән тыңлагыз. Соңыннан дәреснең темасын билгеләрсез. *(Илшат Сафин башкаруында «Чын дустым» җырын тыңлау.)*

– Укучылар, җыр нәрсә турында? Без дәрестә нәрсә турында сөйләшербез?

**Укучылар.** Чын дуслар турында сөйләшербез.

**Укытучы.** Әйе, ә дуслар һәрвакытта чын дус була аламы? *(Укучылар җавабы.)*

– Әйе, без бу сорауга төгәл җавап бирә алмыйбыз.

– Дәрес ахырында без нәрсә белергә тиешбез?

**Укучылар.** «Дуслар һәрвакыт чын дус була аламы?» соравына җавап алырбыз.

**Укытучы.** Балалар, без нәрсә беләбез һәм нәрсә белергә телибез?

| Мин ...беләм. (Я знаю) | Мин ... белергә телим. (Я хочу знать) |
|---|---|
| татарча укый | текст белән эшли (работать над текстом) |
| тәрҗемә итә | бәя бирә (дать оценку) |
| сорауларга җавап бирә | үзе нәтиҗә ясый (делать вывод) |
| җөмлә төзи | төркемдә эшли |

3. Белемнәрне актуальләштерү һәм уку эшчәнлегендәге авырлыкны билгеләү.

**Укытучы.** Рәхмәт, укучылар. Әйдәгез әле, дуслар турында сөйләшеп алыйк. Сезнең парталарыгызда терәк таблицалар бар, шулар ярдәмендә дустыгыз турында сөйләгез.

| | |
|---|---|
| Синең дустың бармы? Аның исеме ничек? | Әйе, ... |
| Дустың кайда яши? | Казан (Бөгелмә, Лениногорск, Чаллы ...) шәһәрендә, Азнакай (Баулы, Бөгелмә ...) районында, Сугышлы (Кандыз, Иштерәк...) авылында |
| Сез кайда таныштыгыз? | Мәктәптә, экскурсиядә, урамда, кинода, каникулда, уйнаганда... |
| Синең дустың нинди? | Гадел, ышанычлы, ярдәмчел, игътибарлы, алдашмый, миңа булыша, миңа яхшылык кына эшли... |

**Укытучы.** Рәхмәт, менә сезнең дусларыгыз яхшы, тыйнак, ярдәмчел...

– Чын дуска нинди характер сыйфатлары хас була? (Какие черты характера имеет настоящий друг?)

**«Кәрзин» уены**

*(Укучылар кәрзиннән сүзне алып укыйлар һәм тактадагы смайлик астына беркетәләр.)*

*Намуслы, тыйнак, тәрбияле, түземле, ышанычлы, ярдәмчел, игътибарлы, саран, алдакчы, ышанычсыз, ялкау, мактанчык.*



*(Хата булса төзәтәләр.)*

Тәрҗемә итү, нәтиҗә чыгару.

**Укытучы.** Балалар, чын дус нинди булырга тиеш?

**Укучылар.** Намуслы, гадел, ышанычлы, ярдәмчел, игътибарлы, тыйнак, юмарт.

**Укытучы.** Хәзер үзегезгә кабатлау этабына билге куеп чыгыгыз.

**(Үзбәя)**

**II. Төзелгән проектны тормышка ашыру**

**Укытучы.** Узган дәрестә без «Зәңгәр яфраклар» текстын укыган идек. Искә төшерик әле. *(Дәреслекнең 75 нче битен (1 нче күнегү) ачалар.)*

1. Тыңлагыз һәм сорауларга җавап бирегез.

– Текстта сүз кемнәр турында

бара?

– Ленаның нинди карандашы юк?

– Ленага яшел карандаш нигә кирәк?

– Ленаның яфраклары ни өчен зәңгәр төстә?

– Укытучы нәрсә дигән?

2. «Дуслар һәрвакыт чын дус була аламы?» соравына җавап эзлибез.

**1 нче төркемгә** – Лена.




**2 нче төркемгә** – Катя.




**3 нче төркемгә** – Катя һәм Лена.




3. Нәтиҗә ясау.

**Укытучы.** Балалар, дуслар һәрвакыт чын дус була аламы?

**Укучылар.** Юк, дуслар һәрвакыт чын дус була алмый. Без моны Катя мисалында күрдек.

4. Үзбәя.

**Укытучы.** Хәзер үзегезгә бу этапка билге куегыз.

**III. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**


1. Синквейн язу.

**Укытучы.** Балалар, чын дус макетын төзик әле.


**Укучылар.** Чын дус нинди була? Ул нишли? Ул дустына булышамы? Сезнеңчә, аны тагын ничек атап була? (*Бернечә укучыдан язган синквейннарын укыту.)*

2. «Чын дус» макетын төзү.

**Укытучы.** Балалар, парталарыгызда яшел һәм зәңгәр яфраклар ята. Әгәр сез Катя урынында булсагыз, Ленага яшел карандаш бирер идегезме?



– «Әйе, бирәм», – дип уйласагыз, агачка – яшел яфрак, «Юк, бирмим», – дигән фикердә булсагыз, зәңгәр яфрак эләсез. *(Нәтиҗә чыгару.)*



3. Үзбәя.

**Укытучы.** Хәзер үзегезгә, дәрестә ничек катнашуыгызга карап, билге куегыз.

**IV. Өй эше**

1. 79 нчы бит, 7 нче күнегү. Катяга киңәш бирегез.

2. Әгәр Катя чын дус булса, хикәя ничек үзгәрер? Язып карагыз.

3. Чын дустың турында хикәя төзегез.

18




# УКУЧЫЛАРДА ТАТАРЧА ДӨРЕС ЯЗУ ГАМӘЛЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ АЛЫМНАРЫ

**Энҗе ХИРАЗОВА,**

Азнакайдагы 1 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар алдында балаларны аралашуга өйрәтү бурычы төп максат итеп куелса да, язу, телнең грамматик формасы буларак, аралашуда гаять әһәмиятле корал булып тора.Тел грамматик закончалыклар, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәләр белән формалаша. Шуңа күрә урта мәктәп укучысы орфографияне өйрәнү нәтиҗәсендә үз фикерен башка кеше аңлый алырлык итеп, грамоталы язу дәрәҗәсендә өйрәнергә тиеш. Укучының программа кысаларында, тел үзенчәлекләрен үзләштерү дәрәҗәсен тикшереп бәяләү өчен төрле язма эшләр дә каралган. 2–11 нче сыйныф укучылары белән өйрәтү характерындагы язма эшләрдән алып, тикшерү төрләрен үз эченә ала торган күчереп язу, төрле типтагы диктантлар, хикәя, сочинение, изложение кебек язма эшләр оештырыла. Һәрбер эш төре укучыларның яшь үзенчәлекләрен, белем дәрәҗәләрен, грамматик һәм лексик минимумны исәпкә алып үткәрелә. Методика таләп иткәнчә, укучының мөстәкыйль рәвештә башкарган эшеннән соң хаталар өстендә эш оештырылырга тиеш. Әлбәттә, шушы эш төренә килеп җиткәч, укытучы алдында авырлыклар туа. Беренчедән, рус баласы белән бу эшчәнлекне ничек итеп үткәрергә һәм нинди формада? Икенчедән, нинди күнегү төрләрен алырга? Өченчедән, кирәкме бу эш төре? Дүртенчедән, ни өчен бернинди ярдәмлекләр юк? Гомумән, нишләргә? Шушы сораулар үзебезне инде күптәннән борчыганга күрә, эш тәҗрибәмнән чыгып, тупланган эш төрләре, алымнары белән уртаклашырга булдым.

Әлеге эш төрләре укучыларның туган телләре буенча булган белемнәренә таянып, чагыштыру аша алып барыла. Хаталарны булдырмау өстендә эшләү алымнарын, эшчәнлек төрләрен билгеләгәнче, рус милләтеннән булган укучының әлеге хатаны ни өчен ясаганын ачыкларга кирәк:

– ишеткәнчә язуы;

– үзе әйткәнчә язуы;

– укытучы әйткәнне дөрес итеп ишетә алмавы;

– авазларны аермавы;

– авазларның әйтелеш үзенчәлекләрен белмәве;

– әйтелеш белән язылышны бутавы.

Хаталарны исәпкә алу нәтиҗәсендә, аларга анализ ясала һәм классификация үткәрелә. Монда язма эшне үткәргән вакыт, укучының исем-фамилиясе, орфограммалар һәм ялгышлар саны күрсәтелә.

Хаталарны бетерү өстендә эш түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– хата ясалган сүзләргә орфографик һәм фонетик анализ ясала; рус теле белән чагыштырыла;

– өстәмә күнегүләр үткәрелә;

– үзләштереп җиткерелмәгән кагыйдәләр кабатлана; мисаллар китерелә;

– йомшак үзләштерелгән темалар буенча кагыйдәләр ныгытыла.

Укучы, үзенең хатасын күреп, аңлап, анализ ясап, хатасына туры килә торган кагыйдәне куллана белергә тиеш. Укучы аңлы үзләштерү, туган теле белән чагыштыру аша ныклы күнекмәләргә өйрәнергә тиеш. Шул чагында гына алдагы тикшерү эшләрендә ул кирәкле кагыйдәне исенә төшерә алачак.

Укучыларның дөрес язу күнекмәләрен камилләштерү юллары алар күптөрле. Иң кулай һәм уңышлы дип саналган төрләренә тукталып китәсе килә. Иң беренче чиратта, «Башлангыч сыйныфларда нинди эш төрләрен кулланырга мөмкин соң?» дигән сорауга җавап бирик.

1. Орфографик биш минутлыклар. Ул

матур һәм дөрес язуны максат итеп куя.

2. Күчереп язу. Рус телендә сөйләшүче баланы дөрес итеп күчереп язарга өйрәтүдә иң отышлы ысулның берсе. Әлбәттә, күчереп язганда, укучыларга үзенчәлекле текстлар сайлана, нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеге искәртелә, һәрбер эш тикшерелеп бәяләнә.

3. Күчереп язганыңны үзтикшерү, үзара алышып тикшерү.

4. Һәр сүзне иҗекләргә бүлеп язу. Игътибарлылыкны таләп итә торган күнегү.

5. «Ә» хәрефе генә кергән сүзләр язу. Аларның язылышын истә калдырырга тырышып язу.

6. «А» хәрефеннән генә башланган сүзләрне язу. Аларның язылышын истә калдырырга тырышып язу.

7. «А» һәм «о» хәрефләре кергән сүзләрне чиратлаштырып язу (бар-бор, тар-тор). Балаларның игътибарын әйтелешкә юнәлдерергә.

8. Төшеп калган хәрефләрне куеп язу.

9. Сүзләрне күплек санга куеп язу яки, киресенчә, күплек сандагы сүзләрне берлек санга куеп язу.

10. Үзтикшерү күнекмәләрен формалаштыру.

Дөрес язу ул – хатасыз язу дигән сүз. Шуны укучылар аңларга тиеш. Күп очракта хаталар игътибарлылык җитмәгәннән ясала. Укучылар төшенсеннәр: һәр язма эш аның дөреслеге тикшерелгәннән соң гына төгәлләнгән дип санала. Ә укытучы укучыны шушы иң җаваплы эшне үтәү тәртибенә өйрәтергә тиеш. Укучыларга «Ничек хатасыз язарга?» дигән белешмә таратыла (бу белешмә рус телендә дә булырга мөмкин). Анда түбәндәге киңәшләр язылган:

* язганыңны иҗекләп укы, хаталары юкмы;

* тиешле орфограммаларны тап;

* ни өчен шундый хәреф язуыңны аңлат (укучылар даими рәвештә ни өчен шундый хәреф язганнарын аңлата белергә өйрәнергә тиешләр);

* хаталар булса төзәт;

* икеләнсәң, хәреф өстенә сорау билгесе куй.

Бу эшне укучы һәрвакыт кулына карандаш тотып башкара. Укучыларның язма эшләрендәге хаталарны төзәтү өйрәтү рәвешендә оештырыла. Үз-үзеңне тикшерү эшенә өйрәтү генә түгел, аңа күнегү дә мөһим, шул очракта гына бала, аңлы рәвештә үз язуын тикшереп, хатасын таба һәм төзәтергә өйрәнә ала.

Үз-үзеңне тикшерү юллары:

– хата җибәрелгән сүзнең яки хәрефнең астына сызу;

– хаталы сүзнең астына сызарга, ә поляда шартлы тамга белән дөрес язылмаган морфеманы күрсәтергә;

– поляда сүзнең дөрес язылышын күрсәтергә;

– поляга дөрес хәрефне язарга;

– хатаны кайсы юлдан эзләргә икәнлеген генә күрсәтеп поляда тамга куярга;

– булдыра алганча, кагыйдәне күрсәтергә.

Башлангыч сыйныфларда укучыларда күчереп язу күнекмәсе тиз генә барлыкка килми. Шуңа күрә татар теле һәм рус теле дәресләрендә балаларны бер үк алгоритм белән эшләтү уңай нәтиҗә бирә. Үрнәк буларак менә шушындый эш тәртибе тәкъдим итәргә мөмкин:

1. Җөмләне укыйм һәм тыңлыйм.

2. Һәр сүзне иҗеккә бүләм.

3. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән иҗекләрне билгелим.

4. Сүзне орфографик яктан дөрес итеп берничә тапкыр укыйм. Сүзне яки җөмләне каплап ничек язачагымны күз алдына китерәм (сүзне яки җөмләне кабатлыйм).

5. Сүзне яки җөмләне язам.

6.Тикшерәм.

5–9 нчы сыйныфларда исә хаталар өстендә эш төрләре бераз катлауландырыла. Түбәндәге эш төрләре тәкъдим ителә:

1. **Фәнни яктан аңлату** (русча да булырга мөмкин). Таблица ярдәмендә үткәрергә мөмкин:

| № | Хаталы сүз, сүзтезмә яки җөмлә | Кирәкле кагыйдә | Үз мисалым |
|---|---|---|---|
| 1. | Урам*л*ар | Иҗек ахырында яки сүз ахырында -м, -н, -ң хәрефләре булса, -нар/-нәр кушымчалары языла. | Көннәр Урманнар |

2. Орфографик сүзлекләр белән эшләү. Даими эшләү күзәтүчәнлекне арттыра, күрү хәтере аша язылышы авыр үзләштерелә торган сүзләрне укучы хәтерендә ныгыта.

3. Үзара тикшерү.

4. Әдәби әсәрләрне укыганда өйрәнгән грамматик материалны искә төшереп алу, мисаллар табу.

5. Газета-журналлардан кирәкле сүзләрне эзләп табып язу.

6. Күрсәтмәлелек куллану. Төгәлрәк әйткәндә, сүз күрсәтмә материалларның иң киң таралган бер төре – дөрес язуга өйрәтүдә таблицаларны дәрестә куллану турында. Таблицаларның укучының игътибарын җәлеп итәрлек, кызыксыну уятырлык булуы шарт. Укытучының эзлекле сорауларына таянып, бирелгән таблица ярдәмендә, укучы нәтиҗә чыгарып, гомумиләштереп, үз мисалларын әйтә алырлык аңлаешлы булырга тиеш.

| **Э, е хәрефләре** | | | |
|---|---|---|---|
| э – эш, эт, экран | | | |
| е – теш, тел, генерал | | | |
| элгеч | дуэль | фотоэтюд | к*е*ш*е* |
| эшче | поэма | тээмин | каф*е* |
| тээсир | маэмай | | үз*е*шчән |

7. Замана кушуы буенча, мәктәпләргә актив рәвештә мәгълүмати чаралар киң колач җәеп килеп керде. Шуңа күрә кайбер дәресләрне презентацион материаллар, интерактив такта кулланып та оештырырга була. Болар барысы да укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру чарасы, чөнки алар заманча һәм кызыклы. Интерактив тактада бирелгән материал дәресне җанлырак, тәэсирлерәк, истә калырлык итеп үткәрергә булышлык итә.

**Кулланылган әдәбият**

1. Зиннатуллина Г.Ф., Гиниятуллина Л.М. Интенсивный курс татарского языка / Г.Ф.Зиннатуллина, Л. М. Гиниятуллина. – Казань, 2010.

2. Максимов Н. В. Морфология һәм орфография буенча кулланмалар / Н. В. Максимов. – Казан: Таң, 1997.

3. Мифтахов Б. М. Татар теле орфографиясе һәм пунктуациясенең кыен очраклары / Б. М. Мифтахов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 370 б.

4. Сафиуллина Ә.Н. Татар теле орфографиясенең кыен очракларына дидактик материаллар / Ә.Н. Сафиуллина. – Казан: Гыйлем, 2008. – 145 б.

5. Шакирҗанова Ә. Б.Татар теле орфографиясенең кыен очраклары / Ә. Б. Шакирҗанова. – Казан: Школа, 2009. – 158 б.